Рөстәм
Зарипов

# ТАМЧЫ
# ГӨЛ

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2004

УДК 820/89(470)
ББК 84(2Рос=Тат) 6
З 26

**Зарипов Рөстәм**

Тамчы гөл: Шигырьләр, хикәяләр, пьеса. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. — 206 бит.

Рөстәм Зарипов үзенең хикәяләре, шигырьләре белән әдәбият сөючеләргә матбугат битләрендә инде узган гасырның җитмешенче елларыннан ук күренгәләп килгән исем. Аның «Тамчы гөл» җыры халык арасында аеруча популярлык казанды. Бу җыентыгында Рөстәмнең шигырьләре, җырлары, хикәяләре, публицистик язмалары һәм пьесасы урын алды.

ISBN 5–298–01382–1

© Татарстан китап нәшрияты, 2004

# ШИГЫРЬЛӘР, ҖЫРЛАР

+ + +

Мин аклыктан качып китеп барам,
Артта кала ап-ак яулык болгап ак кул:
...Ак юл сиңа, ак юл...

+ + +

Һәр язганыннан кычкыра
«Мин — шәп» дигән фикер;
Әхлаксызлык үрнәге ул,
Үз-үзеңә зикер.

## НӘСЫЙХӘТ

Тирәнәйгән саен караш,
Тараймасын сулыш;
Язмыш төпкә тарткан саен,
Кояшкарак елыш...

+ + +

Инде менә күпме уйладым:
Таш яуса да, давыл кузгалса да,
Җилгә очмас төсле, яшәр сыман
Минем тузганактай хыялым...

+ + +

Карап торырга соклангыч: ирек кебек иркен зәңгәр киңлек.
Диңгезмени, акчарлаклар оча. Гаҗәп, гаҗәп сусаклагыч...
Тик күмелеп калган төптә кайчандыр тау-таш ярган чишмәләр.
Сандугачсыз, талсыз һәм кояшсыз.
Алар исле су күләмен ишәйтәләр...

+ + +

Чабаталар атып, илдән сөргәч
Шәхес культын,
Гөлчәчәкләр тотып каршы алдык
Фәхеш культын.

+ + +

Ай Җир тирәли әйләнә,
Ә Җир урый Кояшны.
Мәхәббәт өчпочмагының
Шул, ахры, чишмә башы...

\+ + +

Җәйне — яшәү, кышны — тыну, диләр;
Күңел күнми мондый шартлылыкка.
...Җылы якта безнең ватандашлар
Тилмерәләр кышкы яктылыкка...

\+ + +

Алга бараммы, арткамы — төшенмим,
Башкарсам да, дөньяның бер эшен мин.
Менә сиңа чикләвек, дип, өйделәр,
Ваттым барсын, тик тапмадым төшен мин...

\+ + +

Юк, яратмый идем күрсәм җилдә
Сыгылуын зифа талларның;
Ул чак үзем ачы миләш идем,
Кырау сукты — мин дә балландым...

\+ + +

— Алай түгел, болай кирәк, — дия-дия,
Тәңгәл санап хыялны һәм мөмкинлекне,
Уздырыштан остарабыз, өйрәтәбез,
«Фаш кылабыз», «оялтабыз» президентны.

Ә ул — сабыр, безнең белән бәхәсләшми,
Моңсу гына елмая да, бары эшли.
Һәм кайтара чорлар аша рухыбызга
Милләтебезнең намусы — Кол Шәрифне...

\+ + +

Кайчакларда сагыш ачыттыра,
Талый, борлыктыра күңелне.
«Хуш килдең!» — дип, ишек ачып тора,
Түрләренә әйдәп, үлемне...

\+ + +

Беркем хәтерләми икебезнең
Зәңгәр күкне кыеп очканны!
...Бер сызгырып куям, ачы итеп,
Сискәндереп кунган кошларны...

НИЧӘ ГАСЫР...

Ничә гасыр канлы сугыш бара
Дин-исламга каршы.
Иң алгы сызыкта, ут эчендә
Газиз татар башы.

Җимертелгән мәчетләребез күп,
Кем чыгарыр санын?
Рәсәй җире чирәмен кубарсаң,
Чыгар татар каны.

Җимеш ашый, рәхәт яши, имеш,
Гарәп, төрек, фарсы.
Ут эчендә һаман татар кала, —
Яна ярсый-ярсый...

## КИТҮ

Бу күктә йөзгән болытлар
Кемнәрнең сагышы икән?
Ник каршы исә җил, әллә
Аерылышу шушы микән?..

Вак, салкын яңгыр сибәли,
Юл бормалы, кырлар буп-буш.
Каерылып карыйм артка, —
Сау бул Мөслим, хуш инде, хуш...

## ГАЛЛӘМ МАСКАСЫ

Яңа ел җитте,
Бүген зур бәйрәм.
Бик күптән көтте
Пионер Галләм.

Шатлана Галләм,
Маскасы әзер.
Маскасын киде, —
Негр ул хәзер.

Кулында аның
Өзелгән чылбыр.
Ул халык көчен
Күрсәтеп торыр.

Шуны аңлата
Галләм маскасы,
Шуны белдерә
Дөнья картасы!

## ТӘРӘЗ КИНӘТ АЧЫЛДЫ ЯК-ЯККА

Төнлә, кызлы өй тәрәзен шаку!..
Безгә андый бәхет эләкте.
Әнкәң уянмады. Әткәң чыгып,
Сыртка төшермәде көрәкне.

Тәрәз кинәт ачылды як-якка,

Пырхылдап көлеп син күрендең;
Күзләреңә төшкән ай нурыннан
Йөрәгемә ялкын эленде...

## ТУГАН ТЕЛ

Синдә сандугач һәм чишмә,
Синдә кыя, упкын, лачын.
Һәм һәркемгә җитешле моң
Телә — ела, телә — ачын,
Телә — елмай Җәлилләрдәй,
Йә Дәрдмәндтәй сагышлан.
Йә ян, дөрлә, Тукай булып,
Халкыңа берек, багышлан.

Кайсы телнең алып бакма
Үткәнен һәм бүгенгесен,
Җир белән күк аермасы —
Калса калган бер-ике сүз.
Синең сүзләргә тутык юк!
Синең сүзләр — саф энҗеләр!
Ничә гасыр гомер кичеп,
Үзгәрешсез җемелдиләр.

«Мин—бай!» дип, син «мин — гүзәл!» дип,
«Мин — бөек!» дип шапырмыйсың,
Каядыр китәсең дә күк,
Тик дәшмисең, чакырмыйсың.
Син китәсең, халкың кала,
Өсте бөтен, тамагы тук.
Бабалары зиратында
Дуңгыз йөри актарынып.

Әй туган тел, әй матур тел,
Берүк ташлап китмә безне.
Сакла рухны, сакла моңны,
Сакла кешелегебезне...

## ҺӘЙКӘЛ

Нурлы Казанында мәңгегә
Муса зынҗырланган, дисәләр,
Ышанмагыз, андый һәйкәлне
Дуслар кормас, аны сөйсәләр.

Мондый һәйкәл тиеш калкырга,
Багышланса әгәр Җәлилгә,
Алман дигән илнең түрендә,
Моабит төрмәсе янында.

Һәр чын шагыйрь кыска гомерендә
Кабатлый үз халкы язмышын.
Тамчысына кадәр эчкән ул
Татарына төшкән каргышның.

«Яугир булган, ут вә су кичкән,
Әсир төшкән, башы чабылган,
Асыл исеменә ни гомер
Катлам-катлам яла ягылган...»

Әмма хаклык барыбер килә,
Ансыз кыен безнең халыкка;
Җәлил исеме дә бер көнне
Сүнмәс ялкын булып калыккан.

Улы милләтенә, ә милләт
Бер улына мөмкин охшарга;
Ул һәйкәлгә мин бик еш киләм,
Очрашу билгеләп, дусларга.

Чәнечкеле зынҗырлар белән
Боргычланган мазлум халкыма
Казан йөрәгендә һәйкәл бар —
Ул азатлык даулап, талпына!..

## ТУКТАЛЫП КАЛДЫМ ДА...

Күтәрелеп карадың да
Янымнан киттең узып.
Тукталып калдым да торам,
Атын туарган арба күк,
Ике кулымны сузып.

Ияреп китәр идем бик, —
Куып җитәрмен кебек, —
Җиткәч, каушап, сүз әйтәлми
Узып китәрмен кебек...

## БЕР ХАТИРӘ

Ат итеннән, чуенда томалап, мичтә
Чумарлы-борчаклы аш пешкән...
Әни телем-телем кара икмәк кисә —
Борын кытыклана хуш истән...

## ЗИРАТТА

Әллә чигеш, әллә нәкыш
Гарәп хәрефләре.
Ә мин — надан, таяк дип тә
Белмим әлифләрне...

## ЮККА...

Карар кылып, сыңар имза
Салды тикшерүче.
Мәхкәмәсез, ирегеннән
Мәхрүм булды Кеше...

Камерада «иптәшләре»
«Кызык» эшләделәр:
Башта тотып тукмадылар,
Аннан көчләделәр...

Тик барыбер хаклык җиңде —
Акладылар судта;
Тикшерүченең хезмәте
Чыкты чүпкә, юкка...

+ + +

Китеп барган чак та булды,
Кайтып киткән чак та;
Маңгай терәп баганага
Торган чак та, чатта...

Уйлыйм, капылт кына әле
Тагын бер кителер;
Дөньяның чите ул чакта,
Мөгаен, кителер...

## БҮРЕКТӘГЕ БҮРЕ БАЛАСЫ

Урманга карый, дип гаеплиләр
Бүректәге бүре баласын.
Бәгырьсезләр мәңге аңлый алмый
Нарасыйның йөрәк ярасын.

Адәм исе сеңгән йонлач бүрек
Җәнлек тунап теккән киемдер,
Бүре балакайга аның эче,
Кичерегез, җәннәт түгелдер...

Һәм бүреккә аны аучы салган,
Атып алгач газиз әнкәсен.
Бәйгә күнектереп, бәләкәйдән
Эткә әйләндерү — максаты!

Урманга карый, дип гаеплиләр
Бүректәге нәни бүрене.
Ә бит ул тумыштан ватанпәрвәр,
Шуңа илен барлый үрелеп...

## КЕШЕ

Урыс «Бог» ди, аның өчен «бог»ы Хода,
Ә татарда ошбу сүздә үзгә мәгънә.
Ничә гасыр ут күршебез шуңа мәллә
Безне сүгеп ләгънәт укый, ора нәгъръә?!

...Һиндстанда яши, имеш, ике кавем,
Ызгыш-талашта җилгәреп яшәү ямен.

Эш шунда ки, берсе өчен «лингва» — Хода,
Икенчесенә, йа Тәңре, мәгълүм әгъза...

Шул сүз сәбәп, болар дошман мәңге бакый
Онытканнар «күрше хакы — Алла хакы»н.

...Тарих бәян итә, борын заманнарда
Фаллоска табынган барлык халыклар да...
Кичеп дәвер, томырылып вакыт чапкан,
Бербөтен мәгънә бүленгән ике чатка.

Хәер, ник ерак йөрергә һинд җирендә,
Шундыйрак хәл түгелме үзебездә?
Инанулар чыганагы уртак ласа,
Чорлар рәшәсе артыннан фаллос баса.

Бүген дә сау изге фаллос шәҗәрәсе,
Әнә чиркәү, әнә мәчет манарасы;
Берсе сөннәтләнгән төсле, берсе очлы,
Хач йә ай булып җемелди очта тамчы...

Шул тамчыда гәүдәләнә Кеше үзе,
Җаны-тәне, гакылы һәм әйтер сүзе...

## ЮБИЛЕЙДА УЙЛАНГАН УЙ

Язым үтте, язмый калдым
Булмаганга кәгазем.
Хәзер бар, тик ни мәслихәт, —
Онытылган вәгазем...

## БЕР МӨХӘРРИР АВЫЗЫННАН

Язмасын, дип, юньсез мәкалә
Хатын-кызга бирик ни намә?
Һәм ир-атка ниткән рәтле эш?
Юкса роман сырлый, хәчтерүш...

## АКЧА МӘСЬӘЛӘСЕ

Акча булса, бар да дус та, бар да яр,
Акча исе янда бетсә, бар да яныңнан таяр...
*Габдулла Тукай*

Акчаң булса, гөл сибәләр йөзеңә,
Акчаң бетсә, көл сибәләр күзеңә...
*Равил Фәйзуллин*

Гасыр узды, калынаймый
Шагыйрьнең кесәсе,
Тапмый уңай чишелешен
Акча мәсьәләсе...

## БИОФИЛЛАР

Как жену чужую,
Обнимал березу.
*Сергей Есенин*

Ялгыш каенны кочканмын,
Мин аны син дип торам.
*Роберт Миңнуллин*

Сексуаль азчылык төрләнештә,
Бозыклыкка дөнья ничек чыдар?
Зоофиллар гына җитми иде,
Пәйда булды каен кочучылар...

## КҮРСӘТ ИХЛАСЛЫГЫҢ!

Сергач якларында, концертларда
Ялыктырса әгәр берәр җырчы,
— Икенчең чыксын! — дип аваз сала
Гаҗиз тамашачы.

Күп гәзит-журналда бар даими,
Бер сан калмый сару кайнатучы.
Мишәр агай, кайда ихласлыгың?
Кычкыр, пожалысты!..

## МИН БОРЫЛЫП ЯТТЫМ...

*(Пародия)*

Мин оныттым сине. Ә син әрсез
Төшләремә һаман керәсең.
Җанның теленгәнен беләсең бит,
Арадагы ярны күрәсең...
Телгәләнеп беткән йөрәгемне
Учка кысып тагын кабатлыйм:
Уйларымнан, төшләремнән кит син,
Мин яратмыйм сине, яратмыйм...
*Мөдәмил Әхмәтов*

Мин борылып яттым. Ә син әрсез
Куеныма һаман керәсең.
Җанның үртәлгәнен беләсең бит,
Яшь аермасын да беләсең...
Шәлперәйгән, шиңгән йөрәгемне
Учка кысып тагын кабатлыйм:
Азаплама мине, кит янымнан,
Мин яратмыйм сине, яратмыйм...

+ + +

*Фәизаман Батталга*

— «Тибүчеләр»не фаш итеп,
Кем ул анда теге сакал?
— Кем булсын, мәшһүр Тибүче
Фәнзаман әфәнде Баттал!

*(«Тибүчеләр» — Фәнзаман Баттал язган мәкалә исеме.)*

## ШАГЫЙРЬ ДУСТА КУНАКТА

— Кул суз һәм сос, табын күрке, —
Чикмән кигән бавырсак;
Карап торма, бүтән сый юк,
Аңлыйсыңдыр, авыр чак.

Бер шифа тапмый калмабыз,
Әгәренки авырсак;
Аша туган, әнә суган,
Ачы торма, сарымсак...

+ + +

*Фоат Садриевка*

«Адәм әүлиясы» дими җай юк,
Кунак итеп, «Тозлы бал» ашаттың!
«Таң җиле»нә чыгып, хәл-тын алгач,
«Их сез, егетләр...» — дип, тел шартлаттың.

*(Куштырнаклар эчендә автор*
*язган әсәрләрнең исемнәре.)*

+ + +

*Флүс Латыйфигә*

«Бәйсез этләрне атарга» икән,
Ничек «Ак-карага тимәскә»?
Җитмеш мең тиражлы «Хыянәт»ең
Өнди башны түбән имәскә!

*(Куштырнаклар эчендә автор*
*язган әсәрләрнең исемнәре.)*

+ + +

*Мөдәмил Әхмәтовка*

— Татарстан, әйтче, син соң мөдәм илме?!
Ник белмиләр бөек шагыйрь Мөдәмилне?
— Андый шагыйрь, кызганыч ки, аунап ятмый,
Ахры, шуңа аны һичкем күрми, тапмый...

## АЛЫШ-БИРЕШ

Татарстан, вузларында белем биргәч,
Иң укымышлы яшьләрен читкә куды;
Салып төрмә, корып зона, колония
Үзе чит-ят тарафлардан зеклар җыйды.

Срок тулгач, бу соңгылар бездә калды,
Төрмә рухы җиребезгә сеңә барды.
Тимер таяк алып кулга яшьләребез,
Шул рух илә тешләр койды, башлар ярды.

Татарларны әшәке дип күп яздылар
Гәзитләрдә, журналларда, китапларда;
Инде менә дәлиле дә булдырылды
Язмаларының «хаклыгын» исбатларга...

+ + +

КамАЗ арты АлАЗ күтәрелә,
Калка бер-бер артлы гигантлар;
Саранчадай басты туган җирне
Җыен этрәк-әләм мигрантлар.

Халыклар дуслыгын әләм иттек,
Бездәй аңлы халык бар кайда?
Килмешәкләр арта барган саен,
Милли депутатлар азая...

+ + +

Җитәкчене шуннан таныйм:
Басуга кереп китә дә
Үрелә гел башакка;
Өзә, бөртекләрен саный,
Исни, куя ашап та...

## АКАДЕМИКЛАР

Әле кичә генә «таз» иделәр,
Бүген исә — академиклар.
Элегрәк алар аз иделәр,
Саранчадай басты жуликлар.
Тик бүгенге академикка
Без, олылап, «әкә!» димик лә...

## СССР ТАРИХЫ

Сөннәткә утыртылды тәре,
Анысы ярый әле.
Килеп чыкты чүкеч —
Булды бер эш.

Ә кисекне сап итеп,
Беркеттеләр айга.
Булып чыкты урак —
Тагын файда.

Эшче ир һәм крәстиян хатын
Тотып шушыларны,
Коммунизмга, дип,
Җитмеш өч ел барды...

+ + +

Аргамактан туа толпар,
Ишәктән ишәк инде.
Каулаучыңнан чамалыйсың
Үзеңнең кемлегеңне...

## АЛМА

«Алма агачыннан ерак төшми»,
Димәк, әче, кортлы, диеп аңла.
Илләр-җирләр, чүл-дәрьялар кичә
Татлы, таза алма...

+ + +

Җир астында алтын казык, —
ул нәрсә?

Кешеләр бу табышмакны
Кайта-кайта әле чишәр.
Эзли-эзли алтын казык,
Тотып кала-кала кишер...

## «ШАРТ»НАМӘ

Без, Азатлык һәм Бәйсезлек! дидек,
Россиянең эче кабарды.
Көрән төскә керде, ачуыннан
Кызылланды, тагын агарды.
Нык көчәнүләрнең нәтиҗәсе —
Зур хәрефле олы килешү...
Дөрес чамалыйсыз, милләттәшләр, —
Бу — «шарт иткәч», җылы җил исү...

## ТУКАЙ БҮЛӘГЕН БҮЛГӘНДӘ

Анкетасы аның аң китәрлек, —
Карьерасына кер тимәгән.
Мөдәррискә бирдек, Зөлфәт көтәр,
Гел-гел талантлыга димәгән.

+ + +

«Үрмәләүче мәңге оча алмый!»
Төкерде дә Кеше мәкальгә,
Һава океаны төбеннән этенеп,
Менеп китте бер көн галәмгә...

+ + +

Татарның миенә борау
Гамлет куйган сорау:
Шушы киң, якты дөньяда

Булу яки булмау...

+ + +

Күңел түргәрәк омтыла,
Язмыш яргарак кага;
Бәрелә-сугыла ярга
Гомер ага да ага...

+ + +

— Йөрмә, энем, ут йотып, —
«Асылынам» дисә — бау бир,
«Атылам» дисә — мылтык!

— Мәгънә тапмыйм пычак та, —
Ул асылына муенга,
Ә атыла кочакка...

+ + +

...Порнобоевикка тарта Җирдә тормыш,
Кем соң безнең вазгыятьне шулай бормыш?..
Кем режиссер, кем автор, кем тамашачы?
Һәм жанрда чагыла кем ихтыяҗы?..

+ + +

Өрми, нитми, беркемне дә
кертми, — ул нәрсә?

«Өрми, нитми, кертми», — имеш,
Җавап эзлим озак;
Фикер тайпыла да китә,
Чөнки маңгай сөзәк.

Сабакташларның йөзе ак,
Пышылдыйлар: «Йоза-а-а-ак».
Ә минем тел һич әйләнми,
Уйлыйм: «Бу, — дим, — тозак».

«Өрә, нитә һәм кертә»нең,
Нәкъ киресе — шулмы?
Җитмәсә, йозак үз итә
Ачкыч тоткан кулны...

+ + +

— Мин — бәхетле! — дип кычкырды мескен,
— Мин — бәхетле! — диде бичара;
Бәлештән арткан камырдан, имеш,
Пешә аларга да шишара...

+ + +

...Бас, җавап тот, иптәш Горбачев!
*Зөфәр Шәйхетдинов*

Шашлык ашый идек урманнарда,
Авыз итә-итә хәмерен;
Өстән аска ташып яши идек
ЦК КПСС әмерен.
Шәп нарат йортларда яшәп яттык,
Фатир, ут-су хакын белмәдек.
Чөнки халык өчен көн-төн чаптык,
Ул, дип туңдык, пештек, тирләдек.
Колхоз малын уңга юнәлттек тә,
Дәүләтнекен сулга тараттык.
Дөньясын да фани дип тормадык,
Хур кызларын өзелеп яраттык.
Коммунизм бакчасын гизгәндә,
Перестройка басты үкчәгә;
Күлмәкне күтәртеп типте явыз,
Безнең Җир шарыдай бүксәгә.
Сулыш кысты, тынны капландырып,
Бугазга бөялде бар ачу;
Аяк тибеп акырам төшләремдә:
— Бас, җавап тот, мәлгунь Горбачев!

+ + +

Бүген дә көн узып китте, йа Алла,
Тагын ниләр күрәсе бардыр, алда...

## «ОСТАЗ» КИҢӘШЕ

Мактап җибәр җан өшеткеч кышны,
Киләчәге анық — яз, диген.
Ә аккошны артык узындырма,
Ул, просты, матур каз, диген...

## ФЕДЕРАЛИССИМУС

Ирләр яуда чакта, Чечен илен
«Җиңгән» иде генералиссимус.
Ирләр өйдә иде, шуңа гына
Харап булды федералиссимус.

+ + +

Мин дә әйтим әле, әфәнделәр,
Күккә чөеп ямьшек танауны:
Динне хуплаучылар хәттин ашты,
Тотучылар гына санаулы...

## ТУТАШ

Туташ хәтәр, күзләр камаша,
Бер күрүе хәйран тамаша.
Җидедән үргән камчыны селтәп,
Сыдырсаң да каеш күңеленә,
Тырналу да анда калдырмыйча,
Чажлап кына шуып үтәчәк...
Коелып төшә иде кайчан гына
Саксыз ымнан, әрсез караштан...
Хәзер — хәтәр, күзләр камаша,
Яннан узып китә ләбаса!..

## ХИРУРГ МОНОЛОГЫ

Кемнең генә бүксәсен ярсам да,
Гел бер үк нәрсәгә юлыктым...
Кеше карбыз түгел, бәхәсләшмим,
Һәм хакыйкатьтән дә курыкмыйм!

## ПАРАДОКС

Үз туганы белән кара дошман —
Бар милләтне берләштермәк булды.

Хатынына баш була белмәгән —
Президентлыкка дәгъвасын кылды.

Сыңар хулиганнан коты очкан —
Барча урысларга күсәк изи.

Рәтле гаилә дә кора алмаган —
Безгә, имеш, тәти дәүләт төзи...

Адәм рәтле нәселдән чыкмаган —
Затлылык хакында теш агарта.

Нәсыйхәт укый әхлаксыз... Надан,
Отканнарын сөйләп, җиңнән тарта...

## ЗЫЯЛЫЛАРЫМЫЗ

Милләтнең күкрәген изгән ташка басып,
Зыялылар акыл сата, чиратлашып.
Берсе дәшә: «Татар халкы, уян инде!»
Икенчесе: «Ул бит күптән куян инде...»
Өченчесе: «Ул — хөсетле, сатлык», — имеш,
Тагын берсе: «Аңа юлдаш — картлык», — имеш.
Кайсы әйди: «Чеченнәрдән үрнәк алыйк...»
Бәгъзеләре: «Яһүд төсле булып карыйк...»
Иренәнә су тидерми бер баласы, —
Ята милләт, аһ, ничекләр тын аласы?..

+ + +

Имеш, матур чәчәк атсын өчен,
Бирсен өчен җимеш,
Кеше күңеленә бераз гына
Тирес керү тиеш...

## ИШЕК ШАКЫДЫЛАР...

Ишек шакыдылар көтмәгәндә.
Баштан төшеп китте түбәтәй.
Төксе караш ташлап, түргә үтте
Тикшерүче, ике пүнәтәй.

Каян, нәрсә тартып чыгарырлар?
Башта төрле уйлар — чүмәкәй...
Әле генә бөркет иде йөрәк,
Инде пыр-пыр килгән чүрәкәй...

+ + +

Ике ахмак бәхәсләшә:
Берсе аңламыйча, берсе аңлап.
Сорау туа:
Кайсы ахмаграк?

## МАНТЫЙК

Бер шоколад алып, бүлгән идем
Улым һәм кызыма,
Апасы битемнән пәп иттерде,
Энесе тузына.

— Тип-тигез бүленде ләбаса, — дим, —
Ник дулыйсың алай?
— Миңа тигез кирәк түгел иде, —
Дип лышкылдый малай...

## КАЙТУ

Армиягә килгән яшь егеткә
Честь бирергә куша командир.
Бугазыннан алып, «стариклар»,
«Дедлар» таләп итә: «Давай, бир!»

Киткән юлларына күзен текәп,
Бер кыз көтә, керфек талдырып.
Кайтып килә яры армиядән,
Честь-намусын биреп калдырып...

## ХУШ, БӘХИЛ БУЛ, РӘСӘЙ...

Утка өтеп һәр үлән кыягын
Син гел яңа җирләр яуладың,
Тик кадалды илләр күкрәгенә
Кан-яшьтән тукылган байрагың.

Каф тау җан авазын ирештерде
Лермонтовның шигъри чаптары:
«Хуш, бәхил бул, тәһарәтсез Рәсәй —
Коллар һәм түрәләр ватаны».

Ә үзеңә каршы яу кузгалгач,
Бугазыңнан алгач үлемең,
— Туганнар, — дип дәштең халыкларга,
Бик нечкәргән иде күңелең.

Үзеңне үлемнән йолганнарга
Синнән бүләк булды хыянәт;
Сабый балаларга, карт-корыга,
Хатын-кызга купты кыямәт.

Терлек вагонында син аларны
Ач далага илтеп катырдың;
Онытылып калганнарын җыйнап,
Утка салдың, суга батырдың.

И кинәндең талап, нәфесеңне
Гел аракы белән сугардың,
Мәрхүмнәрнең соңгы малы булган
Кабер ташларын да кубардың.

Ай уелган изге шул ташлардан
Юл түшәдең, табып рәхәтен.
...Украинны син башкача издең —
Оештырып ачлык афәтен.

Ул афәтне коллык дәверендә
Татып арды Идел татары...
Кычкырасы килә: «Бәхил бул, әй
Кеше ашаучылар ватаны».

Чечен, Әфганга барып сөрлекте,
Күп гасырлык тәре походы,
Офыкларны канга күмеп байый
Илбасарның кара бәхете...

Мең үлемне кичкән халыкларга
Атар азатлыкның ал таңы;
Хуш-бәхил бул, үле җаннар иле,
«Пахан», «шестерка»лар малиннигы,
Швондер, Шариковлар ватаны...

## ГАЗАПЛЫ ГАШЫЙК

Гамил Афзалның
«Сайладым, их, сайладым»
шигыренә ияреп.

Ник алаймы, ник алаймы?
Без яраттык Николайны, —
Биле нәзек, кашы кыйгач,
Бер бите ай, берсе кояш;
Халык канын көн-төн эчте,
Тәхетеннән чукынып төште.

Унҗидедә, көзге кичтә
Гашыйк булдык без Ильичка, —
Сакал бер уч, маңгай пеләш,
Бер бите ай, берсе кояш;
Хөррият, дип кертте утка,
Аннан чыккач, салды суга.
Дөнья рисваена калдык
Алданып шул шалапутка.

Мәхәббәткә кысталуга,
Барып аудык Сталинга, —
Бер кул корган, мыек кыйгач,
Уң бите ай, сулы кояш;
Кот алына карашыннан,
Баш гел чыкмый парашадан,
Асты-кисте, суйды-урды
Тимер йөрәк, калай морда.

Ләкин безнең ис китмәде,
Якын иттек Никитаны, —
Керфекләр ак, башы пеләш, —
Бер бите ай, берсе кояш;
Кукурузга кинәндерде,
Бер чуашны өйләндерде,
Боргаланмый әйтсәк туры,
Тәк просты, адәм хуры...

Бәхет кунды бер яз учка,
Гашыйк булдык без Горбачка,
Аннан да суындык имди,
Кәкрәя язгач ачка.
Аннан патша булды Ельцин,
Күрсәтте ул илгә көчен;
«Суверенитетлы» итте,
Рәхмәт аңа шуның өчен...

Бүгенгесен әйтеп үтим,
Инде сөеклебез Путин;
Әбрәкәйдә мачить итә...
...Ә без нәрсә? Пока шутим...

## ҖИРСҮ

Зәңгәрлектә йөзә ак болыт,
Кемдер күзли аны онытылып...
Кыр казлары китә тезелеп,
Озатып кала берәү, өзелеп...
Ә төннәрен йолдыз атыла,

Күккә багучылар хакына...
...Тән — Җирнеке, Рух ватаны — Күк,
Күкне җирси күңел һәр минут...

## ТЕЛ ЯЗДЫРУ

Сәфәр йөреп кайткач, хәләлеңнең
Хәл-әхвәлен белешергә теләп,
Күрше хатынының маңгаена
Куш көпшәле ау мылтыгы төзәп,
Сорашу — ахмаклык, таначак
Һәм артыңнан көлеп калачак...

Очраганда сәламенә каршы,
Әгәр «фәхишә» дип пышылдасаң,
«Үз хатыныңны бел, алаша!» — дип,
Бугазыңнан буып алачак,
Урынын-вакытын, хак-нахагын
Бәйнә-бәйнә тезеп салачак...

## ТОЛПАРЫМ ҖИТЕЗ ИДЕ...

Толпарым җитез иде;
Җилләр җиткесез иде:
Йөрәккә ут якмадым,
Чапмадым шул, чапмадым.

Көрәшчеләрне күрдем,
Араларында йөрдем —
Тик таммады каннарым,
Янмадым шул, янмадым...

Китте йөзеп салларым —
Дымланды күз алларым;
Үз-үземне саkладым...
Нәтиҗәдә — акмадым...

## ЮЛ ЧАТЫНДА

Юл чатында таштан язу укып,
Уйга калган татар егете;
Каян барса чәлпәрәмә килмәс,
Шушы яшь егетнең өмете?

Уң тарафта марҗа кәләш көтә,
— Яратам! — дияр дә туңкаер;
Балалары, оныклары туар,
Алар: «Без — урыс!» — дип кылтаер.
(Урыс зиратында гүргә иңәр,
Кабереннән тәре тырпаер.)

Сулга китсә, карак түрә көтә,
Егет булыр аңа олтырак,
Һәр бирмеш көн хәрам мал китерер,

Машинасы торыр елтырап.
(Кесәләрендә акча чылтырар,
Тик гомере үтәр кылтырап...)

Туры китсә, кунар керфегенә
Олы, озын юллар «сөрмәсе».
Сындырырга теләр армиясе,
«Кеше итмәк» булыр төрмәсе...
Сынауларны узып, исән кайтса,
Барыбер көтмәс аны түр башы...

Кая барырга соң, кайсы якка,
Кай тарафка китеп абынсын?
Сарык булып бүре, бүре булып,
Сарык тиресеме ябынсын?..

...Тик бер киңәш: нәсел чертмә, энкәш,
Малга хирыслык та ялгыш ул;
Юнәлешне кыйбла якка сайла,
Иманыңны күкрәгеңдә сакла,
Күзләреңдә нуры балкысын!..

Үз урынын тапса гына затлы катлам,
Кешечә яшәүгә таба хет бер атлам
Кузгалырбыз. Ә әлегә хәлләр яман,
Татар көтү — табынганы, димәк — чабан...

## ТӨШ

Мин төш күрәм, имеш ки, мин күк хадиме,
Җир язмышы сыйдырылган монитордан,
«Т» атлы төймәгә басып, һәр адымын
Татар милләтенең, имеш, карап торам.

Татар — тырыш, билен буып дуңгыз бага,
Тирес түгә, җир сукалый, күмер чаба;
Вакыты тар, хәтта милли бәйрәмен дә
Кайсы елны оештыра шыксыз көндә.

Гайрәт чигеп басам башка төймәләргә...
Мониторны карнаваллар биләп ала...
Политика... Экзотика... Эротика...
Мондый поэтикадан җан эреп китә...

Карап ятам хозурланып, хөҗерләнеп,
Кяфер кавемнең шаукымлы мәгыйшәтен;
«Мөселман... чечен... фәлән...» — дип борчысалар,
— Тсс, — мин әйтәм, — пожалысты, не мешайте!

Тәмле төшемне шул мәлдә бүлдерәләр,
Сүзнең миңа бирелгәнен белдерәләр;
Депутатлар авыз ачып карап тора,
— Ах, — мин әйтәм, — өн дә пока ярап тора...

## НИК ТӨКӘНМИ?

Азатлык, дип, нәни милләт тәмуг кичә,
«Бөек» халык аның канын көн-төн эчә...
Җәллад — чара... Хөкемдар кем? Һәм шул гомер
Ни өчен түкәнми, кайтмый кемнең үче?!
...Өмет өзми тәмуг кичә чечен халкы,
Янартау йөрәге алга әйди аны...

## БУ — БЕЗНЕҢ ИЛ ТҮГЕЛ...

Паспортымны ачып укыйм —
Мин шушы илнеке.
Әмма ышанасы килми,
Килми, бетте-китте.

Тургайдай күккә чөелми,
Менми, очмый күңел,
Ә йөрәкнең һәр типкәне:
— Бу — безнең ил түгел!

Бу илдә тиз төшерәләр
Муен тамырыңа,
Кемдер тез астыңа тибә,
Бөер-бавырыңа...

Бирешми яшәргә мөмкин,
Булмаса да җиңел.
Тик һәр күзәнәгең сизә,
Бу — безнең ил түгел...

Телең денеңнән яздыра
Һәр бирмеш көн монда.
Каян эзләргә ватанны,
Кайда безнең Урда?..

## МАЙТАП ҖИҢГИНЕҢ ХАЛИТ АБЗЫЙ КОЛАГЫНА ИРЕШТЕРГӘННӘРЕННӘН

— Синең суга бармау, миңа суга,
Зинһар, бүген генә барчы суга.
Ә мин, бәгърем, китәм кычыткanga,
Чәүчәләк йөрәгем кычытканга.
— Майтап, май тап, дисең, бәгърем Халит,
Син ир кеше, майны үзең хәл ит!
...Өстәлдә алма бар; аны алма,
Казанда салма бар; аны салма,
Юкса ач калырлар балалар, дим,
Кемгә әрем, безгә бар алар, дим.
...Көзләр җитәр, кырда башак тулыр,
Картаербыз без дә, баш ак булыр;
Утын эзләп чыгып китәрбезме,
Йөрәк утын сарыф итәрбезме?

— Ботак кирәк! — дисәм, аңларсыңмы?
— Бот?! Ак!!! — диеп чыгып чапмассыңмы?..

# ҖЫРЛАР

## ҖАЙДАКЛАР

Җайдаклар, җайдаклар, җайдаклар килә,
Тояклар, тояклар ялкыннар сибә.
Юлларны ачыгыз, ачыгыз аларга,
Җайдаклар керсеннәр мәйданга...

Яшь кызлар, язгы саф чәчәкләр,
Сез һәрчак җайдаклар уенда.
Очыгыз, очыгыз яшь кызлар, яшь кызлар,
Җайдаклар, җайдаклар куенына!..

## ТАМЧЫ ГӨЛ

Сөңге бозлардан тамчы коела,
Тал бөресенә кошлар сыена.
Тамчы гөлләрдәй, сылу елмая,
Сиңа дип җыйган гөлләрем кая?

Кушымта:

Тамчы гөл! Ә-әй, тамчы гөл,
Сине уйласам, өзелә күңел,
Өзелә күңел, әй, сеңел.

Кояш ут яна, карлар карала,
Бозларда ярсып, учаклар ага.
Арада дәрья, син — аргы ярда,
Ашкыныйм кая, сикерим кая?

Кушымта.

Гөрләвек ага җиргә сарылып,
Чуерташларның битләрен юып,
Тамчы гөлләр дә сине сагына,
Кайт чибәрем, кайт, минем яныма.

Кушымта.

## ХАЛӘТ ФАСЫЛЛАРЫ

Мәхәббәт кабына, таң ата,
Бар дөнья ал нурга күмелә.
Һәм тургай йөрәге күкләрдә
Җыр булып кояшка үрелә.

Хисләнә болытлар
Саф көмеш тавышка.
Кояшлы яңгырда

Адаша сагышлар...

Мәхәббәт яндыра, ал гөлләр,
Җилләрдә очкындай, сибелә.
Акчарлак йөрәге ял таба
Шашынган дулкыннар иркендә.

И дәрья, айкама,
Бу кадәр чайкама.
Ак җилкән канатлы
Шул нәни корабны...

Мәхәббәт сүрелә, йа Хода,
Канатлар әйләнгән күмергә.
Һәм калган яшәргә үрмәләп,
Очышны татыган күңелгә.

Каяндыр ерактан,
Биектән ургый моң.
Синме бу, сандугач?
Исәнме, әй, былбыл...

## БЕРЕНЧЕ КАР

Беренче кар... Тагын ява беренче кар,
Нинди якты сезнең урам, нинди ап-ак.
Тәрәзәңдә ут бар. Яна яран гөле...
Эзләремдә җәйнең көле — сары яфрак...
Күзләремә туры карый алырсыңмы,
Шатлыгыңны сагышыңа авыштырып;
Мин тыңларга әзер синең һәр сүзеңне,
Йөрәгеңнең тибешенә чагыштырып...

## СОЛТАНӘХМӘТ

Солтанәхмәт, диләр шатлык тоеп,
Кем төзегән күкне каеп-уеп;
Гүя мәрмәр атып торган фонтан,
Бер мизгелгә туктап калган оеп.

Кушымта:
Аһ Төркия, алсу гөлләр иле,
Сине назлый зәңгәр диңгез җиле.
Ташларыңны сыксаң, шул ике төс,
Тамчы-тамчы янып тамар иде...

Солтанәхмәт тора нурлар чәчеп,
Айя-Суфияне күккә дәшеп;
Кеше рухы мәхәббәтне шулай
Бәян иткән ташлар аша, шашып.

Кушымта.

Зәңгәр мәчет илә алсу мәчет
Тора ярда икәү җитәкләшеп;
Китәр кебек алар диңгез өсләп,
Югалырлар төсле, күккә ашып...

Кушымта.

## ЯФРАК ӨЗЕЛГӘНДӘ ИСКӘРӘБЕЗ...

Кайчак хөкем итә якын дуслар,
Сөйгән ярлар, җиде ятлар да.
Япа-ялгыз газиз әниең килә,
Сине араларга, якларга.

Уңны-сулны тоймый чапты гомер,
Юлга алсу гөлләр сипкәннәр;
Җиңел иде тормыш йөге иңдә,
«Син» дип, шундый йөрәк типкәндә...

Башны аска иеп торам әле,
Сары яфрак күмә каберен;
Яфрак өзелгәндә искәрәбез,
Газиз әнкәйләрнең кадерен...

## МИШӘ ЯРЫННАН ЙӨГЕРДЕК...

Мишә ярыннан йөгердек,
Агымсуларга каршы.
Карлыгач кебек талпынды
Бәгъремнең кара кашы.

Мишә суы алып керде
Карурман түрләренә.
Башкаемны салыйм, бәгърем,
Күкрәгең үрләренә.

Мишә сулары башында
Карурман чишмәләре.
Бәгърем, суын болгатырсың,
Ярларын ишмә әле.

Чишмә яны ярларында
Былбыл кунар тал була.
Салкыны — ялкын сулары
Яшь йөрәккә ял була.

Чишмә ярыннан йөгердек,
Агымсуларга уңай.
Бөтен дөнья нурга чумган,
Мин гашыйк булдым бугай.

Агымсулар алып төште
Ямь-яшел болыннарга.
Әйләник әле, дускаем,
Уралып толымнарга.
...Тәгәрик әле, дускаем,
Уралып толымнарга...

## КАЙЛАРДА АДАШЫП КАЛДЫГЫЗ?

Озакка сузылды изелү,
Дошманнар мәрхәмәт белмиләр.
Җиребез, нәселебез корсын, дип
Ашкынып АЭСлар төзиләр.

Кушымта:

Кайларда адашып калдыгыз,
Татарның канатлы гаскәре?
Араларга безне дошманнан
Гасырлар аркылы кайтыгыз.

КамАЗлар, АлАЗлар ишәйтә
Ватанда килмешәк өйдәшләр;
Дуңгызлар көтәргә калдыкмы,
Безме бу, мөселман кардәшләр?

Кушымта.

Күгенә карарга куркыныч,
Йөргәндә башкалам Казанда.
Тәреләр урманы бит анда,
Тәреләр урманы бит анда...

Кушымта.

## ЗИЛӘ, ЗИЛӘ, ЗИЛӘЙЛҮК

Кем ул аккошлар шикелле
Урамны ямьләп килә?
Танымыйсыз, белмисезме?
Ул минем дустым — Зилә.

Кушымта:

Җил-җил, җил-җил атлый
Зилә, Зилә, Зиләйлүк;
Күңелемдә зилзилә, —
Зилә, Зилә, Зиләйлүк.

Кем ул саф көмеш тавышлы
Чишмәдәй челтерәп көлә?
Танымыйсыз, белмисезме?
Ул минем дустым — Зилә.

Кушымта.

Аның эзләренә басып,
Йөргән юлларыннан атлыйм;
Исемнәрен онытмаска
Көннәр буе кабатлыйм.

Кушымта.

## ТУГАН КӨН

*Н.абыйга*

Нинди ямьле кышкы урман!
Ак каеннар бигрәк якты.

Ак каендай якты көннәр
Кая акты, кая акты?..

Кушымта:

Кеше күңеле кара урман,
Тик чәчләргә ак бәс кунган.
Тәбрик ява уңнан-сулдан,
Нәрсә булган, нәрсә булган?..

Нинди ямьле язгы урман!
Кар астыннан ага сулар.
Кар астыннан аккан судай,
Сизелми дә уза еллар.

Кушымта.

Нинди ямьле җәйге урман!
Җәйге урман тора моңнан.
Сандугачлар җырын тыңлап,
Аткан таңнар, узган төннәр.

Кушымта.

Көзге урман — алтын урман,
Очкынланып җилдә шаулый;
Урман түгел, безнең гомер
Дөрли-дөрли кайный шулай...

Кушымта:

Кеше күңеле кара урман,
Тик чәчләргә ак бәс кунган.
Тәбрик ява уңнан-сулдан,
Нәрсә булган, нәрсә булган?..
Әйтмәсәк тә әйтик инде,
Якын дусның туган көне...

## ТУРГАЙ РУХТАШЫ

*С-га*

Сиңа сыеналар җылы эзләп,
Җылы яктан кайткан качаклар.
Син тир түккән җирдә баш күтәрми
Тулып пешә алтын башаклар.

Тургай моңы җирдә яңгыраганда,
Кемдер йоклый икән, йокласын.
Сиңа иртә кузгалулар язган,
Тургай бит ул синең рухташың.

Күтәрә беләсең игенчене,
Олылый беләсең җырчыны.
Тау халкына ярдәм җибәрүең
Күңелләргә бигрәк хуш килде.

Күпме игелекләр эшләсәм дә,
Барыбер тәмуг, диеп юрама.
Синең яхшылыклар, агай-эне,

Йөрәк түрләренә юл ала...

Бодай — алтын, чишмә суы — көмеш,
Синең сыең алтын-көмешле.
Бераз гына без дә авыз итик, —
Саташтырыйк, әйдә, йөрешне.

Күгең биек, офыгың киң булсын,
Хыялларың һәрчак канатлы.
Җиктереп чап әле Парижларга,
Җиктереп чап әле пар атны!

## ЙОСЫФ АЛАН

Тирә-ягың бөдрә урман, Йосыф Алан,
Урамыңда урман шавы җил искәндә.
Акбүз атларга атланып, синең якка оча идем,
Оча идем айлы кичләрдә...

Күрше авыл Йосыф Алан, Йосыф Алан,
Синдә гашыйк булган идем мин бер кызга;
Тын күлеңдә йөзеп, аңа өзгән идем төнбоеклар,
Күктә янган чакта йолдызлар.

Сиңа кайттым, Йосыф Алан, еллар урап,
Озак йөргәч чит җирләрдә каңгырып.
Кайда китте, кайда китте ал яулыклы ул гүзәл кыз,
Нигә китте сине калдырып?..

## САБА

Саба җилләре аралый
Тау битендә артышны.
Тауга мендем, таудан төштем,
Баса алмадым сагышны.

Безнең Саба якларында
Кызларның бите алсу.
Шул гүзәлләр арасында
Ник син генә ямансу?

Саба урманына керсәң,
Ургылып чишмә ага.
Әйдә дустым, шул чишмәгә,
Андагы һава — дәва...

## САБА САБАН ТУЙЛАРЫ

Сагыш басса, рух сыгылса,
Авырайса уйларым,
Күңелләргә канат куя
Саба сабан туйлары.

Саба халкы — көрәшче халык,
Якты аның уйлары.

Шаулап тора, гөрләп тора
Саба сабан туйлары.

Дөнья баһадиры килсә дә,
Узсын әйдә мәйдан түренә.
Тик җиңелсә, үпкәләмәсен
Саба егетләренә.

Саба халкы — көрәшче халык,
Якты аның уйлары.
Мәңге-мәңге гөрләп торсын
Саба сабан туйлары!..

## БИЕКТАУ

*Р-гә*

Көтә һәм озата Биектау,
Рельсларда йөрәк кагышы.
Кемнеңдер еракка китеше,
Кемнеңдер еракка кайтышы.

Тимер юл буенда чәчкәләр
Сарылалар йомры тезләргә.
Салават күпере балкышы
Чылангач елмайган күзләрдә.

Узган гомеркәйләр — аккан су,
Ярга ташлап булмый сагышны.
Үзәкләрне өзә таңнарда,
Соңарган поездның чабышы.

Көтә һәм озата Биектау,
Рельсларда йөрәк тибеше.
Үзе бер моңлы җыр хушлашу,
Үзе бер матур җыр күрешү...

## АДАЙ

Адай урамында адаштырдың,
Кузгаттың да ташкын хисләрне.
Дисбе итеп тездем күңелемә
Без кавышкан айлы кичләрне.

Адай урамында абайладым
Зәңгәрлеген синең күзләрнең.
Ялкыннарга салды йөрәгемне
«Тик син генә» дигән сүзләрең.

Адай урамнары яшел чирәм,
Юлга түшәлгәне таш кына.
Минем күңелем һәр көн сине барлый,
Сине сагына, сиңа ашкына...

## МИҢГӘРЕМ

*Җ-кә*

Дөньяларны гиздем, илләр, җилләр күрдем,
Очрамады ишең-тиңнәрең.
Хәтфәдәй болыннар, талгын аккан сулар,
Йолдызлы серле төн синдә, Миңгәрем.

Кунак кызлар кулын ешрак кыстык микән,
Әллә нигә синнән кителде.
Гомерләр толымдай сүтелде-сүтелде,
Авылым-бәгърем, гафу ит инде.

Хәтфә болыныңда колыннардай үсеп,
Күпме бәйгеләрдә дан алдык.
Сабантуй әләме ак сөлге шикелле,
Җилфердек күңелле булып калалдык.

## АККОШ МИКӘН, ӘЛЛӘ СИН МИКӘН?

Якынайган саен ара ерак,
Син — зәңгәр күктәге ак болыт;
Йөзәсең омтылып, ә мин торам
Шул болытка карап, онытылып.

Болыт китте узып, ә күңелдә
Зәңгәр төндә купкан ак буран;
Буранга уралып бер биергә
Дәшкәнеңне көтеп мин торам.

Ак буранлы барыр юлларымда
Якты маяк булып балкыйсың;
Якынайган саен ара ерак,
Ераклашкан саен якынсың.

Тормыш — ярсу дәрья, ерак ярда
Аккош микән, әллә син микән?
Ак өметем минем, ак хыялым,
Дулкында тирбәлгән ак җилкән...

## АЛГА, ТАТАРСТАН ЯШЬЛӘРЕ!

Томырылып чаптың тулпарда,
Куш йөрәкле татар егете.
Тургай кебек кыйды күкләрне
Омтылышың, якты өметең.

Әй тургай, кечкенәм,
Күтәрел көч белән,
Иң якты җыр булып яңгыра!
Юылсын карашлар
Кояшлы яңгырда.

Син беренче идең бәйгедә,
Яшен ташы булып атылдың.
Дөнья сәхнәсен таган итеп,
Йолдызларга ашып атындың.

Әй тургай, кечкенәм,
Күтәрел көч белән,
Иң якты җыр булып яңгыра!
Таралсын сагышлар,
Кояшлы яңгырда.

Тургай күңлең ашты биеккә,
Сискәндерде яшен яшьнәве,
Безнең язмыш мәңге гарасат,
Каушама, татарым яшьләре.

Әй тургай, кечкенәм,
Күтәрел көч белән,
Алкыш ул яшеннәр яшьнәве!
Тик алга, гел алга,
Татарстан яшьләре!..

# ПРОЗА

## КӨЗНЕҢ ГАДӘТИ БЕР КӨНЕ

Дөбердәп ишек ачылды һәм укытучылар бүлмәсенә ике кеше килеп керде. Алар плащтан, эшләпәдән һәм саз ерудан олтаны калынайган пычрак күн итекләрдән иде.

— Нишләп утырасыз монда авыз ерып? — диде алдагы кара мыеклы, тәбәнәк, юан кеше. Ул, идәндә эре-эре эзләр калдырып, түргә, ян як стенадагы «Директор» дигән язулы ишеккә ыргылды. Юлдашы сүзсез генә аңа иярде. Ул ишек тоткасын ике кат йолыкты. — Кайда директор?

— Иртән ронога дип китте, кайтышлый басуга да сугылырмын дигән иде.

— Басуга сугылырга кирәкми, эшләргә кирәк анда, сеңелкәем. Бөтен составны бәрәңгегә мобилизовать итәргә, диелде. Почему үтәмисез? Ә? Замы бармы аның берәр? Завуч бармы?

— Мин булам, Нуриәхмәт Зиннурович, — диде Мәрзия Әгълиевна, урыныннан корт чаккандай чәчрәп торып басып.

— Йә, сайрап җибәр, — диде Нуриәхмәт Зиннурович, завучның бер чеметем борынына, җыерчыклы тар маңгаена текәлеп, һәм теш арасыннан гына: — Ханым... — дип өстәде.

— Мин директорга җиткердем, ләкин ул үзенчә хәл итте, күрәсең...

Яшь укытучы Һашим Мәрзия ханымга карап күзләрен челт-мелт йомгалады да җәһәт кенә урыныннан торып:

— Югары класслар шунда, Нуриәхмәт Зиннурович, түбән класслар да атна буе эшләделәр, ничәсе чирләп больницага керде, — дип ашыга-кабалана тезеп китте.

— Тукта! — дип бүлдерде аны Нуриәхмәт Зиннурович, сөмсере коелып. — Гыйниятов, — диде ул, юлдашына ым кагып, — кара әле бу Түләшкә батырына. Син нәрсә, — диде ул Һашимга бәләкәй күзләре белән тишәрдәй итеп кадалып. — Нәрсә син ат дагалаганда ботыңны кыстырасың? Ә? Дезорганизация таратып! Алайса, без әйтербез. Безгә ак перчаткалы укытучылар түгел, ә народный укытучылар кирәк диярбез, халык арасында йөри торган. Кара син аны! Үкчәле туфлиләр киеп, галстуклар тагып, чалбар төбе шомартып утырасыз. Ә без саз ерып йөрергә тиеш.

Сөйләгән чакта, ара-тирә акселераторга баскач, үкереп-үкереп куйган машина моторы сыман, Нуриәхмәт Зиннурович та вакыт-вакыт тавышын көчәйтеп-көчәйтеп җибәрә иде. Ул пычрак итекләренә ялт кына карап алды да юлдашына борылды.

— Боларга бәрәңге кирәк түгел, Гыйниятов. — Нуриәхмәт Зиннурович, күзләрен әрле-бирле йөртеп, каһәрле карашы белән берара бүлмәдәгеләрне ашады.

Һашимның куллары салынды, башы иелде, ялганчы чокыры йодрык сыярлык булып тирәнәйде.

— Юк, син кем булдың соң әле безне өйрәтергә? — диде Нуриәхмәт Зиннурович бүртенеп һәм җөмләсен берничә хәтәр сүз белән җилемләп тә куйды.

Риза Сафичның урындыгы шыгырдап куйды.

— Сез мәктәп дигән изге йортка сүгенергә килдегезме? — диде ул саңгырау тавыш белән.

Нуриәхмәт Зиннурович песи баласыныкыдай тере, нәни түгәрәк күзләрен Риза Сафичка текәде.

— Изге йорт, имеш, — диде ул, иреннәрен ямьшәйтеп. — Бардак сезнең монда, понимаешь. Энәдән-җептән киенеп, чалбар төбе шомартып утырасыз. Балаларыгыз чыр-чу килеп тәккә чабып йөри. Ике имгәге юлга аркылы төшеп тора бит әле, аягыгыздан салыгыз, дип. Ә бит оялмыйсыз! Аларны басуга чыгарсак, илгә файда килер дип куркасызмы? Сабатажниклар сез! Янгыр ява анда: кала, чери бәрәңге...

Риза Сафичның җыерчыклары тирәнәйде, күзләре урынында ярыклар гына калды. Кинәт аның кылт итеп исенә төште: мондый сөйләшү бер булган иде инде. Күптән, байтак еллар элек булган иде. Шул ерак чорда менә шушы Нуриәхмәт кәнәфиен биләгән Камалетдинов дигән бәндә, исеме аның Әләметдин иде, укытучыларның матур киенгән булуларын, балаларның эш барышында куышып китеп уйнап алуларын ошатмыйча, бузарынып җикеренгән иде. Әйе, әйе, көз иде, мәктәп балалары белән колхоз бәрәңгесе алырга чыкканнар иде... Камалетдинов ишеләргә бернинди дәлил дә тәэсир итмәячәген белгәнгә күрә, Риза Сафич тәртәне зиректән бөгәргә булды.

— Сезгә безнең матур киенүебез ошамый, — диде ул нәфрәт белән. Аннары: — Балаларыбызның шатланып уйнап көлүләрен ошатмыйсыз, — дип дәвам итте. — Бар иде инде ул андый берәү... — Риза Сафич, Камалетдиновның шешенке күзләренә күзен текәп, бермәл дәшми торды, аннары салмак кына теш арасыннан сыгып: — Гитлер иде ул. Без аны өненә барып дөмектереп кайттык, — дип өстәде...

Мәктәп директорлыгыннан кайчандыр әнә шулай очкан иде Риза абзагыз... һәм менә каршыда тагын бер Әләметдин тора...

— Ә сез ояласызмы соң?

— Без нәрсәдән оялырга тиеш әле? Дәүләт планнарын хәл иткән өченме?

— Оккупантларча кылануыгыздан. — Риза Сафич Нуриәхмәт Зиннуровичны баштанаяк, мөхтәрәм күренер өчен водород перекисе белән көмешләндерелгән бер тотам чәченнән алып, пычрак күн итекләренәчә күздән кичерде. — Ә планнар хәл итүгә килсәк, — диде ул тыныч кына, — хәбәрдарбыз. Ит планын туберкулезлы сыерлар тапшырып, сөт планын Башкортстан һәм Круглое поле базасы атланмаен сатып алып, шуны кабат тапшырып үтисез. Ә яшелчәне тагын да кызык юл белән үтисез. «Үзәк» совхозы азык кишерен райпога тапшыра, аны икенче хуҗалык сатып ала да... хөкүмәткә илтә. Әллә дөрес түгелме? Йон белән балны бодайга алмашка башка районнардан җыйныйсыз. Бәрәңге белән чөгендер планын да үтәүнең җаен беләсез.

— Син шулай материал туплау белән дә шөгыльләнәсеңмени әле? — дип үкерде Нуриәхмәт Зиннурович, кара коелып. — Әллә андый һөнәрең дә бармы?

Әңгәмәгә Мәрзия ханым ачыклык кертәсе итте.

— Аның янына элекке укучылары кереп йөри, — диде ул. — Кайсы бухгалтер, кайсы инженер, милиционерына кадәр бар. Шулар гайбәтен сөйли булыр.

— Йә, йә. Бәрәңге белән чөгендер проблемасын хәл итү ничек эшләнә?

— Җәй буе басудан кайтып кермәгән балаларны, укытучыларны, укуларны өзеп, тагын да басуга куып чыгару юлы белән.

— Эшләгәннәре әллә минем өченме? Үзләре өчен, үзләре яшәгән колхоз өчен, үзләре яшәгән район өчен!

— Һәм колхоз җитәкчеләре, белгечләре, бер көтү роно сорыкортлары, тагын басуга килеп тә карамаган әллә кемнәр бүләк алсын өчен. Әйтерең бармы. «Маяк» колхозы председателе җәйнең җәй буена без эшкәрткән, көз җиткәч, берәмтекләп, саздан арындырып, сабагын кисеп, шәһәрдән килгән машиналарга без төяп озаткан шикәр чөгендере өчен ике мең ярым сум премия ала. Ә ел азагында ялганлап үтәлгән барлык төр планнар өчен аңа тагын мең тугыз йөз алтмыш сум бүләк. Хәтта колхоз конторасы җыештыручыга да, план үтәлгән өчен дип, өч йөз җитмеш сум өлеш чыга.

— Колхозчылар эшләми дисеңмени инде син?

— Алар басуда күренмиләр.

— Ә бригадирлар, звеноводлар, бригадир ярдәмчеләре? Алар да күренми что ли?

— Бригадир ярдәмчесеме? — диде Риза Сафич, җене чыгып, — рәхим итте бер тапкыр. Иелеп бәрәңге чүпләгәндә борын төбемдә күн итекләр күреп күтәрелеп карасам, күрәм, өч класс белемле бригадир ярдәмчесе Хәсәнша рәхим иткән икән, рәхмәт яугыры. Балчыкка типкәли торгач, ике бәрәңге казып чыгарды бу. Минем биткә туфрак чәчрәтүенә исе китмәде моның, бәрәңгеләрне иелеп алып чиләккә салу да уенда юк. Күн итеге очы белән күрсәтә миңа Хәсәнша: «Күзең чыккан мәллә, нәрсә калдырасың?» — янәсе.

— Сиңа нәрсә, акча кирәкме? Нигә сөйлисең бу экиятләрне? Безгә аңлашылмый. Син аңлыйсыңмы берәр нәрсә, иптәш Гыйниятов?

Басыйр Гыйниятович, «юк» дигәнне аңлатып, башын чайкады.

Риза Сафич, бармаклары белән аралап, чәчен артка сыпырды.

— Сез мине үзегез белән бутамагыз: хе-хе-хе... Мин бераз мәктәп өчен өмет итеп кенә. Балалар эшләгәннең чирege күләмендә булса да. Сер түгел, елның елында йә күмер бетеп, йә торба ярылып яртышар кыш мәктәп җылытылмый. Җылыту системасы череп беткән, ә балалар туңа, чир ала.

— Мәктәбегезне без килеп җылытып биргәнне көтәсезмени әле сез? Ансат! Ха! Сезнең бит директорыгыз бар. Әйтегез аңа, җылытсын. Шуның өчен ул акча ала.

— Акча ала, дисез. Нигә соң алай булгач үзегез ярдәм кулы сузмыйсыз?! Балалар хезмәте түгеп килгән ул хәрам премияләрдән сез дә өлешсез калмыйсыз түгелме соң?

Нуриәхмәт Зиннурович үзе дә сизмәстән ике адым артка чикте һәм бер адым алга атлап куйды. Юлдашы да ни өчендер шул хәрәкәтләрне кабатлады.

— Ремонт турында, — диде Нуриәхмәт Зиннурович, карлыгып китеп, һәм бер кулы белән галстугын бушата-бушата: — Директорыгызга әйтегез, мәсьәләне кабыргасы белән куйсын. Җыламаган балага имезлек каптырмыйлар, әйе, чишәрбез. Ә премия хакында, агай кеше, үзегез белмәгәнне лыгырдамаска кирәк. Ә сез, иптәш завуч...

— Тыңлыйм, Нуриәхмәт Зиннурович.

— Кемнәр килеп йөри бу картка, списогын төзеп минем секретарьга төшер.

— Ярар, Нуриәхмәт Зиннурович, ярар!

— Менә шул... Стоп. Тукта әле. Сиңа ничә яшь?

— Миңа?

— Сиңа, сиңа. Нигә шүре җибәрдең? — Нуриәхмәт Зиннурович мыскыллы көлемсерәп куйды: — Сиңа!!!

— Алтмыш өч, шуннан ни диярсез?— диде Риза Сафич, каушый төшеп.

— Ах, алтмыш өчмени? — дип сузды Нуриәхмәт Зиннурович, ияген чайкый-чайкый. — Син кайчанга кадәр яшь буынны бозарга җыенасың инде? Ә! Гыйниятов, — диде ул, юлдашына ымлап. — Менә син төзүче кеше, әйт, канализация торбасына берәр сүсәргән чүпрәк яисә иске мунчала тыгылса, шакшы су өскә чыгамы?

Гыйниятов, «әйе» дигәнне аңлатып, ияк какты.

— Аны ыргаклы колга төшереп тартып чыгаралар, шуннан агым дәвам итә, тәк?

Гыйниятов янә җитез генә ияк какты.

Нуриәхмәт Зиннурович Риза Сафичка борылды.

— Синең ишеләрне йолкып чыгарырга ыргаклы колга табылмас дисеңме? — дип ысылдады ул. — Ә застой каян килеп чыктымы? Синдәй һава бозучылар күбәйгәнгә ясалды ул. Яхшы чакта үкчәңне ялтырату ягын кара. Без перестройка язмышы белән шаяра алмыйбыз! Балалар безнең киләчәгебез һәм киләчәгебезне бозарга юл куймабыз. Не позволим!..

Эшләпәлеләр чыгу ягына атладылар. Өч-дүрт адым киткәч, Нуриәхмәт Зиннурович, Гыйниятовка ияргән Мәрзия ханымның уңайсызланып елмайган йөзен күреп, янә туктады.

— Кайту белән шалтыратсын, — диде ул, директор ишегенә ымлап. — Давай, үзегезгә бирелгән участокны до ума доводить итеп бетерегез. Аңладыңмы?

— Аңладым. Җиткерермен, Нуриәхмәт Зиннурович... Карагыз әле, Нуриәхмәт Зиннурович, беләсезме...

— Тагын нәрсәләр бар?

— Карт өчен, зинһар, гафу итегез инде... Шариклары да бушый башлады, хи-хи-хи, картайды. — Бүлмәдә чукраклар юк иде. Тавышын әкренәйтсә дә, һәркемгә ишетелерлек итеп сөйләде Мәрзия ханым... — Яшьлегенә кайтырга ярата, сугышта йөргәннәре белән кизәнгәли... Ничек диләр әле... Эт картайса, койрыгын сөйрәр, кеше картайса, үткәнен сөйләр, диләрме? Хи-хи-хи...

— Хм. Зарар юк. — Нуриәхмәт Зиннурович, укытучы халкын сискәндерерлек итеп, тамак кырып куйды. — Бугаз киерүчеләрне чат саен очратып торабыз. Теләсә кайсы коридорда хәзер шундый үпкәчеләр мыжгый.

Нуриәхмәт Зиннурович көлемсерәп куйды, галстугын төзәтте, бүлмәдәгеләргә күз кысты һәм чыгу ягына атлады. Аңа Басыйр Гыйниятович иярде. Мәрзия ханым да бөгелә-сыгыла эшләпәлеләр артыннан кузгалды. Шып туктап калуына борыны төбендә дөбердәп ябылган ишек сәбәпче булды. Ул, аптырап, як-ягына каранды, бер урында таптанып калды, тирән итеп бер көрсенде һәм мәченекедәй тавышсыз адымнары белән үз өстәленә таба юыртты.

— Басыйр Гыйниятовичы нишләп йөри икән? — дип куйды физика укытучысы Гөлзар ханым, идәндә ярылып яткан пычрак эзләрне сагышлы күзәтеп. — Бер сүз эндәшмәде.

— Кем белгән аларныкын. Безгә караңгы, — дип куйды тарихчы.

— Ә мин беләм, — диде Һашим.

— Әйт белгәч.

— Басыйр Гыйниятович бәләкәй кеше түгел. Шуңа Нуриәхмәт Зиннуровичка тагылган да. — Һашим Мәрзия ханымга шомланып кына күз төшереп алды һәм кулларын җәеп җибәрде: — Бәләкәй койрык тагып йөри алмый ич инде ул.

Пырхылдап көлеп җибәрделәр. Бүлмә эче ничектер яктырып киткәндәй булды.

— Ә нигә соң ул койрык? — дип кызыксынды Алсу исемле яшь укытучы кыз.

— Болгап йөрергә. Әйтик, патшаларга яраннары ияреп йөргән. Хәзерге түрәләргә актив иярә. Магазин төбеннән китмәүче, киң профильле сәрхуш Әхмүшнең дә койрыгы бар. Үзеннән дә аламарак иярченнәр табып тора.

— Ә бәлки койрыкка омтылыш табигыйдер, ансыз булмыйдыр бу дөньяда?

— Кем белә, — диде Һашим, теш төбен суырып, — кешене кеше эксплуатацияләүне бездә бетте, диләр. Ә менә берәүнең икенче берәүне койрык итеп тагуына каршы бернинди чикләү дә, чара да юк.

Кыңгырау шалтырап, әңгәмәне өзде. Укытучылар, уртак киштәдән класс журналларын алып, классларга ашыктылар. Риза Сафич та, урыныннан торып, протезларын шыгырдата-шыгырдата тәрәзәгә таба китте. Хәзер аның буш дәресе. Буш дәрес булуы әйбәт әле, чөнки кинәт кенә башы шаулый башлады, зиһене таралыбрак тора, нәрсә дә булса уйлап китү өчен фикер җебенең очы табылмый... Туктале... Нәрсә дә булса уйларга кирәк бит инде. Нәрсә турында булса да эзлекле фикер йөртергә...

«Ә бәлки Һашимның эт, койрык, дип чагыштыруы уңышсыздыр, — дигән уй кабынып узды аның миен көйдереп. Риза Сафич, шушы фикергә тотынып, аны эзлекле дәвам итеп карамакчы булды. — Кем инде ул Гыйниятов олы койрык саналырга?.. Гап-гади йолкынып беткән төзелеш оешмасының сүгенеп сөйләшә торган бер башлыгы».

Тәрәзәдән кыеклап яңгыр яуганы күренә. «УАЗ» машинасы бата-чума кап-кара басу уртасыннан каядыр шуыша.

«Хикмәт, — дип көрсенеп уйланды Риза Сафич, — урманда җәнлек, авылда кеше кими. Кеше җитми... Беркайда һәм беркайчан да җитми... Кеше һәм җәнлек... Ә бит кешеләрдән барлык төр җәнлек сыйфатларын табарга мөмкин. Кемдә попугайлык көчле, кемдә төлкелек, сарыклык, куянлык, еланлык, ишәклек, бөркетлек... Саный китсәң... Шулай булмаса, аны табигатьнең таҗы, димәсләр иде. Ә шулай да кешегә иң якыны — эт.

...Этләр, этләр... Зурлар, бәләкәйләр... Менә зур эт. Ул әллә нигә бер генә өрә. Кирәк санаса, умыра, санамаса, сине күрми ары китә. Ә бәләкәе чиный, тузан туздыра. Кусаң, чигенә-чигенә өрә. Китеп барсаң, өрә-өрә ияргә. Әйтик, мәктәпкә олырак урыннан зыялырак берәү килә, мәһабәтлек саклап сөйләшә һәм итагатьле генә саубуллашып кайтып китә. Шундый вәкаләт йөкләп җибәрсәләр, кемне дә булса эшеннән бушатуы да мөмкин. Ләкин шау-шусыз гына, иплəп. Менә берзаман ранодан бер сары томшыклы, яисә министрлыктан бер сырты саргайганы рәхим итә. Болар йә бөтенләй укытмаган бу эшкә сәләтсез кешеләр, яки, укыту эшеннән качып, җылы оя табучылардан. Укыта белмәсәләр дә, өйрәтергә кодрәтләреннән килә. Аптырап тормасыннар өчен аларга берише калып тоттырып җибәргәннәр. Шул калыпка салып әлеге Мокытдисәме, Мөкәтдисәме, яки сылу җегет Мостафа, арт чүмеченә бозау аягы, синең хезмәтеңне үлчи. Сыйган өлешен мактый, сыймаган турын хурлый. Педсовет җыйдыра, шау-шу кубара. Макаренко, Сухомлинскийдан өзекләр китерә-китерә үгет-нәсихәт укый, тәнкыйть чәпчерәтә. Асылда, берни үзгәрми, ә күпмегәдер зиһен чуала, чәч агара...

Әле узган ел шундый бер тикшерүче мәктәпкә килеп кергәндә, җыештыручы Шәргыяне очрата һәм сүз куша:

— Сез мәктәптә эшлисезме? — дип кызыксына ул.

— Әһе, — дип җавап бирә Шәргыя.

— Берәр телдән керәсезме?

— Керәм, — ди Шәргыя, — себерке теленнән.

Әһ-һәй! Тикшерүчеләребезнең күпчелеге педагогика хакында түгел, ә чисталык турында озаклап сүз боткасы куертырга ярата. Чөнки бу хакта әңгәмә кору өчен белем дәрәҗәң, эш тәҗрибәң «себерке теленнән» керүче Шәргыянекенә тигез булса да бик җитә. Һей! Теләсә кем югары үрмәли хәзер, һәм бу бик зур бәла. Күтәрелү өчен әллә ни белем дә, зыялылык та кирәкми. Укымышлы кешеләрдән дә үрнәк алу кирәкмәс. Үрнәк алу өчен әнә Акбай да җитә. Югарылар каршында арт тәпиләренә басып, койрык болгарга, түбәндәгеләргә селәгәенә тончыга-тончыга сүгенергә өйрәнсәң, күпкә ирешергә мөмкин... «УАЗ» машинасы һаман күренә, сул күз әйбәт әле, шөкер... Пычрактан бик барып булмый шул. Белоруссия урманнарында саз ерып ничә чакрым үтелде икән? Колак төбендә ядрәләр сызгырганы, якында гына этләр өргән чаклар... Нәселле, хуҗаларның төп сыйфатларын яхшы үзләштергән, зур этләр...»

Кинәт Риза Сафичның тыны кысылды, күкрәге чәнчеште һәм ул, өстәлләргә тотына-тотына чигенеп, терәкле урындыкка ишелеп төште.

— Журнал буталган икән, — дип кабаланып ишектән Һашим килеп керде. — Кара әле, монда да юк. Риза Сафич, өченче «Б» журналын күрмәдегезме?

Җавап булмагач, ул бүлмә уртасында туктап калды. Шунда гына Риза Сафичның сәер кыяфәттә урындыкка чүмәшкәнен күреп алды. Ул, иелеп, карт остазының йөзенә карады, кулын тотты. Сөякчел, ябык куллар сап-салкын иде...

## УЙНА, ГАРМУН!

Түш кесәмнән кичәге хатны алам. Сүзләр. Хәрефләр... Аларны, кулъяулык чиккәндәй матур итеп, Дания тезгән:

*«...Исәнме, Айдар! Сиңа сагынычлы күп сәламнәр белән... Рәсемең өчен рәхмәт. Чын солдатка охшый башлагансың... Беренче курсны әйбәт кенә тәмамладым. Практикага үзебезнең районга кайту насыйп булмады. Каядыр Себер ягына озаталар.*

*Авылда сабан туйлары узды да китте. Быел аны бигрәк иртә ясадылар. Беләсеңме, Айдар, мин ел саен сабан туен шундый көтеп алам, ул гел мин көткәнчә булмый. Атта да чабышмадылар быел...»*

Хаттан аерылам. Сабан туе... сабан туе инде ул! Их...

Чуп-чуар, гөж килеп чайкалып торган халык диңгезе уртасында утрау кебек түгәрәк мәйдан. Көндәшеңнең билен өзеп чыгарырга җитешеп кысасың, каезлыйсың, тартышасың. Сөлгеләр күзгә күренеп тузалар. А, ул көндәге мәйдан! Син гүя оча торган тылсымлы палас өстендә. Зәңгәрлектә йөзгән ак болытлар йә кисәк аска төшеп югалалар, йә тургайлардай биеклеккә чөеләләр. Кайдадыр гармунда өзәләр, өзәләр...

Колакка чыңлап торган гармун тавышы ишетелгәч, мин аптырап торып утырдым. Кичә авторотаныкылар корган палаткалар артындагы урман авызыннан, дөрестән дә, моң агыла. Ул моң чиксез иде. Мин эсселе-суыклы булып киттем. Көй саф татарча! Тордым да йөгердем.

Чәчәкле алан түрендә, кояш чыгышына таба авышып үскән каен төбендә какча йөзле, кара гына яшь солдат утыра. Аңа кара-каршы өчпочмак ясап, ак панама кигән, җете кара күзле бәләкәй бер малай чүгәләгән һәм чалбарына караганда, офицер булырга тиешле ир уртасы агай сузылып ятып тора. Урталыкта — гөмбә тулы тырыс. Малай, дөньясын онытып, гөмбәләр белән мәш килә. Берәм-берәм кулына алып тирбәтеп тора, иснәп карый, чагыштыра.

Гармунчы солдат, мине күреп, баш кагып куйды. Көйгә зыян китерергә куркып, аяк очларыма баса-баса, аның янына елыштым. Офицер барлыгымны бөтенләй искәрмәде. Ул башын кыңгыр салган да, күзләрен бер ноктага төбәп, оеп калган. Гармун моңы аны, бәлки, туган төбәгенә үк күтәреп алып кайтып киткәндер. Бәлки, ул яшь егет булып, беренче ярының яран, тамчы гөлле тәрәзәсе төбендә басып торадыр... Бәлки...

Ул, калтыранып, башын кисәк кенә артка ташлады. Аның яшьләнеп-ялтырап киткән күзләренә малай хәвефләнеп карап куйды. Барып беләгенә сарылды.

— Пап, посли...

Офицер, сүзсез генә борылып, улының саргылт чәченнән сыйпады, күтәреп алдына утыртты.

— Татарча көй бу, улым, — диде ул, бугазына бөялгән төерне көч-хәл белән йотып җибәреп, — тыңла әле.

Малай, аркылы-торкылы килеп, аның кочагыннан шуып чыкты һәм аяк терәп кырыйга, читкә сөйри башлады.

— Ну засем тебе таталски, — диде ул, өзгәләнеп. — Там зе мамка здет, сего расселся!

Малай, әтисенең кымшанмавын күреп, рәнҗеп беркавым сулышына буылып торды. Аннары үтә нәзек, нечкә тавыш чыгарып сулыгып-сулыгып елый башлады.

Көй өзелде. Офицер икебезгә берьюлы каушаган караш ташлады, елмайгандай итеп, авызын кыйшайтты, төкереген йотып куйды.

Тырысын кулына алды, малаен җитәкләде һәм ашыга-ашыга китеп барды.

Без аларны күмелгәнче карап озаттык.

— Эссе бүген, — дип куйды гармунчы якташым сүрән генә. — Их, хәзер авылга кайтып, башны чишмә улагы астына куясы иде!

— Дус, агайне, уйна әле, уйна әле «Фазыл чишмәсен!» — дидем мин.

Якташымның уйчанланып калган йөзендә елмаю чаткысы пәйда булды. Һәм кабат кулына гармунын алды...

Елга агышы сыман талгын башланып киткән көй кызуланганнан-кызуланды, нәфисләнде, нәкышләнде һәм, чын чишмә җырына әверелеп, чылтырап ага башлады.

## ӘЛӘМЕТДИН

Кабинет ишеген кашыган сымак иттеләр.

— Керегез, — диде участок инспекторы Фәнис Хөснетдинов, яза башлаган кәгазь битенең чиста ягын әйләндереп.

Ишектә — йөзе имән кайрысыдай кара-кучкыл җыерчыклы, мәһабәт гәүдәле, өстенә кояштан уңып агарып беткән кожан, башына галәмәт дәү төлке бүрек, аякларына кирза итек кигән берәү күренде. Ул сәлам бирми генә бусагадан үтте, идән-түшәм, стеналарга күз йөртеп чыкты, Хөснетдиновка ниндидер авыр караш белән бермәл текәлеп торды, һәм көтмәгәндә атныкыдай эре, сары тешләрен күрсәтеп елмаеп җибәрде.

— Нихәл, энем, — диде ул, көрәктәй кулын Фәнискә сузып. — Әйләндерәбезме?

Хөснетдинов сузылган кулның бармак очларыннан шикләнеп кенә кысты, миенең бер почмагын «әллә юләр микән бу?» дигән шөбһәле уй көйдереп узды. Чөнки кыш бетмәгән әле, яз җитмәгән дигәндәй, агайның өс-башы сезонга туры килми иде, шуның өстенә кием-салымы артык алама иде.

— Синмени инде безнең яңа участковый? — диде агай, көләчләнгәннән-көләчләнә барып. — Рәхмәт, рәхмәт. Авыл советы почмак та биргән икән үзеңә. — Ул җиһазы бер өстәл һәм ике урындыктан торган нәни бүлмәне җентекләп күзәтте: — Бүтән җирдә дә шушылай кабинетларың бармы, әллә безнекеләр генә шулай милициягә ялагайланамы?

— Минем участокка кергән барлык авыл советларына да юмартланырга туры килде, — диде Фәнис, һаваланыбрак.

— Рәхмәт, рәхмәт, — дип кабатлады карт, дәү бүрекле башын селкеткәләп. — Молодец.

— Йомышларыгызны сөйләп җибәрегез, — диде Фәнис, елмаеп. — Басып тормагыз, абзый, утырыгыз.

Карт тәкъдим ителгән урындыкка утырып кына калмыйча, кесәсеннән папирос чыгарып, кабызып ук җибәрде.

— Мин, энем, — диде ул, тәмәкесен тәмләп пошкытып, — Әләметдин Йосыпов булам. Чакырткан икәнсең.

Фәниснең йөзендәге елмаю чаткысы сипкелләре арасыннан адашып юк булдылар. Яңак мускуллары бүлтәеп чыкты һәм тартышып куйгандай иттеләр.

— Сезмени инде ул шырпы белән шаяра торган сакаллы сабый? — диде участок инспекторы, тешен кысып. — Сүндер хәзер үк папиросыңны! Пож-жарник...

— Кызма, энекәш, — диде карт, папиросының утлы башына төкергәли-төкергәли. — Чәчелмә... кәҗә тизәге... тфү... шикелле. Рәтле сүзең теф-теф... бар икән — сөйлә, юк икән, теф, тоткарлама. Осиновкага барышым, караңгы төшкәнче барып җитәсем бар.

Фәнис, ирен читен тешләп, пианино уйнагандагы сыман өстәл өстендә бармакларын биетеп алды... Тагын биетте.

— Карале, абзый, — диде ул, ниһаять, һәм озак кына авызын зур ачып, иснәгән атлы булып кыланды. — Син болай ниме соң? — Фәнис, серле генә елмаеп, өстәлгә шакып куйды. — Мин әйтәм, кечкенә чагында өстәл-мазардан егылып төшмәгән идеңме?.. Алай-болай больницада учетта тормыйсыңдыр бит?!

Соңгы иҗекне әйткәндә, Фәнис, авызын каплый төшеп, тагын иснәгәндәй итте.

Карт урынында кыбырсып куйды, күзләре кысыла төште, яссы ияге алга омтылды.

— Мин дурак булсам... — диде ул, үртәлүдән калтыравыкланып киткән тавыш белән. — Мин дурак, фәләненче елдан бирле булнистә учетта торам дияргә тиешмени инде? Нәрсәгә дип мыскыл итәсең әле мине, энекәш? Ни хакың бар алай эшләргә?

— Юкка борчыласыз, — диде Фәнис, елмая төшеп. — Сезне мыскыл итү теләгем юк. Эш шунда: сукырга суд юк дигәндәй, җүләрләр өчен закон язылмаган. Мин бик шат сезнең акыллы булып чыгуыгызга. Эһм! Моның белән сезне тәбрик итәсе дә килә хәтта.

Участок инспекторының йөзендә балкыган елмаю сүздән-сүзгә сүрелә, ә тавышында кырыслык чаткылары ешрак сизелә иде.

— Димәк, сезнең белән психиатр түгел, ә мин шөгыльләнергә тиеш булам. Ярый. Инде алай булгач, сезгә бер сорау... Тәк... Сорау...

— Бирсәң бир соравыңны, интектермә.

— Сорау шундый... Нигә дип син, карт алаша, башта улыңны гаиләсе белән төп нигезгә сыйдырмыйча сөреп чыгарасың, аларга колхоз квартира биргәч, килеп бимазалыйсың, и, ахыр килеп, әйберләренә, урамга чыгарып атып, ут төртәсең?!

— Ә синең нинди фактларың бар соң? — диде карт, зәһәр көлемсерәп. — Кем хатыны ялганлады бу әкиятне сиңа? Нәрсәгә дип ул кадәр кәҗә тизәге шикелле чәчеләсеңдер — аңламыйм.

Фәниснең муен тамырлары бүртеп чыкты. Ул, кабаланып, өстәл тартмасыннан берничә кәгазь бите тартып чыгарды.

— Гафу итегез, иптәш Йосыпов, — диде инспектор, мөмкин кадәр сүзләрен салмак әйтергә тырышып, ә бу аңа бик авыр бирелде. — Менә киленегездән кергән гариза. Монысы — улыгызның аңлатмасы.

Әләметдин карт кәгазьләргә күз дә салмады.

— Яла бу, энекәш, — диде әллә ни исе китми генә. — Пычрак яла. Ә яла якканга закон бар. Хе-хе-хе. Пракарурга кичә үк илтеп кайтты инде Әләметдин бабаң сәлам хатын. Синең өстән дә юллый белербез, алай белер-белмәс кәҗә тизәге кебек чәчелә торган булсаң.

Фәнис тир бәреп чыккан маңгаен кызарганчы кулъяулык белән ышкып корытты. Аннары, читеннән чеметеп тотып, тагын бер кәгазь битен Әләметдин агайның ямьшек дәү борынына якын китерде.

— Менә бу сиңа авыл советы биргән характеристика. Нәрсә язылган анда?

— Мин күзлексез күреп бетермим, — диде Әләметдин карт, кесәләрен капшаштырып.

— Үзеңнең кем икәнеңне белү өчен күзлек кирәк микән соң ул? — диде Фәнис, кәгазьләрен җыештырып. — Авылыгызда байтак кеше белән сөйләштем, абзый, сине мактаучы табылмады.

Әләметдин карт авызын зур ачып катып калды. Аннары буыла-буыла көләргә тотынды. Онытылып ютәлли-ютәлли көлгәндә, алынма теш казнасын авызыннан чүт кенә төшереп җибәрмәде.

— Хы, мактамыйлар диген, — диде ул, теш казнасын дәү теле белән уңайлый-уңайлый. — Хе-хе. — Әләметдин карт Хөснетдиновның күзләренә чекерәеп, кадалып карады, ияген чайкап куйды. — Мактамыйлар, имеш... Дөресен әйтеп сөйлә, энекәш, яратмыйлар, диген. Җирәнәләр, дип җиффәр! Дошман күрәләр, диген. Сине монда шыртлатсаң да, кәкәй итте диярләр, диген. Шул башың белән участковый белән телләшеп торасың, адәм тәганәсе, дип, өстәл сук. Җебек булма! Моны мин как коллега буларак әйтәм! Ничава... Син яшь әле, үрәнерсең безнең ишеләрне генә бөгәргә. Дөнья үрәтә ул...

— Ничек... коллега? Әллә төш күрә башладыңмы? — диде Фәнис, көләргә тырышып.

— Көлмә, энем, көлмә, — диде Әләметдин карт коры гына. — Иң авыр сугыш елларында эшләдем мин, энем, бу системада. Авылның җүләр мокытлары дошман күргәнгә, син мине әшәке кеше дип уйлыйсыңдыр инде. Ну, син, ялгышасың. Үзең берәр чатаклык чыгып, погоныңнан колак кагып кара, белерсең аннары. Әллә сиңа сәлам бирергә ашкынып торучылар булыр дип уйлыйсыңмы? Күпме кешене җавапка тартырга туры килә иде. Елдан-ел андыйлар ишәя бара иде. Ә аларның туган-тумачалары, дус-ишләре нишли дисең?.. Әллә алар, безнең фәлән кешебезне туры юлга чыгардың лабаса дип, синең алда сәҗдә кылырлар дип беләсеңме?! Саташма. Эхе-хей... Вот, яшәп кара гомерең буе дошманнарың чолганышында. Бүтән оешмада эшләгән кешеләргә коллективтан матди ярдәм дә килә, хәлен дә белеп торалар.

— Ә сез нишлисез?! Син менә карт ветеранны утыртырга мәтәләнәсең. Кеше булыгыз бәләкәй генә.

— Гафу итегез, Әләметдин ага, сез бит ветераннар исемлегендә тормыйсыз ...

— Тормаса соң. Мин алты гына ел эшләдем сездә. Әллә бу азмы? Күпме судьба узды минем кулдан шушы гомер эчендә. Бу системада алты көн эшләгән кешенең дә хәлен белергә кирәк. Ә мин алты ел эшләдем. Бер чатаклык килеп чыккан иде, сразу кудылар. Менә хәзер үзең уйлап кара, нишләргә тиеш инде мин. Мин каракларны заманасында пачкалап озаткан кеше, бер уч бодай өчен «урлап» китә идем, хәзерге сплошной бурлыкка ничек чыдарга кирәк, ә? Чит кеше урлашканга түздең дә ди. Ә үз малаең әрләнгә әйләнсә? Килен нәрсә ди бит: карт, син тик кенә тор, сиңа кайтып ава, имеш. Аумый гына торсын әле! Бөтен авыл урлашканда, болар ничек урлашмый яши алсын ди. Чыдый алмыйча тавышланып чыгып киттеләр төп йорттан. Ә мин куганга түгел. Хәзер колхоз фатирына урнашып алдылар, кинәнәләр колхоз малын ташып. Юк, мин курыкмыйм. Яктым! Урлап җыйган хәрам маллар алар! Янсын. Урамда түгел, ишегалдында яктым. Берәү дә күрмәде. Шаһитларыгыз юк. Не докажете. Тагы ягачакмын. Авылын ут төртеп яндырмагана рәхмәт укысыннар, җыен карак, җыен сволочь... Әле дә шунысына сөенәм, ичмаса, кулда власть барда үкенечен калдырмадым. Иске зданиегезне беләсеңме? Хәзер архив анда. Кирле-морлы сөйләшүчеләрне шуның подвалына аптөшеп яра идек! — Әләметдин карт, бала башыдай йодрыкларын йомарлап, Фәнискә акаеп карады. Фәнис аның акылы камил булуына тагын шикләнә башлады. — Ефәккә әйләнә торганнар иде! Ә күпме преступникны ташыдым мин Арча стансасына. Тәртәгә тагам да йөгерттерәм. Кем ялкаулана, чыбыркы җидедән үрүле, очында ат кылы, җылан кебек чагып ала торган! Вәт шулай, энем... Укытып күрсәттем мин кое-кому әлхәм сүрәләрен...

— Син шәп кешедер дә, Әләметдин агай, ә бу учак яккан өчен бер дә чарасыз, дөм буш калдырып булмый бит бу рәсми гаризаны...

— Маташма. Пычранма, энем. Әйдә, лучше кулга-кул тотынып эшлик. Менә син, матур фуражкаңны киеп, куеныңа пистолет тыгып, кылыч асып килдең ди авылга. Тота аласыңмы болай каракларны. Юк! Син аның кем икәнен дә белмисең. Каракны аны сиңа менә мин тотып бирәм. Чөнки мин төнлә йөрергә яратам. Кемнәр йокламаганын күреп йөрим... Йә булмаса, әнә Ямбулатка барсаң, ул да синең участокка керә бит?

— Әйе.

— Анда бер Кәшипов дигән кеше бар. Аннан сораштыра аласың. Аның күз бик үткен. Беләсеңме син аны? Теге... Бер кулына перчатка киеп йөри торган кешене. Авыл советында эшләп пенсиягә чыкты... Укытып та алды әле бер турны... Ул эшләгәндә Ямбулат мәктәбендә Тазова Зоя, Жупикова Рита дигән шәп нәмәрсәкәйләр барые. Эвакуация белән килде микән алар... Хөкүмәт бит укытучыларны бик кайгыртты ул елларда, онын, керосинын, утынын дигәндәй... Алар ач булмады. Шуңа күрә без алар белән кулга-кул тотынып эшләдек... Ямбулатның Кәшипов нәкъ ярдәм итә торган иде... У-у-у... бик үткер кеше ул...

...Тукта, тукта... Кара перчаткалы Кәшипов... Аның турында Фәнис әле кичә генә әнисеннән ишетте түгелме соң? Кичә ул соңарып кайтты. Бер аларның тәрәзәләре генә әллә каян яктырып балкый иде алар урамында. Фәнис, кайтмый калган көннәрдә дә шулай төн йокламый көтә микән әни, дип көрсенеп куйды. Сиздерми генә кереп, кызык итим әле дип, ул кесәсеннән пәке алды һәм шуның ярдәмендә эчке келәне күтәртеп, өйалдына үтте. Шыпырт кына өйгә керде. Һәм шундый күренешкә тап булды: Мәрфуга түти, күзлек киеп, бик бирелеп нидер укый, өстәлдә кәгазьләр тузгып ята, түрдәге иске сандык ачык иде. Фәнис сиз-

дерми генә йокы бүлмәсенә үтмәкче булган иде дә, бер сайгак шыгырдап эшне бозды. Мәрфуга түти, ялт борылып, аяк очларына басып туктап калган улын күреп алды.

— Уф, йогырсыз, котымны алдың, — диде Мәрфуга түти. — Ишекне шакып ачтырсаң соң. Атаң мәрхүмнең шундый тозсыз гадәте бар иде... Әнә... кайнар килеш аш аша. Мичтә, чуенда торгач суынмагандыр әле, син ярата торган, ат ите белән чумарлы-борчаклы аш. Юына тор, улым, хәзер салып бирәм.

Мәрфуга түти мич янында кайнашкан арада, Фәнис, өстәл янына килеп, таралып яткан кәгазьләргә күз салды, бер саргаеп беткән фото табып алып караштырды.

— Бигрәк көйсез, улым, эшең, — дип дәвам итте Мәрфуга түти, аш бүлә-бүлә. — Төн юк, көн юк. Әллә чыгасыңмы соң, улым, милицияңнән. Беткәнмени рәтлерәк эш. Бу фурмыны кигәч, минем улым да кебек түгел син. Үз эшең дә бер дигән иде. Нәрсәгә дип барып кергәнсеңдер син анда. Райком җибәрсәни. Хәзер мәҗбүри җибәрә торган заманамыни, үзеңнән сорамый җибәрмәгәннәрдер...

Бу хакта Фәниснең әнисе белән инде кырыкмаса-кырык тапкыр сөйләшкәне бар, ә Мәрфуга түтинең һаман үз туксаны-туксан. Саргая төшкән фото кисәгеннән яшь бер флотчы егет карап тора. Артына «Истәлек өчен Мәрфугага Рәхимнән» дип язылган. «1941 ел, 10 октябрь» дип тә куелган.

— Әни, бу нинди Рәхим? — дип куйды Фәнис, хәйләкәр елмаеп.

Мәрфуга түти, алма урлап тотылган сабый кебек, кызарынып китте. Үзе сер бирми тагын.

— Кая, кемне әйтәсең, улым? — дип, фотоны сорап кулын сузды.

Фәнис фотоны тагын бер әйләндереп карады һәм:

— Чибәр, — дип куйды. Аннары авызын зур ачып иснәнеп алды һәм әнисенең кулына тоттырды.

— Ямбулатның Рәхиме бу, улым, — диде Мәрфуга түти, фотога текәлеп карап, — сугыш вакытында мин шул авылда укыттым бит.

— Йөргән егетең идемени? — дип куйды Фәнис, аштан җитешеп. — Аш бик тәмле булган.

— Кая инде безнең заманда йөрүләр, — диде Мәрфуга түти. — Безнең заманда хат алышу гадәте бар иде. Шушы Рәхим миңа хат язган иде.

— Шуннан? — дип куйды Фәнис аштан бүленгән арада, күзләрен елтыратып.

— Җавап бирмәгән булдым, тиле. Сугыш башланып китте дә Рәхимҗанны бертуган Шәкүр абыйсы белән берүк көнне алып та киттеләр. Тагын бер хаты килеп калды шушы фотосы белән. Әле шул хатны ямансулап укып утыра идем, улым.

— Анысына җавап язган идеңме соң?

— Язган идем дә. Алгандырмы, юктырмы. Бүтән хәбәре килмәде... Син аша, улым, аша. Тәмле килеш ашап кал. Калган ашны үзем дә яратмыйм, әле ярый Акбай бар, әрәм булмый...

— Ямбулатта берәр кемнәре калдымы соң? — дип куйды Фәнис. — Ник дисәң, минем участок, файдам тимәсә дә, зыян тидерүем бар.

— Аларга бер зыян да куркыныч түгел инде, улым, — диде Мәрфуга түти, көрсенеп. — Яшеннәр суккан кебек булды аларның нәселләренә... Ефәк күк ике җегет сугышка китеп озак та тормады, әтиләре Мөэминкол абзый урман кисүдә агачка басылып үлде. Газизә түти япа-ялгыз торды да калды. Ашарга бернәрсә юк, ярты кесә бодай өчен урлап алып китә торган заман. Ачлык... Көннәрдән бер көнне Газизә әбигә Мәскәүдән посылка килеп төшә. Аларның анда туганнары булган икән, Мөэминкол агайның кырыгына җибәргәннәр... Шикәр, чәй, ситсы... Ул чак өчен дөнья бәясе торырдай әйберләр иде болар. Газизә әби шушы бүләк ситсыны бәрәңгегәме, икмәккәме алышкан. Атна-ун көн элек кенә Кәшипов дигән берәү, кулына кара перчатка киеп, сугыштан кайтып төшкән иде, безнең мәктәпкә приказ алып килде. Ронодан, укытырга дип. Ситсыны кемнәр тагын алгандыр. Кәшипов та алган булган, шул чаккан дип сөйләделәр.

— Әни, гел сорыйм дип йөрим, сезнең чорда суд дигән нәрсә бар идеме ул?

— Булмаган кая, — диде Мәрфуга түти, дымланып киткән күзләрен кулъяулык белән сөрткәләп. — Газизә түтигә судны Ямбулатка килеп уздырдылар. Иптәш кызларым белән ачык ишеккә килеп карап тордык. Чандыр гына гәүдәле, ифрат мөлаем бер адвокат хатын да килгән иде. Шулкадәр килештереп сөйләде, ике улының ут эчендә йөрүен дә, картының урман эшендә агачка басылуын да, үзенең гомере буе колхозга бушлай бил бөгүен дә җайлы гына китереп чыгарды... Безнең яшь чак, җүләр вакыт, «и-и, болай булгач Газизә түти котыла икән» дип кайттык та киттек судның азагын көтмәстән... Сигез ел биргәннәрен ишеткәч, өннәрдән чыктык... Безнең күршедә генә Фәрәхия исемле бер хатын бар иде. Үзе яшь кенә булса да, өч бала белән калган. Ире сугышта. Шуның, улым, өстендә гел кожан иде. Кожанның сыңар төймәсе дә юк иде. Бичаракаем, һәр иртә киндерә белән билен ых! дип буа да, колхоз эшенә чыга да китә. Эчтә күлмәге бар идеме, булып та бик өзгәләнгән идеме, әллә булмады ук микән, һәрхәлдә, мин аның күлмәкчән йөргәнен күрмәдем. Моның балалар мич башында; әнисен түземсезләнеп көтеп алалар. Үзе ач, эштән эт булып арып кайткан хатыннан ризык таптыралар. Кемнең газиз баласын ачтан үтерәсе килсен. Фәрәхия, мескенкәем, биленә бәйләп берме, икеме кесә арыш алып кайткан. Кайтышлый безне, улым, — укытучыларны, — карак

тотарга чыгара торганнар иде. Мин үзем беркемне дә тотмадым. Фәрәхия бичаракайны Зоя Тазова дигән бер укытучы тоткан булган. Газизә әби белән аны бергә хөкем иттеләр. Фәрәхиягә ел ярым биргән булганнар икән, ул исән кайткан. Кайткач сөйләгән. Боларны ат тәртәсенә тагып, Арчага кадәр алтмыш биш чакрым буе йөгерттереп алып барганнар. Мине кызганып утыртып та баргаладылар. Газизә әби йөгерде дә йөгерде дип сөйләгән Фәрәхия. Газизә әби шул китүдән юк булды. Абыйсы Шәкүр белән Гомәрне дә сугыш йотты. Өйләрен, абзар-кураларын әкренләп күрше-күлән, алардан күрмәкче башкалар ташып, утынга турап бетерделәр. Аларның өйләре авыл башында иде. Тора-бара урынын тигезләп сөрделәр дә бу нигез басу булып калды...

Әләметдин картның әле генә әйткән сүзләре Фәниснең колак төбендә яңгырап торды: «Алар ач булмады. Шуңа күрә без алар белән кулга-кул тотынышып эшләдек... Ямбулатның Кәшипов нык ярдәм итте... У-у-у... бик үткер кеше ул... Беләсеңме, Ямбулатның Кәшипов дигән шакалын?»

— Беләм, — диде Фәнис.

— Белгәч шул, энекәш, давай, миңа карата булган пүчтәк эшне бетер. Лутчы эшлик кулга-кул тотынып. Менә тиздән чучкачылыкта крупный җинаять булырга тора. Пока шуны әйләндереп торыйк. Аннары бер Ямбулатны дер селкетеп алсаң да ярар иде. Ату узынды бит халык. Урлашу иреге бирелгән мәллә диярсең.

— Чучкачылыкта җинаять булачак дисеңме?

— Шулай дим, энем.

— Ә син ул тармакны бераз аңлый торган кешеме соң? Алай зурдан кубып әйтәсең әйтүен дә?

— Минме? — Әләметдин картның үртәлүдән тавышы яшелле-мөшелләнде. — Беләсең килсә, шушы Сәрдекле авылында чучкачылыкка нигез салган кеше мин алтмышынчы елларда. Чучкачылыкны элегрәк тә бер оештырып караган булганнар. Әллә «бисмилла караклары» үлеп бетмәгән булганмы, әллә ныгытыбрак тотынмаганнармы, ул чакта бу эш пешмәгән. Күрәсең, югарыда күпмедер вакытка «пока отставить» дип торганнар.

Әләметдин карт, нәрсәдер исенә төшепме, сүзеннән бүленеп, болганчык карашын Фәниснең кара-коңгырт күзләренә юнәлтте.

— Менә әйт әле, энем, вәт сиңа бер табышмак. Нишләп керттеләр чучкачылыкны кайта-кайта. Чум делы?

— Табышлы тармак булгандыр, — диде Фәнис.

— Белмисең, — диде Әләметдин карт. — Потому что, башың яшь. Менә тыңлап тор. Без бәләкәй чакта, — дип сөйләп китте Әләметдин карт, ниндидер бер дәртләнү белән: — Осиновкадан узганда, урыс малайлары тотып алып авызга чучка салосы тыгарга азапланаларые. Ашатмакчы булалар. Ә безнең тешләр кысылган, пычак белән каерып алмалы түгел. Ну, болар аптырагач иренгә ышкыйлар. Аннары без юл буе төкеренеп кайтабыз. Менә мин әйтәм, шул Осиновканың берәрсе үсеп, зур кеше булып шаяруын дәвам иттерәдер, дим. Хе-хе-хе.

— Ә нишләп алтмышынчы елларда тешеңне кысмадың соң?

— Ул чакта инде мин авызга чучка салосы сылаганга гына укшый торган кеше түгел идем... Ә халык томана. Беркем чучкачылыкка алынырга теләми. Чучкага ияреп күсе килә икән дә аннан котылып булмый, имеш. Кайсы әйтә, имеш, авылның бәрәкәтен очыра, ди. Кыскасы, саботаж. Ну, минем кеше эшләмәгәнне булдырасым килә. Үч итеп. Тәвәкәлләдем тәки. Тәвәкәлләү бер нәрсә, эшнең рәтенә төшенергә кирәк. Киттем Осиновкага. Барып кердем фермаларына. Чучкалары зәһәр, мыркылдап торалар. Карыйм, бер хатын бер торак буена чүгәләгән.

Әләметдин агай, сүзеннән бүленеп, иләмсез олы кызыл телен чыгарып, яргаланган аксыл иреннәрен ялмаштырып куйды.

— Итәге икәү икән, — дип гөрләде ул, бер күзен хәйләкәр кыса төшеп. — Тураеп баскач, берсен чеметеп кенә читеннән күтәрде дә, икенчесе белән бу турын ышкып та куйды. Аһ, мин әйтәм, бу тәреләрдә ыштан юк бит. Үзем дә сизмәстән «хайт!» дип кычкырып каршына килеп чыккан идем, бу уйламый да, күзләрен тасрайтып тик карап тора. Чибәр, чукынган нәмәрсәкәй, Тазоваларың, Жупиковаларың бер читтә торсын. Заффермы икән бу. Киттек без моның белән. Мужигы сугышта үлгән, самогоны җилле, үзе шалкан шикелле. «Какой ты счастливый, кичә генә бер атнага җитәрлек борщ пешереп, базга гына төшергән идем» дип, уйнаклап йөри. Хе-хе-хе. Әнә шулай Осиновкаларга йөри-йөри оештырдым мин, энем, чучкачылыкны заманасында... Авыл халкы бик әшәке бит ул. Әнә күрше колхозда әле дә булса сарыкчылык белән җаннары чыга. Йөртергә ни болыннары юк, теге елларда сөреп каплатылды. Прибыль юк, мантый торган түгел, сплош убыткы. Эш хаклары мәче артына көл сипкән шикелле генә! Ә безнекеләр уч тутырып акча алалар. Умыралар, энем. Һай, умыралар. Ә берәрсенең Әләметдин абзаларына рәхмәт әйткәне бармы диген? Тот

капчыгыңны! Заманында, мәчет манараларын кисеп, мин клублы иттем бит шул томаналарны... Культурага юл ачтым... Рәхмәтсез бездә халык!

Әләметдин агай, «юк инде, юк» дигән кыяфәттә, авызын кыйшайта төшеп, гайрәт белән кул селтәде.

— Нинди җинаять көтелә соң дуңгызчылыкта? — диде Фәнис салкын гына.

— Нәрсә дисең, үскәнем?

— Бәй, дуңгызчылыкта ниндидер җинаять көтелә дип башлаган идең бит.

— Ә-ә... Аны әйтәсең икән... Дөрес, энем... Көтелә генә түгел, башланды инде ул. Карале, син бик хәйләкәр кеше икәнсең түлке.

— Нидән гыйбарәт инде ул җинаять дигәнегез?

— Менә, энем, унбиш көн була инде, чучкаларны рәтләп керемгә алучы юк.

— Нинди чучкаларны? Ата? Ана?

— Ничек нинди булсын инде, — диде Әләметдин карт, участок инспекторының аңышмый торуына гасабиланып. — Яңа туганнарын, билгеле!

— Ә ни өчен?

— Ни өчен, ни өчен. Тиздән кырылачак алар чебен урынына. Вәт шуның өчен.

— Ә син каян беләсең аларның кырылачакларын.

— Аның өчен әүлия булу кирәкми, энекәш. Менә тыңлап тор. Җир читеннән алтын бәясенә төшереп ташыган комбикорма кичә бетте. Аллаһы әкбәр. Бүтән кайтмаячак та, ди. Фонд беткән. Ана чучкалар рационының туксан проценты әчегән силос.

— Ә фураж?

— Хе, фураж. Көз көне план үтәтәбез дип, рәтле ипине кырып-себереп амбардан алып бетерделәрме? Бетерделәр. Әле симәнә орлыгы да җитмидер дип беләм мин. Кап-кара булып янган, яшелләнеп үргән, план үтәргә ярамый торган ашлыкны тарттырдылар фуражга. Әллә шуның белән чучка малайлары мантыр дип беләсеңме, энекәем. Дурак син. Аны инде син менә миннән сора, коренный чучкачыдан. Син кил берәр көнне, ОБХССтан берәрсен чакыр, и санагыз. Артыгын керемгә алдырыгыз. Бераздан тагын килеп саныйсыз да, хоп, аерма килеп чыга. Син зафферманы запроста утыртасың ныклабрак тотынсаң.

— Тукта әле, тукта, Әләметдин агай. Заффермы синең малай түгелме соң?

— Булса тагы. Мондый эшкә малай да, туган да керешми ул. Җитте аңа да. Вәт, энекәш, мин хәзер Осиновкага китәм, син теге эшне бетер, юк белә инде мине йөдәтмә.

— Әгәр малаең белән киленең гаризаларын кире алсалар яки сине җавапка тартмауны сорап мөрәҗәгать итсәләр, карап карарбыз.

— Сөйләшәм дә, алдыртам да, энем, гаризаларын. Әбзәтелне алдыртам. Син дә мин сөйләгәннәрне йомып калдырма... Сезнең милиция зданиегез эчендә стенада бер бик мәгънәле язу бар. «Бер генә җинаять тә җавапсыз калырга тиеш түгел» дип язылган анда... Ярый, энем, кыйбатлы вакытыңны алдым, сау булып тор.

Әләметдин карт чыгып китте. Фәнис, тәрәзәгә килеп, бу мәһабәт гәүдәле картның урам буйлап китеп баруын озаклап күзәтте. Әләметдин картның адымнары нык, авылдашлары очраганда, уңга-сулга да борылмый, туктап та тормый. Күрәсең, ул сәлам бирми дә, алмый да. Бәлки бу авылда аның үзенә беркем дә сәлам бирми торгандыр. Фәнискә ул ничектер кызганыч булып китте. Ә карт атлавын белә. Әнә ул инде басу юлына да чыкты. Осиновка үренә җиткәнче күренеп барды да, каенлыкны узып сулга борылгач, күзгә күренмәс булды...

Дөресен генә әйткәндә, Әләметдин картны җавапка тартыр өчен әллә ни нигез дә юк иде. Ул яккан әйберләр: бер уч чүпрәк-чапрак, беренчедән, яңа түгел, бәяләре дә бәләкәй. Икенчедән, ягу фактын күргән шаһитлар юк. Әләметдин карт өстеннән материалның җыелган кадәре тора-бара янгыннан саклау инспекциясенә килеп керде. Бу инспекция картка штраф салырга җыенып йөргәндә, районың бер складында янгын чыгып, бик күп сумлык товар җилгә очты да, әлеге эш артык вак булып калып, арткы планга чикте һәм онытылды...

Ул көнне Фәнис милиция бүлегенә оператив җыелышка дип килгән иде. Дежурный бүлмәсе яныннан үтеп барганда, өлкән инспектор-дежурный Нуриман Габрахмановичның дулкынланып үзенә эндәшкәнен ишетеп туктап калды.

— Кер әле, Фәнис энем, — дип кычкырды көмеш чәчле милиция капитаны, телефон трубкасының эндәшә торган башын учы белән каплап. — Синең участокта мәет табылган.

Фәнис, дежурный бүлмәсенә атылып килеп кереп, Нуриман Габрахмановичның янына басты. Тегесе хәбәрне алып бетермәгән, тыңлый-тыңлый әйтелгәннәрне яза бара, сораша, ачыклый иде. Ул, кашы белән ымлап, Фәнискә утырырга урын күрсәтте.

— Әйе, әйе, — диде Нуриман ага. — Ә мәетне иң беренче кем күргән? Тәк. Киемнәре? Иске кожан. Әһә. Соры булган, агарган. Бүреге төлке тиресеннән. Тәк. Аякта? Күн итек. Ничә дисең размерын? Кырык биш? Аһо! Алга сөрлегеп егылган. Осиновка ягыннан кайтканга охшый. Яздым. Карамадыгыз? Ярар, суккан-типкәләгән ише, пычак белән төрткән эзләр юк дидең бит?.. Ничек дисең? Каргалар күзен чукып бетереп, шуннан кереп, миен эчеп бетергәннәр дисеңме? Кесәсендә документлары-фәләннәре юкмы?.. Шешә?.. Эчелеп бетмәгән самогон белән? Туктале, каян белдең самогон икәнен. Син давай ул әйберләргә кагылмый тор әле, яме. Пока аннан китмә. Менә минем янда участковый утыра, хәзер прокуратура тикшерүчесенә шалтыратам. Син берүк алар килмичә китмә, урынны саклый күр.

Нуриман ага, трубкасын куеп, күзләрен Фәнискә төбәде:

— Менә шулай, парин...

— Бу кеше Әләметдин Йосыпов булырга тиеш, — диде Фәнис. — Сәрдекленеке. Малае ферма мөдире. Йосыпов. Исеме Рафаел.

— Сәрдеклеләргә безнекеләрдән берәрсе китмәдеме икән соң? Шулмы-түгелме икәнен ачыклыйсы иде бит, — диде Нуриман ага.

— ОБХСС инспекторы Сәгыйров шунда.

— Нишли ул анда?

— Дуңгыз фермасында контроль санау уздыра.

Нуриман ага телефон трубкасына үрелде, Фәнис бүлмәдән чыгып китте. Коридор буйлап барышлый, ул, туктап, стенада эленеп торган бер планшетка күз төшерде. Анда «Бер генә җинаять тә җавапсыз калырга тиеш түгел!» дип язылган иде.

## МАҢГАЙ

Яңа башлык, кашын-күзен җимереп, бертын безне күздән кичерде, тамак кырды һәм сүз башлады:

— Әйдәгез, эшне танышудан башлыйк, — диде ул, гәүдәсен аяк очларында атындырып. — Беренче рәттән һәм сулдан миңа таба. Менә сез. Басыгыз, бас. Фамилиягезне атагыз. Ә башкалар дикъкать белән тыңлап, шундый ук сорауларга җавап әзерли торыгыз. Йә, кыюрак.

— Мин Мөхәммәтов булам.

— Һы... Мөхәммәтов. Мөхәммәт...оф. Ягъни Мөхәммәт оныгы инде.

— Шулайрак.

— Пәйгамбәр исемен дә йөрткәч, бабагыз күпне белгәндер?!

— Күп белгән бик гыйлем кеше булган минем бабам!

— Алма агачыннан ерак төшми, диләр?..

— Шулайдыр инде, хи-хи-хи.

— Алайса, син би-ик күп беләсеңдер инде, ә?

— Кайчак кирәгеннән артыкны да белә, — диештеләр арткы рәттән.

— Алай... — дип сузды башлык, тирләгән маңгаен кульъяулык белән корытып. — Нишләргә соң инде синең белән, Мөхәммәт...оф?..

— Минем фамилия документта Мухаметов йөри. Акча ведомостенда да шулай.

— Хы... Мухамет... оф. Кызык.

Башлык көлеп җибәрде.

— Пулемет — пуля сиптергеч, огнемет — ут сиптергеч, чөнки мет — метать, ягъни ыргыту дигәнне аңлата. Димәк... Туктале, син чебенне кемгә сиптертмәкче буласың, Мухамет? Бәлки, миңадыр?

— Аллам сакласын! Беткәнмени. Кемгә кушсагыз, шуңа сиптерермен.

— Ярый алайса, утырыгыз.

Башлык игътибарын Мөхәммәтовның күршесенә күчерде.

Чираты җиткәч, ялт сикереп торып, мин дә фамилиямне кычкырдым.

— Кем, кем? — дип үкерде башлык, карашы белән бугаз төеремнән эләктереп.

— Динмухаметов, — дип әйтә алдым мин көч-хәл белән. — Ягъни дингә чебен сиптерүче оныгы. Минем бабай дингә чебен сиптергән!

— Бабаң дингә сиптергәндер дә, хәзер бит дин юк. Ә син чебенне кая сиптерерсең икән инде? Ә? Фәнгәме?

— Кая кирәк дисәгез, шунда, — дидем мин.

— Шулаймыни?.. — дип сузды башлыгыбыз, үтә җитдиләнеп. — Алай булгач утырыгыз. Сез бик кирәк кеше.

Чират Әюповка җитте.

— Татарчасын әйтәсеме, әллә документта язылганынмы?

— Документта язылганын, — диде башлык. — Аннары татарча дигәннән. Әйтик, кырык чакрым китү белән татар теленең пычагыма да кирәге калмый. Үстегез ди. Киттегез ди шәһәргә олырак эшкә. Кемгә кирәк анда татарчаң? Халык алдына чыгып бит урысча сөйләргә туры киләчәк, урыстан да оста итеп. Мәскәүгә үк алыну ихтималын да истә тоту комачауламас...

Башлыгыбыз түшен сыпырып куйды.

— Портфельсез калучылар, гадәттә, шәһәргә юл тотучан. Шулай булгач урысча сөйләргә бүген үк башлыйсыз! Сөйләгәндә эзлеклелек, аксау, логика җитенкерәмәү бик куркытмасын. Иң мөһиме — җил тегермәнедәй зырлап торыгыз. Ярый, төп мәсьәләдән бераз гына читкә тайпылдык. Фамилиягез?

— Аюпов.

— Хы... Аю... пф... — диде башлык, башын чайкаштырып. — Карагыз әле, берәр рәтле фамилияле кеше бармы арагызда, юкмы?

Арткы рәттән сикерешеп тордылар.

— Мин Ахмакҗанов булам, иптәш Тукмакбашев, ә болар — Ахмакдуллин белән Галиахмаков.

Башлыгыбызның йөзенә нур йөгерде. Авызы ерылды.

— Утырыгыз, — диде ул, бик канәгать калып.

...Ниһаять, танышу тәмамланды. Яңа башлыгыбыз Тукмакбашев йомгаклау сүзе белән чыкты.

— Иптәшләр! Сезнең коллективны күпләр җитәкләп караган, ләкин эшегез алга китмәгән. Сезнең коллективны хәтта Арканов та, сөйри алмыйча, мунчалаланып туктады. Мине дә шундый финиш көтә дисезме? Ялгышасыз. Мин сезне өйрәтермен әле. Арагызда акыллы башлар, күп белүчеләр бар икән, юлыгызга ак җәймә. Әнә бик акыллы булсагыз, академиягә кереп, академик булыгыз. Ә миңа академиклар кирәкми. Хәер, ишетүемчә, анда да бик күп белүчеләргә мохтаҗлык юк. Иптәш Мокытбаевның маңгай киңлеге ике бөтен уннан ике сантиметр, ягъни егерме ике миллиметр! Минем маңгай киңлеге — ике сантиметр. Кемнәрнең маңгай киңлеге ике сантиметрдан киңрәк, кулларыгызны күтәрегез.

Зал тынып калды. Без башларыбызны як-якка боргалыйбыз, каранабыз, ә куллар урманы үсми. Менә бер кул шулай да калыкты. Ул — Арслановныкы иде.

Башлык аңа сүз катып, вакланып тормады. Күрмәмешкә салышты.

— Иптәш Ахмакҗанов, сезнең маңгаегызның киңлеге күпме? — дип кызыксынды ул, көлемсерәп.

— Үлчәгәнем булмаса да, ике сантиметрдан таррак булуына иманым камил.

— Күрер күзгә дә шулай, хак әйтәсез. Ә миңа хак сөйләүчеләр бик кирәк. Мин сезне үземә урынбасар итеп билгеләргә телим. Рәхим итеп үзегезгә ярдәмчеләр сайлагыз.

Мин дә, башкалар кебек үк, өмет һәм ялвару тулы карашымны Ахмакҗановка юнәлттем. Ләкин ул Ахмакдуллин белән Галиахмаковны хуп күрде, шайтан алгыры.

— Иптәшләр! Инде соңгысы, — диде башлык, безне берәм-берәм күздән кичереп. — Минем ысул сыналган, әйттем-бетте — ике сүз! Мөстәкыйльлек дигән башбаштаклыкны миегездән чыгарып атыгыз. Миегез булган очракта дип әйтүем. Эшли башлагач, тагын күренер. Әйе!

Җыелыш дөньябызның астын өскә китерде. Без үзгәрдек. Әүвәле артка тарап йөргән чәчләребезне, алга төшереп, кашлардан чак кына өстәнрәк түгәрәкләп кистердек. Кесәләребездә өр-яңа паспортлар, фамилияләребез өр-яңа, ягъни безнең өчен яңа тормыш башланган. Арабызда Арсланов кына юк. Ләкин ул да әллә кая бара алмас. Кемгә кирәк ул бу килеш. Менә мине генә алыйк. Әгәр башлык итсәләр, аламмы мин аны үземә. Бигайбә. Мең гафу! Маңгае тугыз миллиметрдан киңрәк кешене мин, гомумән, якын да җибәрмәячәкмен!

...Кинәт кемдер, якамнан эләктереп, селки башлады. Уянып китсәм — дустым Арсланов.

— Җыелыш тәмам, әйдә кайтабыз, — ди.

Карап торам, Арслановның кай төшедер үзгәргән. Бераздан чамаладым: прическасы бүтән. Мин әйтәм:

— Арсланов, нишләп Сократныкыдай киң һәм биек маңгаеңны чәч төшереп әрәм итәсең?

— Маскировка, — дигән була.

Башы эшли малаеның. Гениальный ул минем дус. Әле өстәвенә акыллы да.

## СӨЯЛДЕМ СӨЯННӘРГӘ

«Машиналарга утырып, җәяү киттем ат белән, аерылыштык, лыштык-лыштык сөйләшербез хат белән» дигән җырдагычарак килеп чыкты. Иртән радиодан Камал театрында Моңзадә Сафина бенефисы узачак дип хәбәр итүләре булды, Нурлыгаян, кырык эшен кырык якка томырып дигәндәй, олы юлгача җәяү, аннан

автобуста тирбәлеп, «Шәмәрдән» стансасына, анда электричкага эләгеп, туп-туры Казанга элдертте. Элдертүченең исемен авылда тутырып әйтүче юк: армиягә, дөресрәге — флотка алынганчы — Гаян иде, кайткач, Нурлы дип дәшә башладылар...

...Камал театрына җитәрәк, егет Габдулла Тукай исемендәге мәйдандагы җир асты юлына төшеп, янып торган чәчәк бәйләме сайлап алды, аерым хутлы кассага барып билет юнәтте. Инде театрның ишекләре ачыласын гына көтәсе калды һәм, Аллага шөкер, диик, сәгать тә үтмәстән, алары да ачылды. Тышта салкын, ачы җил иде, ә театр эче ышык, якты һәм җылы. Нурлы, буфетка барып, салкын тимәсенлек кенә тамак чылатты да, әле уты да эленмәгән тамаша залына үтеп, үз урынын эзләп тапты.

...Ахрысы, мәмрәп кителгән, егет кинәт купкан шау-шудан сискәнеп, күзләрен ачса, зал яп-якты, халык ишелеп керә башлаган. Менә бермәл дәү люстралардагы яктылык әкрен генә сүрелә барып, тамашачылар янә дөм караңгыда калдылар. Тик озакка түгел. Музыка уйнап җибәрде һәм, бәрхет пәрдә өскә күтәрелеп, алда аллы-гөлле утлар уйнап торган сәхнә пәйда булды... Шул сихри мәйданчыкны кыйгач кисеп, кәс-кәс атлап, тигез тешләреннән нур чәчрәтеп, итәге яннан ерыклы җемелдәвек күлмәк кигән гавам сөеклесе Моңзадә Сафина килеп чыкты. Аны күрүгә, тамашачылар урыннарыннан купты, котырып кул чабарга керештеләр...

Кичә, җыр аралаш котлауларга үрелеп, матур гына бара. Сәхнәгә чәчкә таулары өелә. Ә Нурлы кулына кыскан бәйләмен һаман тапшырмый, үзе мөкиббән «Сөялдем сөяннәргә» дигән җырны көтә. Бәхетне юк дип кара син, инде өмет өзелде дигәндә, нәкъ шуны игълан иттеләр, һәм ул, сәхнәне тутырып, залга омтылды.

Сөялдем сөяннәргә, тирбәлдем имәннәрдә,
Бар шатлыгымны бирәем кадерем белгәннәргә...

Җыр тәмамлангач, залдагы гавам беркавым һушына килә алмый, моң канатларына күтәрелгән халәтендә, тын торды. Аннары алкышлар, давыл булып кубып, фәкыйребез Нурлыны да йомычка сыман бөтереп алып, сәхнәгә менгереп ыргытты. Аның чәчәкләрне ничек тапшырганын, сөекле җырчыбызның ут капкан битенә тиереп ничек иреннәрен пешерүен сөйләп тормыйк. Нурлы авызын һич җыеп бетерә алмады, маңгаеннан туктаусыз тир акты, башын түшәмдә, ә үзен бәхетнең сигезенче катында итеп тойды. Гаҗәп җыр бит ул «Сөялдем сөяннәргә». Көе дә искиткеч, сүзләре дә!

Нурлының бер танышы бар. Теләсә кайсы җырның җыртыгын табып көләргә аңа куш. Бу җырга да өлеш чыгарып азапланды... «Сөян... — дип тыңкышланды ул, — сөян — кабыгы туналган юкә бүрәнәсе. Багана утырып торса, бүрәнә ятып тора, тәгәрәп китүчән... Димәк, сөянгә сөялү өчен, җиргә ятарга, ә бәлкем аунарга кирәк! Тәк. Тирбәлдем имәннәрдә... Монда мәгънә тагын да тирән, төбенә төшеп җитешле түгел. Имәннең корычтай каты, чытырман ботакларына ничек урнашып була соң? Чөеп кундырсалар гына инде. Ә бөгелмәс каты имән ботакларының беришесе кабыргаларың аша үтү ихтималы да юк түгел... Имәннең тирбәлүе... Аны тирбәтү өчен, корыч арканнар белән бәйләп, «Комацу» тракторын эшкә җигәргә кирәк... Һәм шундый тирбәлүләрдән соң да шатлыгың калып, аны кадереңне белүчеләргә өләшүнең, әлбәттә, гаебе юк...» Танышының остаруын ошатмады Нурлы. «Кеше тормышында шундый гарасатлар була, сөяненә дә сөялдерә, имәненә дә тирбәлдерә», — дип кырт кисте ул.

...Кайсыдыр җырдан соң сәхнәгә бер көлтә чәчәк күтәргән Төркия кунагы килеп чыкты, һәм «чок гүзәл җырлардан мәмнүн» булуын белдерде. Зифа буйлы, ыспай киемле, чем-кара мыеклы, затлы-зыялы чит ил иренең ягымлы сүзләре артисткабызның болай да тулышкан күңелен тәмам ташытты, аның да үз чиратында кунакны куандырасы килде һәм ханымыбыз рәхмәтен төрек телендә әйтте! Дөресрәге, төрекчә әйтәм дип уйлап, үзбәкчә ябыштырды. Рәхмәт әйтүнең гаебе юк, әмма Нурлы янәшәсендә, кичә дәвамында тачточ сагыз чәйнәп, мыш-мыш килеп утырган юан хатын, аның янтыгына терсәге белән төртеп:

— Нәрсә күр ди ул? — дип, эре тешләрен ыржайтты.

Мәгълүм ки, төрекләр, Тукай заманындагы безнең бабайлар кебек үк, рәхмәт урынына «тәшәккүр», ә үзбәкләр, бу сүзне чак кына үзгәртеп, «ә» хәрефләре урынына «а» куеп әйтәләр. Аерма тик шунда. Шатлыктан сәрхуш сөекле җырчыбыз, төрек кунагына әлеге рәхмәт сүзен, үзбәкчәләп, кат-кат, баш ия-ия кабатлады.

Бенефис төн уртасында төкәнде. Театр бинасыннан чыккач, Нурлы тирән итеп бер сулап күккә карап алды да вокзалга таба атлады. Вокзал халык белән шыгрым иде, аңа байтак гомер көтү залы дигән бүлмәдә аркасы белән стена сөяп торырга туры килде.

...Кинәт кайчандыр, әле бала вакытында, әнисе белән икәүләп Таҗикстанга кунакка барулары исенә төште. Ташкент вокзалында сигез сәгать поезд көткән иде алар. Тамак ялгап, үзара сөйләшеп утырганда яннарына яшь кенә, матур гына бер хатын килеп сүз кушты. Ул биредә үзбәк егетенә кияүгә чыккан һәм

Ташкент кешесенә әйләнгән, әмма туган ягын бик сагына, якташлары очрамасмы дип, көн дә вокзал тирәсен бер урый, имеш.

— Их, үзебезнең Ык буйкайлары! Җәяүләп кайтып китәсе килгән көннәрем күп, — ди ул.

Нурлыгаянның әнисе исә:

— Бер кияүгә чыккач торырга кирәк, ияләнерсең әле, — дип, үгет бирә. — Ичмасам, телләрен беләсеңме? — дип сораштыра.

— Әй, беләм инде, — ди якташ апа.

Нурлыгаян да сүзгә катышасы итте.

— Үзбәкчә рәхмәт ничек була? — дип кызыксынды.

Теге хатын әз генә уйланып торды да, исенә төште, ахры, катгый итеп, аты-юлы белән «фәлән күр!» дип ярып салмасынмы?! «Фәлән»нең каты «к» белән башланганын ычкындырды бу. Нурлыгаянның әнисе мулла нәселеннән чыккан укытучы, авылларының интеллигенты, андый сүздән коты очып өнсез калды һәм, бераз сулу алгач кына, «юк, юк, алай түгелдер» дип әйтә алды.

— Һәй, апа! — диде теге хатын, әрнү катыш ачы елмаеп. — Боларның шулай монда! — Һәм җәлт кенә вокзал диварындагы сәгатькә күз төшереп алды да, саубуллашып та тормастан, яныбыздан китеп барды. Әмма икеме-өчме адым атлауга, борылып: — Апа, фәлән күр түгел, ә төгән күр икән, — дип, тәшәккүр сүзенең үзбәкчә вариантын яңгыратты. Аннары, кинәт кенә сул кулын алга селтәп, урысчалатып: — Один фәлән инде, — дип өстәп, юлын дәвам итте...

...Нурлы инде поездда җилдерә. Бүген ул авылына ук кайтып җитә алмастыр. Шәмәрдәндәге апаларына кереп кунарга туры килмәгәе. Хәер, кайтып җитүдән ни мәгънә? Яхшымы-яманмы хатыны да, елакмы-көләчме баласы да юк аның. Ялгыз өендә зарыгып, ялгызлыгы гына көтәдер. Дөрес, өйләнгәне булды. Хәрби хезмәткә озатып калган һәм көтеп каршы алган яры белән кавышкан иде. Ике атна торгач, пары китеп барды. Аннары аның флотта, су асты көймәсендә хезмәт иткән чакта нурланыш алуы хакында сүз таралды. Ягъни Нурлы үзе дә, җырдагыча, сөялгән һәм тибәлгән кеше ул.

Поезд ашыга-ашыга алга чаба. Тәгәрмәчләр, бертуктаусыз үзбәкчәләп, рәхмәт дип тәкрарлыйлар төсле.

## ТОЗЛЫ ЯҢГЫР

Элек бит карага мана торган каләм белән яза идек. Малайларның шул инде, үзара эләгешеп китәсең дә, пыяла кара савыты идәнгә төшеп чәлпәрәмә килә. Дәрес башлангач язарга кирәк, борылып, арткы партада утырган кызларга ялынасың. Ә алар бөтенесе дә бериш түгел, кайсы мандыра, ә кайсы юк.

Борын асты кибә башлагач, янә кызларны аерасың, озаттыручы һәм озаттырмаучыларга. Рәхимә — ташкүмердәй ялтыр күзле, тулы тәнле, чая сыйныфташым алтынчыда укыганда ук беренче төркемнең алгы сафына чыкты! Әйбәт кыз иде ул, карасын да һичкайчан җәлләмәде.

Хәтерлим, ниндидер бәйрәм уңаеннан концерт куярга безнең сыйныф тиеш булды. Рәхимәнең тавышы матур, җырларга күндерә алмыйбыз, ул элгәре бик оялчан иде. Шуңа да карамастан моның артыннан авылның фырт егете Сәлмән «чиерттерә» һәм Рәхимә шуңа озаттыра, имеш!

Төрле яклап кыстауга түзеп буламы?! Әлбәттә, гүзәлкәйне «сындырдылар» һәм ул, чираты җиткәч, кыска җиңле, акка кызыл борчак төшкән күлмәген киеп чыгып басты да искиткеч матур тавышы белән авылдашларын әсир итеп, җырлап җибәрде.

Кайда соң син,
Кайда соң син...

— дип өзгәләнде кыз.

Шулчак һичкем көтмәгәндә Сәлмән мәлгуньнең:

— Мин мондау! — дигән тавышы яңгырамасынмы...

Рәхимә, комачтай кызарынып, ике битен каплады да сәхнәне ташлап йөгереп чыгып китте, ә зал дәррәү күтәрелеп көлде...

Бар иде заманалар... «Рәхимә өчен тагын сугышканнар», — дигән хәбәр бермәл авылда гадәти яңгырый һәм берәүнең дә исен китәрми башлады. Рәхимәбез, сигезне тәмамлап, бухгалтерлыкка укып кайткач, аның тирәсендә бөтерелүчеләр тагын да ишәйде, мотоциклга атланып район егетләре тыз-быз чабулады, кунакка кайткан кала егетләре дә гел аңа омтылды...

Әмма еллар узган саен гүзәлебез артыннан борылып карап калучылар саны кими төште, һәм көннәрдән бер көнне апагыз хозурында яше утызга якынайган зоотехник Азат кына торып калды. Ул эшне коры тотасы итте, бер кичне чибәр түтине капка төпләрендә кысып кочаклады да:

— Матурым, икебезнең дә яшь Аллага шөкер, безгә өйләнешергә вакыт, — диде.

Рәхимә башын артка ташлап көлде, боргаланды, ансат кына ризалашып очсызланудан да, һавадагы торнага өметләнеп, кулдагы соңгы чыпчыкны «ычкындырудан» да курыкты. Ул, аяк очларына басып калкынгалап торганнан соң:

— Мин риза, әмма шартларым бар, — диде.

— Әйт, — диде Азат, үтә җитдиләнеп.

— Беренчедән, мин үз фамилиямдә калачакмын!

— Ярар, калырсың.

Рәхимә тагын нәрсәләрдер тезде, ә Азаты, баш кагып, гел:

— Ярар, ярар, — дип кенә торды.

Әмма шул кичтән соң егетне Рәхимәләр капка төбендә бүтән күрүче булмады. Ә бер атнадан моның күрше авылдан яшь кенә бер савымчы кызны алып кайтуы мәгълүм булды. Шулай итеп, нәкъ Рәхимә теләгәнчәрәк килеп чыкты, ул үз фамилиясендә торып калды...

Бу хәлләрдән соң кыз суырылды һәм эченә йомылды, урамны яңгыратып көлүләр бетте, клубка, киногa барулар онытылды. Кәнсәләреннән кайта да әнисе кул арасына керә, эштә дә эш, өйдә дә эш, янган йөрәген тагын ничек бассын. Шулай гел бертөрле эчпошыргыч айлар уза торды.

Әмма, кара көннәрне аклары алмаштыра дигәндәй, бермәлне боларның капкасын соңгы араларда яучылыгы белән аты чыккан пенсионер укытучы Гадилә җиңги какты. Ишектән керде, түргә менеп утырды. Баксаң, күрше Көшел авылында бер дигән егет бар икән. Яше утызны гына тутырган, эчми-тартмый, акчаны соскылы көрәк белән көри, ПМКда эшли, начальнигы бик хөрмәт итә ди үзен. Өйләнсә, фатир да бирәчәк, әлегә бу әти-әнисе йортына мотоцикл белән кайтып йөри, кулы алтын, аерым заказлар буенча гына йөртәләр — фатир, кабинет идәннәренә паркет җәя, туалет-ванналарга тәтәй ябыштыра, буйый-матурлый, агач эшен дә белә ди.

Рәхимәнең әтисе Мозаффар агай, пенсиягә чыкканчы колхоз парторгы булып эшләгән кеше, кызыксынасы итте:

— Ник алай ялгыз эшли? Коллективтан аерылып? Акылы камилдер бит? Кем малае ул?

— Камил, бик камил. Хөрмәтле Габделкадыйр абзый малае. Бик йомышлыклы, бик әйбәт кешеләр.

— Теге мулла сымаграк булып йөрүчеме?

— Шул. Шул үзе.

— Беләм мин ул гаиләне... Бик динле кешеләр. Малае да намаз укыйдыр инде, ә?

— Укыса, — диде Гадилә җиңги, акланган кыяфәттә кулларын як-якка җәеп җибәреп. — Оясында ни күрсә, очканда шул, диләр бит...

Хәтерли Мозаффар агай, бер елны районнан вәкил килеп, шомлы тавыш белән: «Колхозыгызның Көшел бригадасында тәравих укыйлар, как сез моны допустили?» — дип, утка бастырган иде. Аннары Габделкадыйр агайны кәнсәләргә дәштерделәр.

Түгәрәк сакаллы, чиста йөзле абзый озак көттермәде, «Кобровец» матаена атланып килеп тә җитте. Ашыкмыйча каскасын салып рульгә элде, кесәсеннән чиста кулъяулык алып битен-кулын сөрткәләде, бәрхет түбәтәен рәтләде һәм нәчәлствога каршы атлады. Агайның пинжәге түшендә ике медаль һәм бер Дан ордены җемелди иде.

— Әссәламегаләйкем, — диде ул, үзен көтүчеләргә ике кулын сузып.

— Сәлам, сәлам, — дип, сыңар кулын тоттырды вәкил иптәш.

Мозаффар да ике куллап күрешергә йөрәксенмәде.

Вәкил, һич көтелмәгән йомшаклык күрсәтеп, агайның тормышлары белән кызыксынды һәм ахырдан гына:

— Ничек соң рамазан айлары, тәравихны кайда укыйсыз? — дип кызыксынды.

— Аллага шөкер. Минем өйдә, — диде Габделкадыйр агай, үзен ник чакырганнарына, ниһаять, төшенеп.

— Күп җыеласызмы соң?

— Бер биш-алты карт җыелышып утырабыз инде.

— Тешләр беткән сезнең, — дип куйды вәкил, «утырабыз» сүзен дөрес әйтә алмаучы авызны сагышлы күзәтеп. — Теш врачына чират су буе, ну, мин военкомга да, баш врачка да шалтыратырмын, тешләрне ремонтлап алырга кирәк, гаетләр узгач.

Габделкадыйр агай ут-суның төрлесен кичкән кеше, эшнең ансат төгәлләнүенә беркадәр гаҗәпләнеп, рәхмәтен әйтеп кайтып китте.

Ә вәкил, ул күздән югалгач, Мозаффар агайның иңенә кулын салып:

— Хәрби ветераннарны бик куырып булмый хәзер, оборона министрына шикаять юлларга да күп сорамыйлар, — дип акланды...

Ә Гадилә җиңги үз эшен төгәл белә, егетнең бертуган абыйларын мактауга күчкән. Бар да ишле гаиләләр, бик бәхетлеләр, имеш.

— Ник борчыласың, атасы, динле дип инде, аның каравы эчми-тартмый ди бит, — дип, карчыгы да сүзгә катышасы итте.

Мондый җайлы сүз чыккач, Гадилә җиңги һөҗүмгә үк күчте.

— Әгәр дә уңайрак фикердә булсагыз, ул абыйсы белән килгән күршеләрегез Фәлихларда гына, дәшим булмаса, — дип чыгып та йөгерде.

— Кызым, син ул егетне беләсеңме соң? — дип куйды аптырашта калган Мозаффар агай.

— Үткән атнада безнең кәнсәләрдә прит кабинетын ремонтлады. Миннән ике-өч ел элек укыган бугай мәктәптә, тик мин аны хәтерләмим.

— Үзара сөйләшкәләдегезме соң?

— Бухгалтериянең ике тәрәзәсе ачылса ябылмый, ябылса да ачылмый тилмертә иде. Моңа әйтүем булды, кабинеттагы эшен ташлап, бик тиз рәтләде. Өстәл-урындыгың какшау дип, аларны да сүтеп keләйгә утыртты. Алдына гына карап эшли ул Мәхмүт, ә мине күрсә, кызара, — диде Рәхимә һәм көлеп җибәрде.

Кызларының көлүен тансыклаган әти-әни күзгә-күз карашып алдылар һәм ишектән кереп килүче ир-атларны елмаешып, басып каршыладылар, түргә узарга кыстадылар.

Сөйләштеләр, аңлаштылар, туй көнен дә билгеләделәр. Әмма булачак кияүнең шарты бар булып чыкты.

— Туйда ризык хәләл булыр, исерткечләр куелмас, — диде ул, катгый итеп.

Әлбәттә, Мозаффар аганың борын салынды, әмма ни хәл итәсең, тешен кысып күнде.

Туйлар узды. Кияүнең начальнигы озын буйлы, кызыл чырайлы таза урыс, сүзен сүз итеп, хак мөселман динен җиренә җиткереп тотучы яраткан эшчесенә эре панельле йорттан ике бүлмәле фатир бирдертте, ә ПМКның яңа килененә бухгалтериядә җайлы эш табылды.

Мәхмүт тормышчан ир булып чыкты, ике як әти-әнине дә тигез кайгыртты, үз фатирларын да курчак өе рәвешенә кертте, йорт җиһазларының яхшысын кайтартты, аяк асларына келәмнәрнең дә калын һәм затлылары түшәлде. Бар да житеш, түгәрәк кебек. Рәхимәгә дә кияү килеште, ул кабат тулыланды, чибәрләнде, конторана яңгыратып, чылтырап көлә торган булды. Әмма хатынның эчен пошырган нәрсә, бухгалтерия кызлары белән берәрсенең туган көнен коры шәраб белән «юып» кайткан өчен дә сүз чыгуы. Әлбәттә, Рәхимәкәй җаен тапты, тулы, нык беләкләре белән мыжык ирен кайнар кочагына кыса да, тулы иреннәре белән мораль укырга һәвәс авызны томалый. Һәм Мәхмүт йомшый.

Ләкин сыйныфташлары белән очрашуга бару мәсьәләсе кузгалгач, бу сыналган ысул үзен акламады, тәки киресенә катты ир дигәнең.

— Бармыйсың, и вчу, — ди. — Син ир хатыны, ничек инде ят ир-ат арасына, кара урманга төн кунарга чыгып китәсең? Табыныгызда хәмер, җитмәсә, чучка итеннән шашлык куырасыз, ямьле урманны сасытып...

— Мәхмүт, акылыңа кил, анда килүчеләр бар да ир хатыннары. Синнән башка берәү дә хатыныма тиярләр дип курыкмый, ышанычсызлык күрсәтеп, газиз хатынын рәнҗетми. Ышанмыйсың икән, икәү барыйк, син минем тән сакчым булып йөрерсең. Ярый, юк икән кирәкми. Кил төнге уникедә, бергәләп кайтып китәрбез, анда бит беркем дә йокларга җыенмый...

Янә кайнар беләкләр, тулы иреннәр эшкә кереште һәм аяк терәп карышкан ир чая хатын тарафыннан кабат «сыртына салынды».

Очрашу дигәннәре мәктәптә, укыган класс бүлмәсендә башланып, иң мөһим өлеше, әлбәттә, урманда дәвам итте. Рәхимә арада иң чибәре иде. Кием дә затлы һәм ыспай, колакта да алтын алкаларның саллылары, бармактагы йөзекләр дә берничә, йөз дә елмаюлы, көлү дә элеккечә! Мәҗлестә аңа тиң булырлык бер генә мәһабәт ир бар, кайсыдыр районда нindидер шәп түрә булып киткән сыйныфташы Әдһәм иде. Магнитофонга танцы иткәндә аны гел шул Әдһәм чакырып йөдәтте. «Ак бию» игълан ителгәч, Рәхимәнең дә бурычлы булып каласы килмәде...

Магнитофоннан җыр агыла:

Сине назлап,
Сине сөюләрем —
Никахыма бит ул хыянәт...

Күңелле вакыт тиз уза, унике дә тулган, чит ир пинжәген җилкәсенә элгән хатынын Мәхмүт каенга аркасын терәп торган хәлендә очратты. Пинжәк хуҗасы Рәхимәнең колагына нидер әйтә иде шикелле, көтмәгәндә Мәхмүт килеп чыккач, болар читкә тайпылышты.

— Сәлам, — диде Әдһәм, көтелмәгән кунакны кочагына эләктереп һәм ияген Мәхмүтнең баш түбәсенә терәп. — Әйдә, бер сыйланыйк, якташ. Күптән күрешкән юк бит.

— Икенче вакыт, — диде Мәхмүт, көч-хәл белән хәмерле сулышлы авылдашыннан ычкынып. — Кайтабызмы, карчык. Уникедә кил дигән идең, сәгать беренче китте...

— Бу минем Мәхмүт, — дип уңайсызланып елмайды хатын, Әдһәмгә пинжәген кире кайтарып.

— Сау бул, классташ. Кулыңны болгап кал Рәхимә абыстаңа.

Күк тулып йолдызлар яна, ә йөзгә яңгыр җиле бәрә. «Урал» мотоциклы оча гына. Матай бишегенә утырган Рәхимәнең калын кара чәчләре тузгый, кыйгач кашлары киерелгән, күзләре ут яна. Аһ, нинди чибәр ул. Ә Мәхмүт аңа мәктәптә укыганда ук күз төшереп йөрде. Рәхимә исә аны бөтенләй искәрми иде. Мәхмүт, шушы Рәхимә хәләлем булса иде дип, намаз саен Ходайга ялварды. Менә бит, бәхет бар ул, алар бергә. Әмма икесе ике кеше шул аларның. Ире намазлыкка утырдымы, Рәхимә утны шарт-шорт яндырасүндерә башлый, тузан суыргычны эшкә куша, ишеген ябарга «онытып» бәдрәфкә кереп утыра...

Вакыт-вакыт ул Мәхмүтне ихластан яраткан төсле дә булып тора. Бигрәк тә акча алып кайткан көннәрдә. Ә Мәхмүткә нәрсә, яңа кәчтүм-чалбарны да ул Рәхимә кыстаганга гына алып киде.

Кайтып җитәрәк сөекле ханым йокымсырады, һәм ире аны, биленнән коча төшеп, икенче катка сөйрәде. Өйгә кергәч, диванга ятарга булышты, өстенә юрган япты, баш астына мендәр кыстырды һәм, тиз генә ваннага кереп, тәһарәт алып, намазлыкка басты; башта азан, аннары камәт, аннан ниятен әйтте:

— Илаһи ният кылдым ясыйгы намазымның дүрт рәкәгать фарызын үтәмәккә...

Мәхмүт, сәҗдәгә китеп, маңгаен намазлыкка тиергәндә, артында кыймылдау һәм мышнау абайлады.

— Әй! Ять-яшь башыңнан укыма әле намаз! — диде хатын, сәҗдәдәге иренә төртеп: — Иди сюда...

Мәхмүт корт чаккандай чәчрәп торып басты. Йөзе ап-ак булды, тәне дер-дер килде.

— Талак! — диде ул, көч-хәл белән шушы сүздән буылып.

— Нәрсә?! — дип, авызын ямьшәйтте гүзәл ханым, гаҗәпләнү катыш серле елмаеп.

Мәхмүт сүз көрәштереп тә, талакның калган икесен дә әйтеп тормады, ашыгып өеннән чыгып китте, бер тибүдә матаен кабызды һәм әти-әнисе яшәгән авылга таба элдертте. Биткә яңгыр бәрә, ә Мәхмүтнең иреннәре тоз тәмен тоя иде...

## БҮРЕК

Җиргә беренче кар ява иде. Ике егет цинк белән йөгертелгән калай түбәле, силикат кирпечтән салынган, аклыгы белән үзеннән-үзе яктырып, нурланып торган җыйнак һәм күркәм бер йорт каршына килеп туктадылар.

— Мин хәзер, — диде берсе. — Тиз генә белешеп чыгыйм әле, бу кешедә булмый тормый иде.

Бер-ике адым киткәч, ул борылды һәм, гафу үтенгәндәй:

— Үзем генә керәм инде, таныш түгелләр белән эш йөртми бу абзый, — дип өстәде.

Ялгыз торып калган иптәше, тирә-юньне ваемсыз күзәтеп, әрле-бирле йөренергә кереште.

Урамнан уңга-сулга туктаусыз кешеләр үтеп тора. Һәркемнең үз уе, үз шөгыле, үз кайгысы. Әти-әниләренә тагылып тәпиләүче нарасыйларда гына артык гамь юк. Алар, телләрен чыгарып, бөтерелә-бөтерелә уйнаклаган кар бөртекләрен аулыйлар. Вакыт-вакыт, онытылып, туктап калалар. Ә кайчак, нәрсәгәдер абынып, егылып та киткәлиләр. Аларның җитәкләүче, юнәлтүче кулдан котыласылары, йөгерешеп уйныйсылары, керләнмәгән ап-ак кар өстендә тәгәриселәре килә. Әмма әти-әниләрнең мөһимрәк эшләре бар, алар ашыгалар, ашыктыралар...

Инде аяк астында мамыктай келәм хасил булган. Агачлар да, шәрәлекләреннән котылып, бәйрәмчә киенешкәннәр. Төшеп баручы кар бөртекләрен аралап, әллә кайлардан адаша-адаша килгән кояш нурларыннан ак дөнья зәңгәрсуланып җем-җем итә.

Йомгактай бер көчек, бу могҗизага таң калып, шаян йөгерек күзләрен күккә теки, агачлардагы үзгәрешне тикшерә һәм шатлыгыннан «һау» дип өреп куя.

Ул карны әле борыны белән капшый, әле тәпие белән чөеп җибәрә, әле койрыгы белән себереп туздыра. Ләкин һаман да хозурлыкка төкәнә алмыйча, чалкан ятып сыртында әйләнә, йонлач тәпиләрен селки, рәхәтлектән күзләрен кысыш, беленер-беленмәс сиземләнгән кояшны күзәтә.

Ул ямь-яшел җәйне хәтерли. Аннары сап-сары көз булды. Соңра яфраклар коелды, әче җилләр исте. Дөнья төссезләнеп, шыксызланып, шөкәтсезләнеп калган иде. Ә аның әле мондые да, агы да бар икән...

Шыгырдап ачылган капкада теге егет күренде.

— Эш пеште, — диде ул, кәефле елмаеп. — Озын йонлы эт тиресеннән. Синнән дус кеше...

— Төсе нинди? — дип бүлдерде аны иптәше.

Тегесе беркавым уйлангандай итеп калкынып торды. Шулчак ул ут өереп уйнап йөргән көчекне күреп алды һәм аңа бармагын төбәп:

— Нәкъ шушындый, — диде. — Моның анасының тиресеннән текми микән әле ул аны, — дип тә өстәде, маңгаен җыера төшеп.

Иптәше көчеккә кызыксынып, якын итеп, җылы караш ташлады.

— У-у, — дип сузды ул канәгатьләнү белән. — Каяле, кил әле монда, Акбай, маһ, маһ, маһ!

Көчек колакларын торгызды, икеләнеп калды. Ләкин үзен дәшүченең тавышы ифрат ягымлы һәм дустанә булгач түзмәде, йөгереп килеп, аның ботинка башларын яларга тотынды.

Егет, иелеп, көчекне сыртыннан сыйпады, йонын бармаклары белән аралады.

— Мондый булса, матур чыгачак икән, — диде ул эшлекле кыяфәт белән. — Сиңа чын күңелдән рәхмәт инде, агайне. Югыйсә кар ява башлады, ә минем башка кияргә дә юк иде бит.

— Анысын соңыннан әйтерсең, — диде икенчесе, кулын селтәп. — Әйдә киттек. Ярар инде... Йә күз тиереп, киләсе елга берәрсен бүрексез калдырырсың, ташла шул корчаңгыны.

Көчек, егетләр тыкрыкка борылып күздән югалганчы койрыгын болгап, ышаныч тулы тугры күзләрен мөлдерәтеп, озатып калды. Бу вакыт эчендә аның ялтыравыклы кара борынына кунып җемелдәшкән кар йолдызлары берәм-берәм сүнеп юкка чыктылар.

## АК ТЕПЛОХОД

Идел өсте сукаланган басу кебек. Кая карама — буразналар, буразналар... Менә иң кырый буразна, буе белән кубарылып, янәшәдәгесенә капланды. Ул да түгел, алар икәүләп күрше буразна өстенә ишелеп төшteләр. Һәм тагын... тагын...

Нәни ак яулык, ераклаша барган теплоходны озатучы кызның кулыннан ычкынып китте дә, канаты имгәнгән кош шикелле түбәнәйгәннән-түбәнәя барып, бер дулкын өстенә килеп кунды. Әмма яралы акчарлак — ак яулык — су буразналарының ак ялына ятып озак ял итә алмады шул, очарга теләгәндәй талпынды, талпынды да, хәле бетеп, су төбенә китте.

Җил кызның итәген тарткалый, йолыккалый. Яңакларын яртылаш каплап, иңнәренә яткан чәчләре тузгып китә дә керфекләренә эленгән яшь бөртекләрен себереп төшерә.

Идел тулы акчарлаклар: шыңшыйлар, сукраналар...

\+ + +

— Озаттыңмы, кызым?

Кыз әнисенең күзләренә мөлдерәп карап торды да баш какты.

— Ни белән китте, бәбкәм?

— ...

— Су трамбае белән мәллә?

— Ак теплоход белән...

— Нигә балтаңны суга төшердең? Бер елдан кайтам ди ич. Бетә ди бит экспедициясе.

Кыз, тавыш-тынсыз гына өстәл янына килеп, ашыга-кабалана пластинкалар актара башлады. Берсен кулына алып, уйлангандай карап торды. Аннары уйнаткычка куйды. Җыр башланды...

Ә ул... Ә ул — кара чәчле, кысык күзле йомшак курчагын күкрәгенә кысты да, хисләренә чыдаша алмыйча, кискән агач сыман, караватына йөзтүбән капланды.

...Киткән кошлар язын кайтырлар...

Кухня ягыннан әни кешенең яшелле-мөшелле тавышы җырга кушылды.

Иркәм син дә кайтырсың әле...

\+ + +

Ак теплоход койрыгында су күбекләнеп кайный. Ике ир палуба читендә тәмәке суыра-суыра сөйләшеп тора. Теплоход торбасыннан кара төтен чыга.

— Экспедиция бетүгә өйләнешәбез, кайгырма, дустым, дим.

— Дустым дисең?

— Бәй, хатын-кыз кешенең дусты ич ул.

— Ха-ха-ха. Геолог, имеш! Бишьеллык экспедиция! Каян башларыңа килде ул, әй?

— Кыяфәт килгән ич. Сакал бар... Учак ягып, гитара чиерттерү дә берни тормый. Берәр шул як исе килә торган сувенир кыстырам да...

— Ничек тотылмыйсың соң син шул гомердән бирле?

— Барыр алдыннан укыштырам. Китап, журналлар актарам. Таулар, ташлар, токымнар, гомумән, Себер хакында. Хатын аптырый: «Ник кирәк ул сиңа?» — ди.

— Еш барасыңмы соң?

— Елга бер-ике. Ерак җир түгел бит, утырдың-киттең, бардың-кайттың, бернәрсәсе дә юк.

— Ну, малай. Үдибләюс мин сиңа. Грам үзгәрмәгәнсең, һаман мәхәббәт фронтында!

Ак теплоход бара да бара. Ярлар күренми. Артта да, алда да, уңда һәм сулда да дулкыннардан торган Идел.

## ЛӘЙСӘН

Көне бик матур туры килде тагын. Болынлыкны, тау яңакларын чуп-чуар итеп сарып алган кызларны, егетләрне, абый-апаларны кояш үзенең нурларына кинәндерә. Җыр-бию авазлары, уен-көлке, чыр-чу, һаваларны ярып, җир тетрәткән ат тоягы тавышлары, көрәшчеләрнең авыр-авыр сулыш алулары, шоп-шома колга башында җилфердәгән сөлгеләре, коңгырт-кара күзле татар кызларының оялчан, мөлаем елмаюлы күз карашлары...

Сабан туе иде бу.

Һәр тараф, күк гөмбәзе әллә нинди шифа белән өртелгән. Бөтен нәрсә җитешле, тантаналы һәм бәрәкәтле.

Сабан туе. Монда һәркем үзенчә бәйрәм итә. Бераз колак алкасы астына чиертеп алган егетләр, җилкәләрдән кочаклашып, гармун тартып, әйттереп йөриләр. Көрәш, бәйгеләр баруын уйлап та бирмичә, кайберәүләр, түгәрәкләнешеп, табын ясап, ашап, кәеф-сафа корып утыралар. Кемнәрдер капчык сугышына ихласын салган, ә кемнәр — колга башына үрмәләүчеләргә...

Ходаның хикмәте — һәр сабан туе көнне яңгыр яумый калмый. Бу юлы да әллә каян гына тастымал хәтле бер болыт кисәге килеп чыкты да, кояшның шат йөзен томалап та куйды. Ул да булмады, чиләкләп яңгыр орырга тотынды. Чыр-чу көчәйде, кем плащ, кем ашъяулык бөркәнде, малайлар йөк машиналары астына ышыкланып тулдылар, яңгыр сихәтеннән калыккан гөмбәләр сымак кулчатырлар пәйда булды. Ә көрәшчеләр, берни булмагандай, җитди, эшлекле кыяфәттә, манма тир-суга манчылып, сабан туе батыры исеменә дәгъваларын дәвам иттерделәр.

Иртәдән бирле аяусыз кыздырган кояштан һава сафланып китте, яңгыр яуган чакта битләрен юарга өлгергән чирәмнәр тагын да яшелләнделәр, һәм аларның өстендә янә асылган кояш нурлары чагылышыннан, юка томан элпәсе сыман, яшькелт балкыш хасил булды. Офыктан офыккача салават күпере сузылды...

Яңгыр вакытында бераз тынып торган шау-шу, ниһаять, чын-чынлап ачылып китте, уртада батырлар көрәше башланган икән... Ай-яй, каты булып чыкты ул алыш!.. Кайсы да юл куярга исәп тотмый. Тартышалар, тартышалар, тирә-яктагылар егарга вакыт икәнен әйтеп кычкыралар, ә нәтиҗәгә һаман ерак, ие килсә, җәбе килми, күтәреп бәрергә җае килми.

Батырларның кыска җиңле аксыл ефәк күлмәк кигәне, гәүдәгә базык, беләкләре юан, хәрәкәтләре салпы-салмак, җилкәләре киң, утыз-утыз биш яшь тирәләрендәге ир булса, икенчесе — сыгылма тәнле, чандыррак гәүдәле яшь кенә егет иде. Чандыр булса да, аның тәнендәге мускуллар уйнап-тәгәрәп торалар, һәм моны күреп тору да күңелләргә хушлык өсти иде.

Халык чыгырыннан чыгардай булып гүли башлады.

— Комиссия!

— Батырларга ял бирегез!

— Ял итсеннәр!

— Ял иттермәскә!

— Билләрен бәйләргә кирәк, җитте!

Көрәшчеләргә ял бирделәр. Габдулла, әлеге көрәшче яшь егет, мәйданның бер читенәрәк барып чүгәләде. Янәшәсенә туры килгән карт көрәшчеләр «мунча ташына эссене өсти тордылар».

— Егетләр солтаны икәнсең, булдырасың. Тигезлә җир белән сырт сөяген! Ал да сал! Уңга сал! Сулга ташла!

Шулчак «комиссия» янында басып торган сылу кызый, кыска итәкләрен җыеп, килешле генә чүгәләп, янында торган өр-яңа чиләктән йомыркалар эләктерде дә Габдулла янына йөгерде.

— Мә, эчеп җибәр, — диде кыз ягымлы тавыш белән. — Тәнеңә хәл керсен.

Габдулла, утырган җиреннән генә кулын сузып, илтифатсыз гына кызга күтәрелеп карады. Әмма шул мизгелдә аның күңеле дертләп китте.

— Кара аны, сынатма! — диде кыз елмаеп, һәм йөгереп китеп тә барды.

Көрәшчеләрне янә уртага чыгардылар. Икесенең дә билләрен сөлге белән буып бәйләп куйдылар. Менә алар ипле генә якынлаштылар һәм капылт кына, билләрдән алышып, мәйдан уртасында бөтерелергә керештеләр. Габдулланың җан көчләре белән терәп баскан аяклары җирне сукалый башлады. Бу Баһавиның әкренләп егетне кысып китерүе иде. Әлбәттә, билләр бәйләнгәч җитезлек белән әллә ни алдыра алмыйсың, кем көчле — шул җиңә, ә Баһави авыррак та, көчлерәк тә. Мускуллар таш булып катты, кан тамырлары соң чиккәчә киерелеп бүртте, сулыш алырга һава җитенкерәми башлады. Һәм!.. Габдулла Баһавиның күкрәге астына атылып килеп тә керде, күтәреп тә алды, китереп тә салды! Мәйдан аһ итте. Халык кыршавы әллә ничә җиреннән берьюлы өзелде. Ир-егетләр йөгереп уртага чыктылар һәм сабан туе батырын чөяргә тотындылар.

Бер читтән тирләгән, арыган һәм шуның өстенә йөзендә эчкерсез елмаю балкыган батыр егеткә теге кыска итәкле кыз сокланып карап торды.

Кич җитте. Яшьләр болынга уенга җыелды. Җырлар, биюләр башланды. Габдулла күзләре белән болынны айкый торгач, ниһаять, аны эзләп тапты, якында гына икән. Егет салмак кына атлап килде дә кызның кулына кагылды. Шәһәр кызының йөзендәге елмаю көчәеп китте, очкынлы күзләрен сирпеп, ялт иттереп Габдуллага бер карап алды, биеп киттеләр.

Төн шундый матур иде, хәтта күктә тулган ай да тирбәлә иде бугай. Әллә нинди төн булды бу. Көрәштән соң сызланып торган иңбашлар кызның нәфис куллары кагылуга, үзеннән-үзе язылып киттеләр, арка буйлап хәмер зәүкымы таралгандай булды. Кызның таралып торган кара куе чәчләреннән килгән хуш ис Габдулланың муенында ышанычлы гына утырып торган башын җиңелчә әйләндереп җибәрде.

Ярсып-ярсып гармун уйный. Гармун моңы томан сыман бөтен авылны сарып, куенына туры килгән һәрнәрсәне — йортларны, киң ябалдашлы тупылларны, яр буендагы сыгылма билле талларны, егетләрне, кызларны назлый, иркәли иде.

Инеш ягыннан исеп-исеп куйган талгын җил белән бакаларның бетмәс-төкәнмәс мәхәббәт җырлары агылып килә дә, моңлы авазларда тирбәлгән бу болынга үзенә бер илһамлык, сихрилек һәм мәгънә өсти иде.

Уен таралгач, Габдулла Ләйсәнне өенә озата китте.

\+ + +

— Нигә бер сүз дә сөйләшмисең, Апик, әллә телеңне йоттыңмы?

Габдулла, кыз култыклап алганнан соң, чынлап та телдән калган иде. Бер сүз дәшми бару кыен, ни дә булса әйтергә кирәген ул бик яхшы белә, тик тел ачкычлары гына әллә кайда җуелган булып чыкты. Бераз аптырап барганнан соң ул, тотлыгыбрак:

— Иртәгә утынга... урманга барасы бар әле, — дип әйтеп куйды.

Ләйсән кичке тынлыкны яңгыратып көлеп җибәрде. Әле кайчан гына, нинди таза көрәшчеләр каршына чыкмасын, тып-тыныч килеш күкрәк киереп торган Габдулла тәмам югалып, бөрешеп калды.

«Их, агач авыз, кызлар белән утын турында сөйләшәләр димени, тумран», — дип үз-үзен сүкте. Әмма эш үткәч үкенүдән ни файда. Ләкин кыен хәлдән ничек тә котылырга кирәк иде. Рәхмәт төшкере, гомер булмаганны, тел очына кирәкле сүз килеп кунды:

— Урманнан сиңа нәрсә алып кайтырмын дип уйлап барам әле менә.

— Ой, Апик, ни алып кайтырсың икән?

— Алып кайткач күрерсең, — диде Габдулла мәгънә белән. Әмма күкрәген тынычсыз уй сыдырып үтте: «Нәрсә алып кайтырмын икән соң?»

— Алайса әйтмә, әйтмә! Әйткәч кызыгы да булмый аның. Сюрприз ясарсың! — диде кызый, каударланып. — Бик күңелле булыр.

Ләйсән Габдулланың беләгеннән кысыбрак тотып, сыеныбрак атлый башлады. Егет үзен күкнең җиденче катында итеп тоя иде. Ничә төннәр керфек какмый хыялланган мәхәббәт килгән! Ул шундый якын, ул аны тоеп атлый, юк, атламый, ә оча иде, ахрысы...

Габдулла шулкадәр сак, кызга кагылып китүдән дә шөлли, әйтерсең тегесе иңбашына килеп кунган кошчык, ялгыш хәрәкәт ясасаң, куркып очып китүе бар.

Ләйсән Габдуллага сынаулы караш ташлаштырып бара торгач, кинәт, каршына чыгып, аның күзләренә туп-туры карады.

— Мин сине шундый көрәшче дә булгач, кызлар белән ут кебексеңдер дигән идем, ә син киресенчә артык тыныч, битараф икәнсең. Әллә кызлар белән бер дә йөргәнең булмадымы?

— Әйе, — диде Габдулла, авыр сулап. — Булмады.

Ләйсән пырх итеп көлеп җибәрде, аннары:

— Ух, сине, — дип, бармак янап алды.

— Менә килеп тә җиттек, — диде Габдулла җитди генә. — Сезнекеләр йокламый, ахры, утлары җете яна.

— Бездә кунаклар! Әйдә керәбезме?

— Төн бит инде хәзер, Ләйсән, — диде ул, пошынып, — уңайсыз ич, тиктомалдан...

— Нишләп батыр кешегә уңайсыз булсын ди. Аннары бит бүген синең көн! Әйдә инде!

Ләйсән Габдулланың кулыннан тотты. Кызның кулы кайнар һәм йомшак иде. Юк, бу кулдан кулны тартып алу мөмкин түгел. Габдулла күндәм генә кызга иярде.

Өй кунаклар белән шыгрым тулы иде. Табын мул, кунакларның йөзе килгән, мәҗлеснең чилләсе иде әле монда. Бусагадан атлап кергән шәпкә Ләйсән ярып салды:

— Гайфулла абый, менә батырыгызны тотып алып кайттым. Кая куясыз?

— Үһу, әйдүк, әйдүк, түрдән уз, Габдуллаҗан энем, уз, уз! Синең шикелле баһадирларга оялып тору килешәмени ул? Әйдә, кызым Ләйсән, син дә, әйдә, әйдә. Менә шулай...

Ләйсән белән Габдулла игътибарның кыл уртасында калдылар. Мәҗлес бердәм гүли башлады.

— Штрафнуйны бирергә бу асыл кошларга, штрафнуйны!

— Праулни!

— Соңга калып йөрмәсеннәр, эме...

Габдулла, кызарынып, бер ноктага карап тик утырды.

— Тутырып сал, кем, Гайфулла, тутырып сал! Мөлдерәмә булсын.

— Тимерче Баһавины күтәреп тондырганны, моны каплап кую аңа чүп тә түгел, һи-һи-һи.

Ләйсәннең тустаганы, Габдулланың стаканы мөлдерәмә тутырылды. Гайфулла абзый, үзенең чәркәсен күтәреп, «Алмагачлары» көенә җырлап та җибәрде:

Стаканың төпләрендә
Советский келәймә,
Ал, күтәреп эчеп җибәр,
Келәймәсен күр әйдә!

— Җәмәгать, кыстагыз әле шуларны, утырмасыннар, мин сиңа әйтим.

— Юк, юк, куясы түгел, Габудуллаҗан энем, юу-ук, шулай, бездә шулай.

— Бетереп, бетереп!..

— Һай, рәхмәт төшкере, күптән шулай кирәк иде.

Габдуллаҗанга эчеп җибәрмичә һичнинди чара калмады. Ашыгып кабымлыкка үрелгәндә, яшьләнеп киткән күзләре Ләйсәннең чыраен да сытмый рюмканы ялт иттергәнен күреп калды.

Көне буе алышулардан соң арыганлык үзенекен эшләде, беренче чәркә үк эчми эчкән Габдулланың маңгаена чүкеч белән утырткандай итте. Озатырга чыккан Ләйсән аны кулларыннан алып әллә ниләр сөйләнде, әмма Габдулла берни аңламады, пыялаланган күзләре белән аңа карап торды, торды да, чайкала-чайкала өенә кайтып китте.

Әмма йокы аны алмый интектерде. Ләйсәннең мөлаем йөзе күз алдыннан китми генә бит. Аңа әйтәсе ягымлы сүзләр байтак җыелган икән. Шуларны әйтеп, кулларыннан, чәчләреннән сыйпыйсы иде үзен... Габдулла хыялларга чумып онытылды, ә иреннәре гел бер сүзне пышылдады: Ләйсән, Ләйсән, Ләйсән...

Таң алдыннан гына йокыга талган егетне иртән-иртүк әтисе уятты.

— Тор, Габдуллаҗан, тор, улым. «Тор-тор»дан хәбәр килгән, ыһым. Бар, юын да җәтрәк ашап ал, озакламый Сәлимең «Белорус»е белән килеп җитәр, кузгаласыгыз бар.

Урманнан кайтканда вакыт соң иде инде. Утын алып кайтучылар өйгә кереп табынга утырдылар. Мактый-мактый токмачлы аш ашадылар. Аш астына, аннары аның өстенә, аннары ахыргысын, ахыргысы артыннан соңгысын, соңгысы артыннан йомгаклап, тешкә йомшак нәрсәне тиешле урынга озаткач, юл аягына тоттылар да, саубуллашып йортларына таралдылар.

Ярты метрлы галошлар өстерәп, дусларын озата чыккан Габдулла ишегалдында озак басып торды.

Нишләргә? дип аптырап уйланды егет. Урманда Ләйсәнгә лаек бер әйбер дә табылмады. Инде килеп, чәчәкләрдән абага яфракларына төреп ясалган бәйләмгә дә (Габдулла аны юл буе саклап кына кулында то-

тып кайткан иде.) кабина эченә туктаусыз тулып торган солярка исе сеңгән булып чыкты. Кинәт Габдулланың карашы бер әйбергә ябышып туктап калды.

Хикмәти Ходa! Бүрәнәләр өеменең очындарак нәрсәдер ялт итеп янып тора. Тик ни ялкыны, ни төтене юк! Тукта, нәрсә соң бу?!

Габдулла тиз генә өем өстенә үрмәләп менде һәм утка үрелде.

— Һай, егетләр! — дип кычкырып куйды Габдулла, — утын түмәркәсе ич бу!

Шул түмәркәнең уртасындагы черектән яктылык сибелеп тора иде.

Егет утын лапасыннан тиз генә эш кораллары салынган әрҗәне өстерәп чыгарды. Түмәркәнең сау өлешен түгәрәкләп китеп төшерде. Ә аннары ышкы белән ашыкмыйча, сакланып кына табылдыгын шомартырга кереште.

— Һәйбәт. Бик һәйбәт, — дип куанды ул эченнән. — Шәп була бу!

Чыннан да, җыйнак кытай фонаре сымак булып калган агач кисәгенең бер башында ут янып тора иде.

— Менә бит ул Ләйсәнгә дигән бүләк, — дип шатланды ул. — Бер дигән!

Икенче кич алар очраштылар. Габдулла Ләйсәнне биергә чакырды.

— Кичә нигә килмәдең, Апик?

— Урманнан соң кайтылды. Без кайтканда уен таралган иде шул.

— Ә мин сине көттем дә көттем, — диде Ләйсән моңсу гына, ә аннары кинәт ачылып: — Кстати, син миңа нәрсә алып кайттың соң урманнан? — дип сорады.

Габдулла Ләйсәнгә сөеп карады. Аңа рәхәт иде. Аның күңеле кызның гүзәллегеннән тәмам тәслим булган; менә шулай сөйләшә-сөйләшә биюдән ләззәтлерәк ни бар икән соң бу дөньяда.

— Кайтканда алып чыгып бирермен инде. Мин аны печәнлектә калдырганмын. Йоклар алдыннан озак кына карап яткан идем. — Аннары пышылдап кына өстәп куйды: — Сине уйлап...

— Әйдә хәзер үк киттек, минем хәзер үк күрәсем килә! Әйдәме?

Ләйсән кайнар кулы белән Габдулланы кулыннан өстерәде:

— Пошли, — диде ул, балаларча сузып.

Габдулла Ләйсән әйткәч җир читенә китәргә дә әзер иде. «Әйдә икән, әйдә генә, бәгърем!» дип әйтәсе килде аның. Ләкин шундый зур сүзне ничек кычкырып әйтмәк кирәк.

Ләйсән белән Габдулла яшелгә буялган урыс капка турына килеп җиттеләр. Капкадан шым гына үттеләр дә абзарга керделәр.

— Хәзер алып төшәм мин аны, көтеп тор, яме, Ләйсән, — дип пышылдады Габдулла.

— Апик, мин дә синең белән меним әле, печән исе иснисем килә.

— Соң, печән былтыргы бит, — дип куйды Габдулла, гаҗәпләнеп, — аның нәрсәсен иснисең?

— Барыбер меним инде, ә? Монда әллә нәрсәләр кыштырдый.

— Мен соң алай булгач, рәхим ит, Ләйсән.

Тавык тизәкләре ябышып каткан баскыч буйлап, әкрен генә өскә күтәрелделәр.

— Саграк, Ләйсән, тавыкларны уятмыйк, менә монда гына ул. Хәзер, хәзер! Менә ул. Менә! Ә-ә! — дип тотлыгып тавышы киселде Габдулланың. Дөнья әйләнеп киткәндәй булды. Кичәге ут бүген янмый иде! Габдулла, тәмам каушап, беткән тавыш белән: — Кичә менә моның бу башында ут яна иде, — диде. Аңа кыз алдында уңайсыз иде. «Нәрсә булган соң моңа, нәрсә булган?!»

Шулчак Ләйсән сәер генә көлеп куйды.

— Ой-яй, Апик, нинди хәйләкәр син! Ничек оста итеп мине монда алып мендең, ә? Ха-ха. Нәрсәнең макеты бу? Ух, сине. Не думала!..

Һәм, әкренләп, Ләйсән аңа елышты-елышты да, ныгытып кочаклап ук алып, кайнар иреннәре белән Габдулланың нәрсәдер әйтергә дип ачыла башлаган авызын томалады.

Тышта өзеп-өзеп сандугачлар сайрый, күктә саран гына елмаеп ай йөзә иде.

## АУ-У-У!

Өченче сыйныфны тәмамлагач, әти белән әни мине авылга, туган тиешле Һаҗәр апаларга кунакка кайтарып җибәрделәр.

Кайтмыйм дип, юкка кәҗәләнеп торганмын икән, анда бик күңелле булып чыкты. Көннәр буе малайлар белән су коенам, балык тотам, туп тибәм. Табигать тә күңелгә хуш килде. Саф һава. Ике як яры куе таллыкларга чумган инеш бер көйгә генә агып ята. Чылтырап аккан чишмәләр дә, сандугачлы таллыклар да, төрле-төрле чәчәкләр арасында куышлы уйнаган күбәләкләр дә, зәңгәр күкне айкап, атылып очып, кырларны, басуларны җырга коендырган тургайлар да бирелә икән. Авыл үзе дә бик матур, Артышлы тау башыннан карасаң, аны бөтенләй танымый торасың, нинди урман икән соң бу, дисең. Бөтен җирдә алма бакчала-

ры, тупыл, шомырт, балан, миләш, канәфер агачлары. Аяк астында яшел чирәм, баш өстендә зәңгәр күк һәм анда нәни сарык бәрәннәренә охшаган бөдрә ак болытлар йөзеп йөри.

Минем көне буена ике кулыма бер эш — уен. Әмма һич җиткереп булмый шул көн дигәнне, сизми дә калам, ул үтеп киткән була. Ә кич җиткәч, урамны тутырып, тузаннар туздыра-туздыра көтү кайта. Кәҗә, сарык тавышлары уеныбызны иң тәмле, иң кызыклы җирендә өзә — дус малайлар көтү каршыларга сыптыралар, миңа да өйгә кайтырга туры килә.

Кайткач, Һаҗәр апа аркамнан сөя-сөя яңа сауган сөт эчерә. Их, аның тәмлелекләре, кибетнекеләр бер кырыйда торсын!

— Эч, эч, Сафа балакай, уңайсызланма, — ди Һаҗәр апа, кытыршы кулы белән чәчләремнән сыпырып. — Куркып эчмә, сөт күп...

Менә берзаман күктәге ай бик җете ялтырый башлый. Мин өскә ак күлмәк, «этеп егарлык» итеп үтүкләнгән чалбар, аякка чия төсле туфлине киеп, щетка белән ялык-йолык иттерәм һәм без, Әлфинур апам белән икебез, болынга, кечке уенга чыгып китәбез.

Ә болында егетләр-кызлар ду килә! Бииләр, «Наза», «Тимерчыбыклы» уйныйлар. Ә иң соңыннан, бөтенесе бергә җыелып, әллә нинди матур-матур җырлар җырларга тотыналар.

Минем яшьтиләр дә монда. Без, серләшеп, болынны әйләнеп йөрибез, куышып китәбез. Җырлар башлангач кына, уеннарыбызны ташлап, авызларыбызны ябарга онытып, тынып калабыз. Җыр тыңлыйбыз. Мин әллә ничә тавыш арасыннан Әлфинур апайныкын табып, аерып тыңлыйм. Беренче көнне үк бөтен кызларны күздән кичердем һәм иң матуры Әлфинур апам дигән нәтиҗәгә килдем.

Әлфинур апамның дулкынлы коңгырт чәчләрен үреп салган ике калын толымы, тулы чия ireннәре, борын читләренә әз генә сипкел кунган якты йөзе, нур бөркеп торган күзләре мине әллә нишләтәләр иде.

Өйгә кайтышлый безгә баянда уйный торган Һади абый иярә. Капкага килеп төртелгәч, апам кереп китмәкче була. Тик Һади абый аны кулыннан эләктереп ала да җибәрми интектерә.

— Бар, энем, мине ишегалдында көтеп тор, әни сизә күрмәсен, — дип пышылдый апам колагыма.

— Апаңа әйтәсе сүзем генә бар, хәзер керер, Сафа дус, — дип ялагайлана Һадие.

Мин аңа каш астыннан гына карап алам да кереп китәм.

— Нинди бетмәгән сүздер инде ул көн саен, — дип уйлыйм ачу белән.

Аннары өйалды баскычына утырып апамны көтәм. Менә бераздан ул да керә, яныма утыра. Тын гына, сөйләшми генә йолдызларны күзәтәбсз. Апам мине кочаклап ала... Миңа рәхәт тә, әллә нишләп бераз уңайсыз да...

Ур-ра!.. Бүген апам белән икебез генә урманга җиләккә барабыз.

Юл буе мин аңа Казанда барган кызыклы яңа кинолар турында такылдыйм. Без атлап барган тузанлы юлның ике ягында офыкларга барып тоташкан алтын арыш басулары, ә каршыда зәңгәрләнеп торган урман.

Сөйли торгач, мин, ахрысы, кызып киткәнмен, нәрсәгәдер абынып егыла яздым, ярый әле тотып калдылар! Һәм мине тотып калган кеше... Һади абый иде.

Минем, билгеле, кәеф кырылды. Апа да дәшми. Һади абый да, мин дә. Шулай урманга барып кердек. Аннары бардык, бардык, бардык та, бик матур аланлыкка килеп чыктык. Мондагы җиләк-к!

Сузылып ятып җиләк чүплим, ә үзем күз кырыем белән апамны күзәтәм. Ачу китереп Һади абый гел аның тирәсендә бутала. Күреп торам, йә бармагы бәрелеп китә апама, йә җиң очы. Менә ул аны кочаклап алыр да, апам шуңа бик тә рәнҗер кебек тоела башлады. Нишләргә соң?

Ярый әле Казанда чакта дус малай күрсәткән фокус искә төште, кулымны чирәмгә куеп, кепкам белән капладым да:

— Һади абый! Бер әйбер тоттым, карале, нәрсә икән ул? — дип кычкырдым.

Тынымны кысып кына торам, Һади абый йөгереп килеп тә җитте. Кепка астында кукиш ясаган кулымны кырмыскалар тешли башладылар.

Мин:

— Тешли! — дип кычкырып җибәргәнемне сизми дә калдым.

— Кайда? — дип сорады Һади абый, кабаланып.

Ул арада апам да килеп җиткән.

— Кайда, нәрсә ул? — диде ул, куркып.

Мин бармакларымны үзгәртергә теләмәдем. Һади абый сак кына кепкамны күтәрде. Шаккатып бер апама, бер миңа карый. Ә мин, маңгай астыннан гына сөзеп, аңа карап торам.

Һади абый шаркылдап көлеп җибәрде, аңа апам кушылды, ниһаять, мин дә көлми түзә алмадым.

Җиләк җыябыз. Һади абый да, апам да, мин дә. Җыям дигәч тә, икесен кабам, берсен банкага салам инде. Кая карама каен җиләге, тегендә дә кып-кызыл, монда да, анда да.

Берзаман җиләк дип йөри-йөри мин апаларны бөтенләй хәтердән чыгарганмын. Вакыт та хәйран үткән бугай. Шунда каяндыр:

— Ау-у! — дип кычкырган Һади абый тавышын ишеттем.

— А-а-а-у-у-у! Сафа-а! — Монысы апамныкы иде.

— Ау-у! Апам!!! Мин монда-а!!! — дип җавап күндердем. Безнең тавышлар шундый яңгырыйлар. Бер кычкырган сүз икешәр, өчәр тапкыр кабатланып, яңгырап килә.

— Ау-у-у! — дип кычкыра Һади абый. Аның көчле тавышы агачларга бәрелә-сугыла, чәрдәкләнеп, әллә ничәгә әйләнеп килә төсле.

— Ау-у-у! — Апамның йомшак тавышы агачларга бәрелмичә, әйләнсп уза-уза, дулкынлана-дулкынлана килә сыман.

— Ау-у-у!!! — Монысы минеке, башта һаман агач очларына табан өскә менәргә һәм апамнарга җитәрәк, кыйгачлап, аска төшәргә тиеш шикелле.

— Ау-у-у!

— Ау-у-у!

— Ау-у-у!

Шулай кычкырыша-кычкырыша теге матур аланлыкка җыелдык. Әллә кояш баеганга микән, апамның битләре алсу-алсу, ә күзләре шундый нурлы! Ике бит уртасында ике кояш балкыган йөзе дә, борыны һәм колак очлары да елмаялар төсле.

Һади абыйның да йөзе көләч иде...

Кайткан чакта алар икесе арттан, ә мин, бер биш адым ара калдырып, алдан кайттым.

Гөрлиләр...

Бик моңсу иде миңа. Әллә нишләп елыйсым да килә иде...

+ + +

Авылга яңадан алты ел узгач кына кайтырга туры килде. Һаҗәр апа картайган икән инде. Күзләре елап, шешенеп беткән.

— И бала, исәрләнмәсә генә ярый инде, — дип сулкылдый Һаҗәр апа. Ара-тирә әтиләрне, әниләрне сораштырган була да яңадан үкси башлый. — Нинди матур йортлар җиткереп чыктылар, икесенә болын хәтле өй, шуны бала-чага белән тутырып рәхәтләнеп яшисе иде бит кана. И Ходаем... Керфекләре бигрәк озын иде шул кияүнең, кыска гомерлегә булган икән...

Һади абыйның юл фаҗигасенә тарып харап булуын ишеткән идем. Кайтуым да, апамны юата алмаммы, дип иде.

— Әлфинур апа кайда соң?

— Үз өендә. Әни, бар кайт, үземне генә калдыр, ди. Йа Рабби, гакылын гына җуймаса ярар иде. Балакаем.

Һаҗәр апа такмаклап калды, мин әкрен генә чыгып киттем. Әлфинур апаларның өйләре авыл башында икән. Ул берьялгызы өстәл читендә утыра иде. Мин килеп кергәч, сискәнеп, борылып карады... Йа Хода, күзләре генә утырып калган...

Бер-беребезгә карашып тик торабыз.

— Сафа... — дип пышылдады, ниһаять, апам карлыккан тавыш белән, аннары өстәл читенә ябышып, этенеп урындыгыннан авыр гына күтәрелде һәм ышанычсыз адымнар белән миңа таба атлады.

Аның элекке алсу йөзе агарып, хәтта бераз зәңгәрләнеп, тартылып каткан иде. Менә ул адымын ялгышты, чалыш басты һәм морҗага килеп бәрелде. Аннары аңардан иңе белән этелеп янә кузгалды, һәм кием шкафы янында торган урындыкка килеп төртелде. Апам ничектер бик сәер, сукыр кеше сыман, сул кулын алга сузып атлый иде. Мин урынымнан кымшана алмадым. Була шулай, өстеңә ыжгырып машина килә, ә син ни уңга, ни сулга кузгалып китә алмыйсың, каккан казык сыман бер урында катып тик торасың.

Апам йөзе белән күкрәгемә капланды.

— Апа! Апа! Тынычлан. Апа җаным, үзеңне бетермә, нихәл итмәк кирәк...

Үзем юаткан булам, ә бугазыма йодрык кадәрле төен менеп кунаклады. Ләкин бу халәттән ничектер котылырга, үз-үземне кулга алырга, аңа нидер әйтергә, сөйләштерергә, нәрсә беләндер мавыктырып, авыр хәсрәтен беразга булса да онытырырга кирәк иде.

Һәм мин, булдыра алганча, тыныч тавыш белән:

— Әле генә килеп җиттем, апа, юл бик арытты, әйдә, самавыр куеп чәй эчик әле, — дидем.

Ничек кирәк алай самавырны гөрләтеп җибәрдек. Аннары аннан чәй, шикәр, икмәк таптырдым. Әмма өйдә нәрсәдер җитми, икебезне дә изә торган нинди дер әйбер бар шикелле иде. Ниһаять, аның ни икәне башыма менеп җитте — караңгылык икән — тиз генә утны кабызып җибәрдем... Өстәл өстендә гаилә альбо-

мы ята икән. Апам кырына утырып, шуны кулыма алдым. Беренче биттә үк бергә төшкән рәсемнәре... Икесе дә чибәрләр, елмаялар... Апам абайлап алганчы тиз генә икенче битне ачтым.

— Бу абый кем? Ә бу бабай? Ә менә бу матур кыз? — дия-дия һич кирәкмәгән әллә кемнәр турында сораштырып утырдым.

Самавыр кайнап чыккач, кара-каршы утырып чәй эчтек. Юк, апам матур икән әле.

Әнә бераз елмайган сыман да булып алгалады. Аннары мин кечкенә вакытымда ничек аны Һади абыйдан көнләгәнемне, аңа гашыйк булып йөрүемне сөйләдем. Урманда күрсәткән фокусны искә төшердек.

Сөйләгән вакытта ул йә сулкылдап куя, йә яше кипкән дәү күзләре белән сәерсенеп миңа карый.

Озак утырдык.

— Ярый, апа, кайтырга вакыттыр, — дидем мин, тәрәзәгә карап. Тышта караңгы иде инде. — Вакыт та соң, Һаҗәр апа да борчылып көтә торгандыр.

— Энем, китмә, кал, — диде апам, күзләрен тутырып. — Хәзер мин сиңа урын салам.

— Үзем, апа...

— Юк, юк...

Утны сүндергәч тә бераз сөйләштек.

Менә берзаман апамның сулышы тигезләнде. Аллага шөкер, йокыга китте бугай... Һәм мин дә, җиңеләеп, тыныч күңел белән йокыга талдым.

Ишек шапылдап ябылуга, сискәнеп торып утырдым. Апам караватына карасам — буш. Йөрәгем «жу» итеп китте. Тиз генә чалбарны кидем дә тышка атладым. Апам, коймага тотынып, бакчага карап тора иде. Мин акрын гына аның янына килеп бастым.

— Ишетәсеңме, Сафа, — дип пышылдады ул, миңа карамыйча гына.

Мин як-ягыма карангаладым һәм, куркып, апама текәлдем. Тирә-юньдә тып-тын иде.

— Алма коела...

Чыннан да, бакчада ара-тирә тып-тып иткән тавыш ишетелеп куя иде.

Минем эчкә җылы кереп китте. «Әллә апама Һади абый тавышы ишетелә микән» дип котым алынган иде.

— Өйләнешкән елны утырткан идек, — диде Әлфинур апам һаман да хәлсез тавыш белән. — Быел менә беренче алмалары...

+ + +

Апамны шуннан соң озак күрә алмадым. Армиядән кайткан елны да барып чыгып булмады авылга. Аның инде бу вакыт эчендә кияүгә чыкканын, балалары булганын ишеткән идем. Ә күрәсем килә иде аны.

Һәм менә быел, чираттагы ял аемның соңгы атнасында авылга кайтып төштем.

Апамның хәзерге ире Нариман исемле бер кеше иде, авыллар буйлап югары көчәнешле электр линиясе уздырып йөргәндә, апама өйләнгән дә төпләнеп калган. Колхозда механик булып эшли икән. Бик күңелле кеше, алтын тешләрен күрсәтеп елмаерга гына тора.

Өйдә бер көтү бала-чага, абзар тулы мал-туар, келәт тулы икмәк, мул яшиләр. Мондый хуҗалыкны өстерәү апама җиңел түгелдер.

Әнә ул ашыкмыйча гына табын әзерли, йөргәндә бераз алпан-тилпән дә килгән сыман... Минем сөекле Әлфинур апам гадәти таза тормышлы крәстиян гаиләсенең чын хуҗабикәсенә әйләнгән иде. Әмма кай төшедер һаман элеккечә матур. Елмаюы, ахры.

Табыннан кузгалгач, ишегалдына тәмәке тартырга чыктым. Башыма, «Тукта, бер бакчаларын әйләним әле» — дигән уй килде. Рәшәткә очларында сикеренгәләгән бер кошчык, мин килә башлагач, пыр итеп кузгалып, кояш баешы ягына таба очып китте һәм ноктага әйләнеп юкка чыкты.

Бакча, чыннан да, гаҗәеп иде. Нариман җизни уңган кеше булырга тиеш...

Монда гел урмандагы сыман, кая карама — алмагачлар, алмагачлар, алмагачлар... Баланнар, миләшләр, шомыртлар... Бакча уртасыннан өйне дә, урам ягындагы коймаларны да күреп булмый, тик ишегалдын гына бераз чамаларга була иде.

Кинәт, кайчандыр урман яңгыратып, «Ау-у!» — дип кычкырып йөрүләребез искә төште. Әнә апам башмак тананы сыртыннан сөя-сөя абзарга ябарга азаплана.

— Ау-у-у! Ау-у!!! Апа!

Башмак тана, апамнан ычкынып, ишегалды буйлап чабуларга кереште.

Мин яңадан:

— Ау-у! — дип кычкырдым.

Кайтаваз урынына Әлфинур апамның арыган, шелтәле тавышы яңгырады:

— Шаярма әле, Сафа, хайванны куркытасың бит!..

КГУГОМ КГИС

Җәй көне Казан елгасының шома таш плитәләр белән ныгытылган кыйгач ярында утыру бик хозур. Казанга килеп, студент чактагы дустым Камил Хәйруллинны очраткач, шешәләрнең хәмерлесен һәм шифалы сулысын эләктереп, шунда тукталдык... Ә элек бу ярга күбәүләп кунаклый идек...

Казан матур. Кай ягы беләндер Бакуга охшый. Киевның Днепр ярын хәтерләткән урыннары бар. Хәтта Истанбул чалымнарын төсмерләргә дә мөмкин. Кыскасы, Казан — башкалалар затыннан.

Зәңгәр киңлек, саф һава җанны иркәли, сулышны тирәнәйтә, гәүдәне турайта. Ә сагынып искә төшерерлек вакыйгаларның исәбе-хисабы юк.

Безнең авылның Мәүлә атлы бер абзый, улы Фәрхәт белән урманга, утын урларга баргач, иң әүвәле бер яртыны «урталай сындыралар». Бер караңгыдан бер караңгыга эштән башы чыкмаган Мәүлә агайның күңеле нечкәреп китеп:

— Әйдә, улым, кисмик утын. Утырыйк әле. Сәхрә бит бу! — дигән, имеш.

Дөрестән дә, бер утыру — бер гомер. Алай да шомлы мәкаль бу, Алла сакласын. Хикмәт, шешәләр бушауга бетмәс сүзләребез түкәнеп, кырыкмаса-кырык эшләребез искә төште һәм без кабалана башладык.

— «Акчарлак» тирәсенә ничек чыгып була? — дип кызыксындым мин.

— Юл бег генә, — диде дустым. Ул «р» хәрефе урынына «г» кулланучылардан. — Башта Казанка буйлап аска төшәбез, аннагы, богылып, тыкыгыктан өскә күтәгелеп, какыгаз консегватогия тугына килеп чыгабыз.

— У, ерак.

— Бег тугы юлы баг. Зигат аша. Шушылай тутыга китсәң, Әбҗәлилгә чыгып була.

— Киттек алайса шуннан.

— Киттек.

Үзәк парк янындагы зиратның арт коймасыннан кергәч, кылт искә төште, Хәйруллинны, шаяртып, зиратоман дип йөртә идек ләбаса. Ул зиратларда йөрергә ярата, һәм ялгыз да түгел, иптәш белән. Менә мин дә «кармакка» эләктем.

Әлеге зират тыштан гына яфрактан ташып, ямь-яшел булып утыра икән. Яшеллек — бөҗра гына булып чыкты. Эчтәрәк агачлар — кайсы аягүрә, кайсы янтаеп, ботаклары белән һавага чытырдатып ябышып, тартышып җан биреп яталар. Ә тагын да түрдәрәк, ботаклары сәлперәйгән, кәүсәләре каралган, яфраксыз үле агачлар. Аяк астында ник бер тере үлән булсын. Бу зират эчендә җәй төсләре гел юк: ак, кара һәм аларның төрләре генә иде. Зиратны, әллә ни киң булмаса да, ансат кына кичеп чыгармын димә. Чып-чын лабиринт. Чардуганнар арасыннан барганда, адым саен тупикка төртеләсең. Кая карама Петровлар, Ивановлар, Сидоровлар һәм башка шундый исемнәр. Бара торгач бер кабер каршында ток тоткандай тукталып калдым. «Садрисламов Илһам Билалович» дип язылган иде мәрмәр ташка. Һәм аңа фото да беркетелгән.

Камил җилкәсе белән җилкәмә бәрелеп янәшә басты һәм:

— Бик матуг бег магҗа кызына өйләнгән булган инде бу. Һәм тегесе аны кая китегеп тыккан. Кгугом кгис бит...

...Бер таныш апа үзенең урыска кияүгә чыккан апасын җирләргә баруын сөйләгән иде, әллә нишләп шул сөйләгәннәр хәтердә яңарды...

...Урыс бит мәетне ашыктырмый. Өченче көн дигәндә, барып кердем тәки. Хәерче генә совхозның үзәктән читтәге бер авылы икән... Узган ел ук совхоз биргән яңа коттеджга күчә алмаганнар, стеналарын штукатурлап агарткannarын һәм ут керткәннәрен көтәләр икән... Безнең якта мондый өй бирсәләр, өч көндә эш итеп бетерерләр иде, ә болар урысның «должны», «обязаны», «положено» тройкасында җилдерүчеләрдән булганга, һаман алты почмаклы борынгы урыс өендә яшәп яткан булганнар. Почмакларда иконалар, асларында пыскып шәмнәр яна. Олы якта да шул, кече якта да. Кече якның яртысын зур мич били һәм кемнәрдер аның башында кымшангалый... Мичнең акшар күрмәгәненә дә байтак бугай. Урыста өй юуу, ел да өмә ясап, бүрәнәләрне, сайгак-түшәмнәрне пычак белән кыргычлап тазарту мәшәкате юк бит, шуңа күрә бүлмә такталарының да сөрем-тузан сеңеп каралган булуы гаҗәп тоелмый. Кергәч тә сул як почмактагы юынгыч астында күгәреп беткән чиләк һәм аның төнге чүлмәк вазифасын да үтәгәнен борын урамнан керешли җиңел сизә. Газ плитәсендәге дәү кәстрүлдә бокырдап ит пешә, аш исе бөтен өйне тутырган.

Хәдичә апа түр якта ята... Урыста бит мәрхүмәнең ике кулын да күкрәккә куйдыралар икән. Ә татарда алай түгел... Бер кул күкрәкне ябарга тиеш, икенчесе гаурәтне. Хәдичә апаның куллары күкрәктә тормый икән. Аптырагач, бау белән бәйләп куйганнар.

Чишеп җибәрүем булды, бер кулы урынында калды, икенчесе дөрес итеп ятты. Интегеп яткан икән Хәдичә апа. Аннары, башы очына утырып, ясин чыктым...

Җилкәмә кемдер кагылгач, уйларымнан айнып киттем. Камил икән.

— Әйдә... Менә монда аның тугы юлы.

Һәм Камил, тупикларны оста гына әйләнеп, Әбҗәлил тукталышына чыгарып та куйды.

— Нәгсә сөмсегең коелды? — дип кызыксынды ул.

— Чаллыдагы туганнан туган энекәш марҗа кызы белән шаярган. Малай туган. Камил дип исем кушканнар, — дидем мин. — Туганнарга, безгә хәбәр итәргә яхшысынмый, китәм мин аннан, — ди, имеш.

— Яшь чакта күңел магҗага тагтыла инде ул, — дип куйды Камил. — Әнә «Татагстан яшьләге»ндә язганнаг. Бег апа яза. Абыйсы магҗага өйләнгән булган. Башта әйбәт тогганнаг. Хәзег магҗа да, балалаг да моны «вонючий татагин» дип кенә «зуглыйлаг» икән. Хәег, дөгес әйтәләг. Сөннәтсез һәм тәхәгатсез угыс —ногмальный угыс. Ә тәхәгатсез татаг — ул, чыннан да, вонючий татаг инде. Энеңә яз, сасы татаг булуың белән котлыйм, диген.

— Тукта, баланың гөнаһы юк. Кеше үлмәгән, ә туган. Әнә Дудаевның да хатыны марҗа, ә ислам динен кабул иткән.

— Чечен батыг һәм гогуг халык. Ә татаг егете магҗа белән көгәштә гел аста кала. Гадәттә, магжа батыг кала.

— Димәк, бернинди яктылык та күренми синеңчә?

— Синең алагда бег эшең дә юк. Үз балалагыңны гына кага... дус кеше...

## ТОТЫНЫРГА САЛАМ БАРМЫ?

*(Җүләр кеше язмалары)*

### ӘГӘР ҖҮЛӘР БУЛСА, ДӨРЕСЕН ӘЙТЕР...

Татар халкы дөреслекне, әлбәттә, белергә тиеш, ләкин кем соң аны аңа әйтер? Түрәме? Галимме? Президентмы? Язучы яки табиб, экстрасенс яисә журналистмы? Прокурормы? Милиционермы? Артистмы? Игенчеме? Эшчеме? Боларның һәркайсының дөреслекне ярып салу ихтималы бар барын, әмма бер генә очракта — акылларына зәгыйфьлек килгәндә генә. Чөнки акылы камил түрәнең — кәнәфиен, бизнесменның байлыгын югалтасы килми; артистның роль һәм исем, язучының Тукай премиясе аласы, профессорның академик буласы бар; ә депутатның җимле тагарактан коры каласы килми. Игенче яки терлекче дөрес сүз такылдый башласа, терлек азыгыннан мәхрүм итәчәкләр. Әйе, бары тик ычкынган кеше генә моны рәхәтләнеп эшли ала.

Әйтик, аның өчен ГАИ хезмәткәренең легендасы — юлда хәвефсезлек тәэмин итү, ә асыл максаты — автосөючеләрнең кесәсен юкарту.

Прокурор закон сагында торучы дәүләт хезмәткәре санала. Ә аныңча, ул — үзе хезмәт иткән биләмәдә законнарның эт табигатендә, ягъни гади эш кешеләрен өзгәләп ташларга, ә түрәләр — аларның яраннары башмагын яларга әзерлеген тәэмин итүче.

Укытучы — белем бирүче. Ә аныңча, ул Мәскәү таккан-юллаган программа, чыганаклар ярдәмендә балаларның баш миен чамадан тыш күп, кирәкле-кирәксез, шул исәптән ялган информация белән дә доңгычлаучы. Нәтиҗәдә, укытучы ихтыярына буйсынып, бишкә генә укучылардан остазлары сыман мескен мөгаллимнәр, галимнәр, офицерлар, каләм ияләре, функционерлар һәм вак-төяк җинаятьчеләр чыкса, икелегә, өчлегә укучылардан зур-зур түрәләр, бизнесменнар, җинаятьчел авторитетлар борынлый... Ягъни милләтләрнең каймагы, иң аңлы өлеше, мәгълүм бер конкурентлар файдасына нейтральләштерелә. Ә Муса Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театры, ычкынган кеше фикеренчә, Җәлилнеке дә, татарныкы да түгел, үткәргән фестивальләре дә кемнәрнеңдер ниндидер халыкара җыеннарын маскировкалау һәм финанслау өчен генә кирәк...

...Кеше күңеле маятник сыман гел тирбәлештә. Әмма һәркемнең рухи түшәме төрлечә, кемнәрдер галәмнәрне иңләп тирбәлә һәм, әлбәттә, андыйлар өчен «ычкыну» ихтималы да күбрәк, ә кыска амплитуда белән тырт-пырт килүчеләргә мондый «бәхет» сирәк тәти, чөнки рух йөген күтәреп торучы күңел кыллары да нечкә, нәфис түгел, ә кыска, юан һәм корычтай нык...

Ә мине исә, «ычкынганга» санап, махсус хастаханәгә тыгып куйдылар...

Хәтердә, палатага урнашуга, кичке аш китерделәр: кызыл винегрет, манный боткасы, чәй, өч телем ипи һәм армиядәге сымак 20 граммлы май кисәге.

— Син яңа бит әле, — дип кызыксынды аш китерүче.
— Әйе, — дидем.
Бу шуны ишеткәч, май кисәген шыпырт кына кире алып куйды...
Икенче көн иртән янә ашарга китерделәр: ботка, чәй, өч телем ипи һәм янә май шакмагы.
— Сине кичә генә китерделәр бит әле, — дип кызыксынды кичәге танышым.
Мин ак майны тиз генә кабып йоттым да:
— Әйе, — дидем.
Ашчымның ягымлылыгы шундук эреп юкка чыкты, йөзенә каралар коелды һәм ул:
— Итәрсең аларны дурак! — дип сукрана-сукрана янымнан рәнҗеп китеп барды.
Ә бит мин дөресен сөйләп харап булган кеше! Аңлыйм: «Кеше ышанмастай сүзне чын булса да сөйләмә!» — дигәннәрен дә бик беләм, әмма түзеп булмый. Оча торган тәлинкәдә сәяхәт итеп кайтканнан соң күргән-белгән, төшенгәннәрне сөйләми ничек түзәргә? Хәер, бездә дөрес сүзгә кем ышансын, кул гына селтәделәр. Ә мин, җүләр, исбатларга тырыштым һәм, ахыр чиктә, тырышлыгымның нәтиҗәсе шул булды.
— Мин — нормаль, акыллы кеше, — дип карыйм мондагы табибларга.
— Әйе, син акыллы, — дип аркадан сөяләр, тынычландыралар.
Баксаң, үзеңнең камил акыллы булуыңа ышандыру биредә дә мөмкин түгел икән. Инде бердәнбер юл калды: көтәргә! «Авыруым» турында фәнни мәкаләсен язгач, бәлки табибым миңа «әйләнеп кайтыр» һәм аның сорауларына «дөрес» җавап бирсәм, фәкыйрегезгә эчке җүләрләр дөньясыннан тышкысына капкалар ачылыр...

## КУКУРУЗДА ИКӘН ЧИКЛӘВЕК

Кәгазь аз, карандаш кыска булу сәбәпле, ничегрәк «тәлинкәгә» эләгүемне язып тормыйм. Әмма анда ниләр күрүемне, ниләр ачыклавымны халык белергә тиеш!..
Кешенең чәч-сакалы, чыннан да, антенна хасиятле галәмнән безгә информация килә һәм безнеке дә «югарыга» тапшырыла икән; димәк ки, кире элемтә дә бар һәм система эшли дигән сүз. Пыяласыман тышчалы оранжереядә димме, кукурузга тартым шәхси үсемлегең, көндәлек гамәлең, уй-хыялларыңны теркәп, «чәкәне» көн дә бер орлыкка арта бара. Шул «орлыкка» махсус аппараттан нур юнәлтсәң, бәндәнең, әйтик, үткән көнен монитордан карап була. Шунсы да бар, «орлыкларның» төсен кылган гамәлләр билгели. Күрәсең, ахырдан дөм кара чәкәннәр тулаем, ала-колаларының каралган өлеше ут хөкеменә бирелеп, шәхеснең уй-хыялларын, яшәешен саклаган информация мәңгегә, тулаем яки өлешчә шул рәвешле юк ителәдер.
...Бермәлне гәзитләр, мәшһүр бер сәясәтчебезне суга тотып аттылар, дип язды. Вакыйганың асылда ничек булуын бик беләсе килеп калган иде, тәки җае чыкты. Кызык фильм кебек карадым мин булып үткән хәлләрне. Ә ул болай булган икән.
Ул машинасы белән биек бер йорт янына килеп туктады. Баксаң, бер сәнгать йолдызы фатирына кунакка килүе икән. Тегесе каршы алды һәм әзер табынга утыртты. Каһарманыбыз, кесәсеннән телефон алып, үзенең урамда калган шоферына, иртән фәлән сәгатькә килерсең дип, әмер бирде.
Болар ашап-эчеп, тартып, тәмле әңгәмә корып утырганда, ваннадан халат кигән бер шәп гәүдәле кавказлы килеп чыкмасынмы. Ханым, ике ирне татуландырырга теләп, матавыкланды, әмма, аңлаша торгач, соңрак килгән кунакның бугазына пычак очы терәлде. Кавказлы швабра сабын кунакның пинҗәк җиңеннән тыгып аркасы аша үткәрде һәм икенче җиңеннән чыгарды. Ни өчендер көндәшенең ботинка бауларын чишеп, балак очларын, кул астына туры килгән тастымаллар белән швабра сабы шуып чыкмасын диптер инде, җиңнәрен, бер дә иренмичә, буып бәйләп куйды... Аннары кухняда торган аптечкадан флакон алып кружкага бушатты һәм янә «татардан да яманрак» кунакның бугазына пычак терәп, әлеге сыеклыкны эчәргә күндерде. Шуннан соң бөркет карашлы егеткәй моны этә-төртә башта коридорга чыгарды, аннары лифтка җайлап кертеп, соңгы катка алып төште һәм артына тибеп урамга озатты. Шуңа кадәр азмы-күпме тынычлык саклаган сәясәтчебез, сабыры төкәнеп, «Кайнар кан, понимашь. Ну, гад, сабыр ит. Мин әле синең бөтен нәсел-ыруыңның арт сабагын укытырмын, Каф тавыңның астын өскә китерермен, сам не рад будешь», — дип янады.
Ә кавказлының тамчы да исе китмәде, сызгыра-сызгыра хыянәтчел һәм талымсыз гүзәлкәе янына ашыкты.
...Урамда калган пәһлеван гәүдәле дустыбыз исә, ике кулын як-якка тырпайткан хәлдә, йөри торган тәре сыйфатында алга атлады. Юлында очраган кешеләргә мөрәҗәгате уңыш китермәде, бар да куркып, читкә тайпылды. Җитмәсә, теге мәлгунь эчерткән нәрсә пурген булып чыкты, һәм Мишка Горбачев әйткәндәй, «процесс башланды». Алай да дөньяда мәрхәмәтле кешеләр бетмәгән икән, бер исерегә килеп:

— Фу. Син нәрсә, братан, астыңа җибәрдең мәллә? — дип сораша-сораша, бичараны швабра сабыннан азат итте.

Сәясәтчебез коткаручысына сәгатен салып биргәч, исерек ифрат шатланды һәм, җәһәт кенә чүгәләп, юмарт танышының балак очларын буып торган ботинка шнурларын да өзеп атты... Соңгысы кирәк тә булмаган икән, сыеклык агып чыгып ботинка эченә керде һәм сәясәтчебез йөргәндә чәп-чеп иткән тавыш чыга торган булды.

Бәхетенә, шәһәр уртасыннан аккан елга якын икән, бәлагә тарыган танышыбыз, исерек коткаручысы киңәше белән шунда төшеп, Мөхәммәт Мәһдиевнең Зарифуллины сымак, озаклап йөзде... һәм бер постовой милиционерның игътибарын җәлеп итте...

## КЕМ ИДЕК, КЕМ БУЛДЫК, КЕМ БУЛЫРБЫЗ?

«Тәлинкәчеләр» янында КЕШЕнең килеп чыгышы белән дә кызыксынырга җай табылды. Баксаң, Рәсәйдә саф кызлар ничек булса, галактикада да саф планеталар шулай сирәк очрый икән. Фәлән миллион еллар элек бер «тәлинкәче», галәм гизеп йөргәндә, Җиребезгә сугылып чыккан, һәм аны «харап иткән», ягъни аның чиста стериль суында коенып, керен коеп калдырган... Бәлкем әле, су суык булып, ихтыярсыздан пес тә иткән, ә ярга чыккач, олы йомышын да үтәгәндер.

Кыскасы, Җирдәге тереклек шундый калдыклардагы микроорганизмнардан башланганга охшап тора... Мондый мәгълүматтан соң, урысның «бог»ка табынуында, ... һәм бу сүзнең асыл мәгънәсен аңлау өчен татар телен белү кирәклегендә берәр хикмәт юк микән, дигән уй ихтыярсыздан сискәндерә...

Галимнәр хаклы, тормыш арбасы ары таба эволюция юлыннан тәгәрәгән, әмма акыл үзеннән-үзе, әлбәттә, пәйда булмаган. Янә «тәлинкәчеләр» төшкән һәм кайсы җан иясенә акыл орлыгы салып калдыру хакында бәхәс купкан. Берсенең гүзәл кошны, бәгъзесенең көчле, дәртле ерткычны, бәгъзесенең сөйрәлүчене, бәгъзесенең җитез, матур грацияле үлән ашаучы җәнлекне акыллы итәсе килгән. Әмма күп бәхәсләшүләрдән соң бер фикер: аккош, әйтик, болай да матур, арыслан болай да куәтле, алар үзләрен үзгәртүне зарур тоймаячаклар, иң ямьсез, иң шөкәтсез, иң котсыз җан иясен сайларга кирәк, тик шундый мәхлукның гына камилләшүгә көчле мотивациясе булачак дигәне җиңеп чыга. «Ә бу бичараның җәйран кебек грацияле, арысландай көчле буласы, коштай очасы, балыктай йөзәсе киләчәк һәм ул моңа ирешер дә», — дип, төкерек чәчә бер «тәлинкәче» галим, бинибая серле карашын кешелекнең тимераяк киеп фигуралы шуачак ерак киләчәгенә төбәп. Шулай итеп, нәкъ бездәге сайлауларга охшап, кызыл артын чәбәкләп йөрүче маймыл кандидатурасы өскә чыга һәм, шартлы рәвештә әйтсәк, «инаугурацияләнә». Аның миенә акыл орлыгы җирләштерелә... Җирләштерү сутын, җан ияләренең ми матдәләрен комбинацияләп ясыйлар. Һәм, әйтик, сарык мие матдәсе күбрәк тәшкил иткән сут кулланудан сарыкманнар, дуңгыз мие матдәсе өстенлек иткән сут кулланудан дуңгызманнар барлыкка килә. Материал күп булгач, мондыйракларны күпләп тәпәлиләр... Шул юл белән атманнар, бүреманнәр, мәчеманнәр, төрле хәшәрәтманнәр дә сафка баса, һәм, әлбәттә, аз булса да, тависманнар, былбылманнар һәм башка шундыйлар да онытылмый. Тыштан караганда бар да бертөсле маймыл булгач, киләчәктә кавем булачак өерләрдәге төрле эчтәлекле затлар бик табигый кушылышка да керә. Әмма төрләрне тәмам катнашып бетүдән мәхәббәт саклый, чөнки һәркем кавышу өчен рухташын эзли. Тотемизм да рухташлыкны танудан туган. Ә вампирлык яки кешеләр йөрткән җәнлек исемле кушаматлар исә тотрыклы җирлеккә таяна.

Ыруг, кабилә һәм халыклар барлыкка килү янә галимнәр язганчарак бара.

Әмма һәр кавемдә дә, әйтик, аккошманнар, башка затлыманнар өлеше кими, чөнки үзара низагларда дошман кавем дә, ил эчендә исә хакимияткә үрмәләгән үз хәшәрәтманнәре дә нәкъ шуларны бетерергә омтыла.

Дини мифологиядә оҗмахтан куылуга сәбәп булган алма хакында әйтелә. Мәгълүм ки, кешенең теш казналары, җимеш, яшелчә ашауга көйләнгән... Әмма аның миенә «тәлинкәчеме», кемдер шундый коткыны җиткергән ки һәм бу көннәрдән бер көнне чикләвек урынына җирдә аунап яткан баш сөякләрен ватып ашарга өйрәнгән. Мөгаен, ул елны, корылык килеп, җиләк-җимеш, яшелчә уңмагандыр һәм кешелеккә рекрутланучылар күпләп кырылгандыр. Әлбәттә инде, баш сөяген ватып, ми ашаганда, бер кабиләгә сарыкныкы, икенчесенә атныкы, өченчесенә юлбарысныкы, шакалныкы, бүренеке күбрәк эләккәндер. Ә бер кабиләгә, ач чакта карап торасыңмыни, үз тәрдәшләренеке белән тукланырга туры килгән, ахры. Күрәсең, алма әлеге ризыкның шартлы исеме... Һәм менә шушы токым тора-бара каннибализмнан этенеп китеп, үз-үзләрен «Ходайның кашка тәкәләре» дип игълан итә торган теория уйлап табуга, ахыр чиктә һәртөрле фашизм, расизм, евроцентризм, глоболизмнарга кадәр килеп җиткәндер. Вьетнам халкын напалм белән яндыру, дефолиантлар белән агулау, Япониягә атом бомбасы ташлап кешеләрне терелэй тәмугка кертү һәм башка вәхшилекләрнең нигезендә дә, тәгаен, кешенең шул чактагы ризыкка ориентациясе үзгәрүе ята. (Аннары

бүтән ориентацияләргә дә чират җитә. Без бала чакта «катится, катится голубой вагон» дигән җыр бик популяр иде. Ул чакта җырның асылын азлар аңлагандыр, хәзер ул «голубой вагон» Рәсәй илләренә килеп җитте.) Әйе, нәрсә ашыйсың, шуңа әйләнәсең, дигән гыйбарә бар. Һәм физик яктан бу шулайдыр да. Әнә татар гомере буе ат ите ашаган, һәм ул ат урынына эшләргә мәхкүм. Дөрес, кайберләренә яхшы, толпар ат дәрәҗәсенә күтәрелү дә язган. Шәп ипподромнарда, дөньякүләм бәйгеләрдә баш килүчеләребез байтак. (Хак, безнең Сәгъдиевләребез, Нуриевларыбыз бар! Һәм бу мәсьәләгә без алдарак киңрәк тукталырбыз әле.)

Кайчандыр татарда бүремәнлек өстенлек иткән. Әмма төрле кушылулар, әйтик, дуңгызның асылын шундук үзгәртә алмаса, бүренең сафлыгын югалтуы, бердәнбер бүрелектән төрледән-төрле эт токымнары күчешенә китерә. Карл Фукс — урыс татарны «собака», ә татар аны «дуңгыз» дип «зурлавын» язып калдырган. Минемчә, һәр ике күрше хаклы, чөнки аларның күңел күзләре шулай күргән. Менә ни өчен урыс җирендә мәетләр һаман җыелмый чәчелеп ята һәм моңа урысның исе китми, менә ни өчен ул башкаларның кабер ташларын да актарып ата, менә ни өчен Волга-матушка нәҗес канализациясенә әйләнде!

Теләсә кая таралып, теләсә ничек актарынып, җир-суын пычратып үрчи торган җиңүчән бу кавем дә инде бүген кимүгә йөз тота. Чөнки пычратучыга да, үз-үзен саклау өчен булса да, чисталык кирәк. Җитмәсә, башкаларга да пакьлек урнаштырырга мөмкинлек бирәсе килми, табигате рөхсәт итми. (Татарстан суверенитетына каныгу хикмәте-сере дә шунда.) Урыс үзен «медведь» димәкче, кайчандыр аю ашаган урысларда аюлык сыйфаты саклангандыр да, һәм андыйлар бу милләттә бүген дә дөм юк түгелдер. Әмма алар милләт йөзен билгеләүдән, без бүредән ничек, шулай ерак.

Әйе, нәселебез башын бүре итеп күрәсе килә. Тик безне «собака» дип таныйлар икән, ахрысы, аларда да хаклык бар. Кайчак үзара чәйнәшергә яратуыбыз да, ә бу яшәү өчен бик тә зарури сыйфат, шуннан киләдер. Әүвәл заман борынгы греклар безнең җайдак бабайларны кентаврлар итеп күргән һәм тасвирлаган. Татарда бүген исә ат һәм эт компонентлары өстенлек алган. Сугыш, афәт һәм үзара низагларда милләтнең затлы кушылмалары булган аккошман, тургайман, бөркетмәннәре кызганусыз исраф ителгән, бүремәннәребезнең байтагы этмәнгә әйләнеп, эчке капма-каршылык туган. (Хәер, зарар юк, киеренке бетон гади бетоннан ныграк була, цемент кына сыйфатлы булсын. Цемент дигәндә, мин динне күз алдымда тотам, әлбәттә. Үзем күргән-белгәннәремне язам, әмма шайтан шаяруларына тап булдым, ахры, дигән шөһбә дә күңелдән китми...) Әлбәттә, шәхеснең кайсы җәнлеккә якынлыгы, җәмгыятьнең социаль киселешендә дә чагылыш таба. Әйтик, бездә җитәкче кай ягы белән үзенчәлекле? Ул үзеннән астагыларга тончыга-тончыга өрә, ә өстәгеләр алдында койрык болгый. Күрәнә ки, буйсындырылган халыкларга җитәкчене этмәннәрдән күтәрәләр. Һәм шуңа да алар бүреләрне аямыйлар, бүре аулаучыга өстәп акча да түлиләр! Әйтик, Татарстанда дуңгызның баш саны миллионга җитсә дә сүз юк, ә бүре фәләнданәдән артмаска тиеш... Бүрегә карата геноцид халкыбызга карата авазадаш. Ягъни мондый канун безнең халыкның асылына каршы юнәлдерелгән. Һәм мондый канунны, әлбәттә, дуңгызманнарга ялагайланучы этмән депутатлар үткәргән. Әлбәттә, аучылык белән дә этмән җитәкчеләребез шөгыльләнә. Искәртәсе килә, үтергән өчен акча алу аучыны палачка әйләндерә.

Күп кенә каләм ияләребез авыз суы корытып мактый торган европалылар, аларның бәдәни җирлеге компонентлары, әлбәттә, безнекенә караганда чуаррак... Алар бит хәтта тургай йөрәгеннән, сандугач теленнән ризык әзерләп ашыйлар! Ә Кытай якларында елан, бака, мәче ите һәм һәртөрле бөҗәкләр дә дилекатес санала... Бүтән милләт төсле булырга өндәүчеләргә, рационны үзгәртәсе булмасмы соң? дигән сорау бирәсе килә.

Кайсы халыкта башкалар җитештергәнне үз өненә ташу, ягъни йомранманлык өстенлек алган, кайсыларда сарыкманлык көчле, көтү башы кәҗәгә ияреп йөрүне өниләр. Кыскасы, кеше, чыннан да, табигатьнең таҗы һәм табигатьтәге төрле-төрле үсемлекләрнең, җан ияләренең һаман саен югала баруы аның да рухына суга, фәкыйрәйтә...

Хуш, йомранлык, атлык, этлек, бүрелек һәм башка инстинктлар пропорциясе үзгәрештә йөрсен дә ди, ә кешелек орлыгы кайда яши? Милләт үзенең кешелек асылын кайчан югалта? Һәм кешелек асылын югалткан милләтләрне үзенә кушкан милләтнең асылы белән нәрсә була?

Мәгълүм булсын, кешелеклелекнең асылы, әлбәттә, телендә. Иң башта сүз булган, диелә изге китапта да. Үз телен югалтучы үз милләте өчен юкка чыга. Ул, борынгы бабаларының киләчәккә илткән әманәт тәсбихын төпкелгә чәчүче. Ул милләте өчен борынгы үткәненнән һәм аның киләчәгеннән суырып чыгарылган бер фантом буларак, әлбәттә, кеше кыяфәтендә башка милләткә кушыла. Бүген урыс халкы составында мондый куркыныч фантомнар өлеше инде критик чикне чыкты һәм шуңа да әлеге милләтнең дәүләте җимерелүгә, үзе бетүгә йөз тотты. (Татар империяле чагында татарлашучы кавемнәр дә күп булган, бәлкем безнең һәлакәт төбендә дә шул сәбәп ятадыр?) Урысның исән калу шарты, әлбәттә, татарның татар, чукчаның чукча, фәләннең фәлән булып кала алуында.

Дөрес, катнаш никахлар урыска Булгаков, Тургенев, Карамзин, Державин, Кутузов, Суворовларны биргәндер. Бу — мәсьәләнең күн ягы. Әмма табигать балансны ярата. Ә катнаш никахлар тудырган коточкыч җинаятьчеләр, маньяк-монстрлар әлеге үлчәү тәлинкәсен кай якка авыштыра соң? Бу хакта информация яшерен сер итеп саклана. Милләт хыянәтчеләре — Смердяковларның үз аталарын үтерергә омтылуын бөек акыл иясе Достоевский язып калдырган лабаса. Урысны юк итәргә омтылучылар юлында татар, башка халыклар кайчандыр ышанычлы форпостлар иде. Әмма ятлар алдында ул киртәләр урысның үз кулы белән юк ителә. Чират җитте, бүген ятлар хуҗа булып алган телевидение, башка мәгълүмат чаралары инде урысның үзен дә үз теленнән, дененнән, рухыннан һәм сүзеннән читләштерәләр. Әллә нинди ят сүзләр аның үз сүзләрен берәм-берәм кулланыштан, сафтан, читкә — чүплеккә куалый. Әлбәттә, бу процесс күптән башланган, һәм инде урыс халкының палестиналылар кебек интифадага күтәрелүе, хөрмәтле классигыбыз әйтмешли, «едва ли»... Берәүләрне урыс-татар катнаш никахыннан туган балаларның тик урыс булып язылуы борчый. Ә бит бу милләтебезнең исән калуы өчен түләнә торган хак һәм бердәнбер чара. Киресенчә булса, без беткән булыр идек. Эш шунда, милләтебез үзе өчен зарарлы фантомнарны якын җибәрмичә, асылын, бүремәнлеген тәмам төкәнүдән саклый. Башкортларның татарны «үзләштерүе» татарга зур зарар китерсә, башкортның үзен, асылда, юкка чыгарачагын бу милләтнең аңлы вәкилләре, милләтчеләре төшенә микән? Әллә аларның хакыйкый милләтчеләре дөм юк, милләтче саналучылары поп Гапон варислары, «провакатор кәҗәләр» генәме?

Әйтик, ниндидер бер милләт вәкиле, кинәт кенә шундый юләр омтылыш уянып, яки берәр файда эстәп, алман, эстон, яһүд яки француз булырга теләде ди. Әмма моңа ирешү искиткеч катлаулы, ә бәлкем мөмкин дә түгелдер. Ә менә урыс булу үтә ансат: туган телеңдә сөйләшүдән туктыйсың, эчәсең, сүгенәсең һәм син — урыс. Болай итеп урыс булучы татары да, чукчасы да, башкасы да буа буарлык. Мәгълүм ки, югарыга менү авыр, ә түбән төшү ансат. Инде, Ходайның хикмәте, татарга башкорт булу мөмкинлеге дә ачылды! Әмма Зыя Ярмәки кисәткән бер кыенлык бар: атлар аранында торган ишәк атка әйләнми, ә ишәкләр аранында торган ат ишәккә әйләнә! Менә күрербез инде, Башкортстандагы туганнарыбыз ат булып калырлармы, әллә атка бик охшаган башка җан иясенә әйләнерләрме? Бу мәсьәлә турында уйлый башласаң, Герберт Уэлсның «Сукырлар илендә» әсәре искә төшә. Сукыр хирурглар хикәя героеның күрүен нерв авыруы дип бәялиләр, һәм бу «бәладән коткару» өчен операциягә ризалаштыралар. Герой сукырлар тормышына инде ияләшкән, тамагы тук, өсте бөтен, торагы җылы һәм үзенә матуррак дигән сукыр кәләш тә ярәшкән була. Әмма соңгы минутта ул кире уйларга көч таба һәм сукырлар илен уратып алган кар түбәле таш кыялар буйлап югарыга, билгесезлеккә үрмәли... һәм, ахыр чиктә, зур дөньяга юлны таба... Башкортстандагы татар язмышы турында түгел микән бу әсәр...

Виктор Гюгоның «Диңгез хезмәтчәннәре» романында Жилбер атлы егетнең сигезаяк белән алышы тасвирлана. Сигезаяк, өч капшавычы белән кыяга тотынып, калганнары белән Жилбернең тәнен уратып ала. Капшавычлардагы һәр күзәнәк сөлек сыман егетнең тәнен, сутын, канын имә! Рәсәй кочагындагы Татарстан язмышы турында түгелме бу? Достоевскийның «Җинаять һәм җәза» әсәрендә Раскольниковның төше бик тә гыйбрәтле. Анда урыс мужигы җигелгән атка күпме кирәк йөк, кешеләр төйи һәм атын каулый, чыбыркы белән яра, тарта алмый башлагач, казык алып килеп, аркасына, башына суга. Татар тәкъдирен тасвирламады микән бөек әдип? Кунгаева-Буданов, Шакирова-Суклетин язмышлары урыс-чечен, урыс-татар мөнәсәбәтләрен гәүдәләндерә түгелме? (Ягъни татар язмышы күпкә күңелсезрәк...)

...Аннары кешелекнең нәрсәдән башланганын уйлыйсың да, бөтенесенә кул да селтисе килеп китә. Әмма өметсез тик шайтан гына, дисең һәм тотынырга кабат салам эзләргә керешәсең...

## ПИРАМИДАЛАР ҺӘМ КОМПРАЧИКОСЛАР

Дөнья вакыттан, ә вакыт пирамидалардан курка, ди гарәп мәкале. Чордан чорга нәрсә тәкрарлый соң еракта калган бабаларыбыз әлеге таш «хатлары» аша? Пирамида иерархия символы, һәм бәлкем алар, камил пирамидага ирешмәсәгез, бетәчәксез, ди торганнардыр? Әмма адәм баласы хатадан хали түгел һәм югары урынны, гадәттә, әрсезләр, ертлачлар, юньсезләр эләктерә, ә вөҗданлылар, сафлар астарак тибелеп, тапталып калучан. Әллә алар пирамида күп булырга тиеш диләрме? Бүген барган глобальләшү процессы, милли пирамидаларны ишеп, һәм масса-культура ярдәмендә (аны урыска кайсы халык җитештерәдер, безгә үзебезнең татарлар тәпәли) һәр шәхесне «шакмаклы» хәлгә китереп, бердәнбер пирамида укмаштыруны күздә тота. Андый пирамидага ирешүгә Кытай һәм ислам дөньясы гына комачау тудыра төсле.

Евроцентризм, расизм, фашизм, коммунизм, глобализм — менә шулар инде цивилизацияле дип аталучы илләр күтәргән байраклар. Геноцид — цивилизаторлар бакчасы җимеше. Америка һәм Австралия кыйтгаларында «цивилизаторлар» бу миссияне планлы дәрәҗәдә үтәүгә ирешкәннәр. Тевтон ордены җиңеп чыккан булса, иң беренче «индеецлар» урыслар булырга тиеш иде. Әмма татарлар аркасында Евроазия ха-

лыкларын ул чакта индеецлаштыру, ягъни тоталь юк итү барып чыкмады... Русияне «индеецлаштыруга» бүген дә татар комачаулый: урыслашып, урысны ныгыта, түләмәсәләр дә, тырышып эшли һәм яшәве белән алдагы көнгә өмет уята. Хикмәт шунда: татар үзенә карата төрлечә геноцидка, яла ягуларга төкереп тә бирмичә, Рәсәйне һаман инстинктив рәвештә Алтын Урда, ягъни ватан дип санавын дәвам итә. Мәскәүнең дә вазифасы үзгәрмәгән. Элек ул татарга ясак җыю каласы булып, шул кәсеп белән паразитлык иткән булса, бүген дә Рәсәйдәге Евроазия кыйтгасына караган халыкларның уртак милли хәзинәләре булган казылма һәм табигый байлыкларны «цивилизацияле» дөньяга озатудан файда таба.

Виктор Гюго XVII гасырда Европаның цивилизацияле дигән илләре Англия, Франция һәм Испаниядә компрачикослар атлы кәсепчеләр булуы хакында яза. Болар, акча түләп, балаларны сатып алганнар һәм төрле мәзәк гариплеклардә шәкелләштереп, ягъни ортопедиянең эчен тышка әйләндереп, Европа вельможалары сарайларына шамакайлар җитештергәннәр. (Әлеге авторның «Көлә торган кеше» герое шулар кулыннан үткән, авызы колакларынача ерык кеше.) Дөнья компрачикосларның рух «төзәтә» торганнарын да белә. Милләтебез башына төшкәне — чукындыру, денсезләндерү һәм алфавит алмаштырулар... Америкада «елмая торган кешеләр» яшәсә, без «төксе чырайлар» иле булдык. Шәхес тормышына тоталь тыкшыну һәм башка бик күп тәэсирле ысуллар СССРда яшәүчеләрне «гомо-советикус» итеп шәкелләштерде. Ә бүген ачыктан-ачык порнография тарату, «СПИД-ИНФО» һәм башка шундый матбугат ярдәмендә «агартулар», туктаусыз үтерү-көчләү-тукмашу турында фильмнар әйләндерү киләчәк буынны ничек үзгәртәсен тик шайтан чамалый торгандыр. Ни дип атарлар аларны? Бәлкем гомо-раша дип?

## АНДЫЙ ПАРТИЯ ӘЛЕ ДӘ БАР!

Кесә карагына планлаштырып, эшен тормышка ашыру өчен мәгълүм бер вакыт аралыгы кирәк. Күзәтү, лезвие белән кесә кисү һәм, акча янчыгын тартып чыгарып, җинаять урыныннан эзне суыту өчен, әйтик, шома угрыга 15 минут җитсен ди. Ә инде КамАЗ кебек заводны үзләштерергә вакыт һәм әзерлек чаралары күбрәк кирәк. Арадашчы, фирмалар төзеп, банкларда исәп-хисап счетлары ачарга, килешүләр төзергә һәм заводтан продукцияне үзкыйммәтеннән түбәнрәк бәягә «сатып алып», биш бәягә урнаштырырга кирәк. Нәтиҗәдә, кесәгә ургылып табыш керә, завод та, бөлгенлеккә төшеп, теге фирма милкенә әйләнә... Фараздан, мондый афера өчен биш ел вакыт җитсен. Ә инде Рәсәй кебек дәүләтнең милкен тулаем кулга төшерергә 70—80 ел кирәксә, шулкадәр зур байлыкка ия булу хакына бу срокка да түзәргә була. Әлбәттә, иң әүвәле Остап Бендер сыман ниндидер фирма, дөресрәге, фирка төзергә кирәк. Ул төрле чорларда РСДРП, ВКП(б), КПСС дип аталырга мөмкин. Беренче этапта байлык Рәсәй халыклары кулыннан тартып алына һәм максатка ирешү чарасы буларак файдаланылган гидайларның күзләренә төтен җибәрү өчен, вакытлыча, гомумхалыкныкы дип игълан ителә. Аннары милекнең асыл хуҗалары һәм дәүләтчелек рухын геннарында саклаучы элита юк ителә. Җае чыкканда Хаммер ишеләр мөлкәтне өлешләп читкә чыгаргалый башлыйлар, әмма зур үзләштерү «Ч» сәгате суккач башлана. Әйе, халыкта фидакарьлек уятып, рәтле түләүләрсез зур эшләр эшләнде, күп байлыклар тудырылды, хәтта космоска менелде. Әмма болар ахыргы максатка зарар китермәде. Сәгать сукты, барлык хезмәт җимешләре, казылма байлыклар, иң переспективалы галимнәр, аларның ачышлары, кыскасы, бөтенесе-бөтенесе, Корейконың миллионы сымак, путалы тәлинкәдә «Мөгезләр һәм тояклар» фирмасының хакыйкый хуҗасы кулына керде. Без белгән кайбер дәү җитәкчеләр Ильф һәм Петровның «Алтын бозау» әсәре герое Фунтны хәтерләтәләр. Ә Сталин Рәсәйдә яшәүче халыкларның калдык элитасын һәм элита резервларын кат-кат юк итү миссиясен үтәргә сәләтле шәхес буларак, хакимияткә махсус менгерелгәнгә охшый. Рәсәй халкының иң аңлы һәм көчле ул-кызларын концлагерьларда һәм сугышларда сирәкләделәр, исән калганнарын төрмә-каторгаларда катырдылар, ирektәгеләрен бер-берсе өстеннән әләкләп торуга күнектереп, җинаятькә катнашучы ясадылар. Шундый һәм башка эшкәртүләр нәтиҗәсендә элитасы төкәнә язып, тәмам өне каткан халыкны Хрущев чорында «җебеткәч», Брежнев заманында сөрсеттеләр. (Колхозчыны — терлек азыгы карагы, эшчене — несун, тарихчыны — алдакчы, иҗат кешесен — ялганчы, җитәкчене — канун бозучы һәм карак, студентны — шпаргалкадан файдаланучы, озын сүзнең кыскасы, һәркемне теге яки бу дәрәҗәдә хыянәтче ясады.) Шулай итеп, илне таратып, бар байлыгын үзләштерүгә бер сүз әйтми торган мокыт-масса өлгереп-пешеп җитте, һәм аның үзен дә бу операциягә вак карак сыйфатында тартып керттеләр. Ә Фунт ролен башта Горбачев, аннары Ельцин үтәде. (Һәм хәзер дә лаеклы алмаш дәвам итә шикелле.) Санап кителгән Фунтлар, Фунтиклар тарих хөкеменә кала, постан китүгә, без аларны дуракка чыгарабыз, ә «Мөгез һәм тояклар» фирмасының хакыйкый хуҗалары кайчан да булса ачыкланыр. (Әйтик, мактанасылары килеп, үзләре бу хакта берәр заман язып чыксалар...) Балтыйк илләрендә реституция турындагы канун нигезендә таланып алынган милек асыл хуҗаларына кайтарылды. Ә бездә андый процесс күзәтелмәде шикелле, ягъни хәзерге милекчеләребезнең биләгән милке законлылыгы артында, урыс әйткәндәй, зур сорау билгесе калды.

Коммунистларның дингә үчегүләре халыкта гаҗәпсенү уята. Югыйсә бит дингә таянсалар, ил дә, үз позицияләре дә ныгыр гына иде... Хикмәт тә шунда шул, ахыргы максат бит илне ныгыту түгел, ә талау. Ә дин хилаф эшкә, һәртөрле хыянәтләргә фәтва бирмәү генә түгел, аркылы төшәр, карышыр иде. Шуңа да идарәчеләр коммунист атлы курчакларны дингә карата аяусыз иттеләр. Шуңа да немец концлагерьларыннан исән калучыларны гына түгел, хәтта дошман самолетын урлап кайткан герой Девятаевны да совет төрмәсендә тоттылар. Беренче карашка бу бернинди мантыйкка сыймый төсле. Ә Сталинның төп бурычы — милләтләрнең элитасын, димәк ки, хакыйкый каһарманнарын да юк итү, чүпкә чыгару икәнен танысак, бары да үз урынын ала... (Ялган каһарманнарны зурладылар анысы, ә Гази Заһитовның батырлыгын бик озак, үзе бик сәер генә дөньядан китеп бармый торып, танымадылар. Петр Гавриловны да бик соң, язучы Смирнов үҗәтлеге аркасында гына «искәрделәр».) Илебезнең хакыйкый элитасы юк ителүенә тукталдык. Бүгенге элита кем соң, һәм нәрсәсе ни өчен канәгатьләндерми? Хәзерге югары катлам — кичәге коммунистик җитәкчеләр, зур талауда «лаеклы» катнашып, мәгълүм бер өлешкә тиенүчеләр. Болар, нигездә, Сталин чорында кулак дип, күршесе өстеннән әләк язган крәстиян, мәхбүснең күзен тибеп чыгара-чыгара сорау алган тикшерүче, колхоз басуыннан чүп үләне җыйган өчен, ач балаларның уф алла арбаларын ваткан полевой һәм башка шундыйлар нәселеннән чыккан елгыр токым. Һәрхәлдә, КПРФ идеологлары аңлатканча, совет властена үч саклаган, юк ителеп бетмәгән дошман сыйныф калдыклары түгел. Халыкның затлы, гумус өлеше бетерелүе аның халык булудан туктап соры массага әверелүенә китерә. Бүгенге элитадан дәүләтчелек хисе, дәүләтле булырга омтылыш, дингә, телгә, моңыбызга тугрылыкны өмет итү — бәхәсле мәсьәлә. Әмма хакыйкый элита дәвамчылары да югарыга омтыла бит әле, өмет шуларда.

Мәгълүм ки, «Мөгез һәм тояклар» фирмасы үз максатына ирешкәч, КПРФ бик батыр кыяфәттә Горбачевны, Ельцинны һәм башка җитәкчеләрне дә хыянәттә гаепли, ил хөкүмәтләрен пыр туздырып сүгә башлады. Күрәсең, РСДРП, ВКП(б), КПССлар булып йөргәннән соң яңа псевдоним алган әлеге оешмага инде өр-яңа бурычлар йөкләнгән. Ә бәлкем, әлеге фирмага асылын яшерү өчен шулай кулайдыр?

## БӨЕК БАШЛАНГЫЧЛАР

Үзгәртеп кору чорында экстрасенсларга зәңгәр экраннар аша тулы бер ил халкы өстендә психотерапия сеанслары уздырырга форсат бирелде. Боларның тәҗрибәләре уңышлы төгәлләнгәч, сеансларны МММнар, «Хопер»лар дәвам итеп, халыкның кесәсен кабат чистарттылар. Моңа дәүләт юл куйды, мөмкинлек тудырды. Чөнки хакимияттәгеләргә өлеш тимәсә, андый проектларны кем дә эшкә ашыра алмас иде. Андый гипноз — бизнес пирамидалар Татарстанда да халыкны рәхәтләнеп өтте. Боларның эшчәнлегенә, гадәттә, пирамидага акча агымы килми башлагач кына нокта куела. Аннары инде, олылыклап, җирле Фунтикларны хөкем итәләр... һәм матбугат аша «үрдәк» җибәрелә: имеш ки, монда ятлар кулы уйный.

Рәсәйдә театрларны аз, диләр. Минемчә, һәр оешмада көн саен спектакль бара. Һәр җыелыш яки планерка — үзе бер серия. Башлык төп рольне башкара. Ә кайчак арткы пландагылар да алга чыгып куя. Җитәкчеләрнең ысулы да экстрасенсларныкына охшаш. Көн дә кемне дә булса сүгү, җүләргә чыгару үрнәгендә башкаларга көнлек куркыту порциясе биреп зомби ясау, установка ярдәмендә кәнәфине саклап калу өчен көндәлек көрәш — әнә шуннан гыйбарәт дәүләт ирләренең бар уй-фигыле. Шушы яссылыкта татар халкын да көн дә ахмакка чыгару, алдау, талау һәм төп башына утырту дәвам итә. Карьеристларыбыз ыгы-зыгысы моделе телевидениедә «Сыек буын» (Слабое звено) атлы уенда тәңгәл чагылыш тапты.

Бер татар гәзите атаклы Бигәнәй ишаны хакында мәгълүматлар бастырды. Иң тетрәндергәне — Бигәнәй ишанның патша «хәзрәтләренә» биргән анты булды. Ә без бит кемнәребезнең кемнәргә нинди антлар эчкәнен белмибез... Күрегезче, бүген Татарстан Дәү Киңәшендәге «элитабызны». Үз туган телендә сөйләшергә, Совет сүзен татарча Киңәш дип хет парламентыбызның татарча әйтелешендә беркетергә дә йөрәге җитмәгән бу филдәй гәүдәле кешеләр «Табеев куышы» дип аты чыккан «дачаларны» шәп үрчетәләр, ягъни күренекле коммунист җитәкченең «бөек башлангычын» лаеклы дәвам итәләр. Комсомол вожакларының, партбоссларга кызлы мунчалар яктырып, карьера ясаулары хакында да күп яздылар. Хәер, хәзер дә комсомолга алмаш оешма башлыкларының чибәрлек конкурслары жюриендә утырулары тикмәгә түгелдер... Кайчан да булса аларга Казанда һәйкәл куелса, һичкем аптырамас.

Безнең гомумхалык сайлап куйган президентларыбыздан чын мәгънәсендә бөек башлангыч өмет итәргә хакыбыз бар. Президент үзе билгеләгән яки сайланган хакимият башлыкларының компетентлылыгын үстерелгән икмәк, җитештерелгән продукция күләме, төзелгән объектлар саны һәм шәхси симпатиядән чыгып түгел, ә бер критерий, демографик хәл, аның динамикасыннан чыгып бәһаләсә, гаделрәк булыр иде. Нәкъ шундый критерий белән бәяләгәндә генә җитәкчеләр кешеләребезнең милекче, иҗатчы, югары квалификацияле хезмәт иясе, үрнәк гаиләче булуын, аның аеклыгын һәм сәламәтлеген кайгыртачаклар. Бермәл-

не көчле рухлы якташым Фәүзия Бәйрәмова «Алтын Урда» гәзитендә президентыбызны дин эшләренә тыкшынуда гаепләп язган иде. Ә минемчә, ул күбрәк бу эшкә тартылсын, хәтта хаҗга барып кайтсын иде. Заманында ислам динен башта хан, аның яраннары кабул иткән, гади халык мөселманлыкка шулар үрнәгендә күчкән ләбаса. Димәк, моны кабатлау лазем һәм бу Путин вертикаленә лаеклы җавап булыр иде.

Рәсәйдә революцияләр ясалуында һәм хәзерге вазгыять тууында да «демократик әдәбиятның» роле әйтеп бетергесез. Ә нәрсә соң ул «демократик әдәбият?» Демократик әдәбият ул — үткен, үтемле инструмент. Әйтик, егет белән кыз яратыша, ә аларның саф мәхәббәтенә, имеш ки, дин яки гореф-гадәт киртә. Һәм күздән яшь чыгара торган универсаль сюжет ярдәмендә теләсә кайсы халык күңеленә (татармы, һиндмы, румынмы — барыбер) дингә, гореф-гадәтләргә каршы протест оеткысы салына. Яисә мәктәптә «иске» тәртипләр өчен көрәшүче педагогны ямьсез итеп сурәтлиләр. Ә асыл максат, яшәп килгән тәртипләрне җимереп, хаос тудыру, һәм болганчык суда балык тоту, ягъни шул халыкның милли пирамидасын ишеп, милкен талау һәм үзләштерү. Икенче этапта сюжет өчен мәхәббәтнең сафы инде кирәк булмый. Күрегезче, хәзер безнең телеэкраннарны. «Күп көлмә, күп көлү күңелне үтерә» диелә хәдистә, ә анда ихахай да михахай. Шәрә тән, көчләү, үтерү күренешләре туктаусыз әйләнештә. «Сары» матбугат та халыкны өзми-куймый секс өлкәсендә «агарта» һәм мондый «агартулар» инде мәктәп программасын да яулады. Ник шулай соң бу? Билгеле инде, бүгенге кампрочикослар Яңа Бабил манарасы, ягъни бердәнбер уртак пирамиданың аскы каты өчен бездән «кирпечләр» ясыйлар... Ә бит пирамида төрмә өчен дә хас. Анда да югары ноктаны пахан били, астарак — «шестеркалар», аннары эшләүче һәм һәрдаим туры, һәм күчерелмә мәгънәдә үз арты өчен куркып яшәүчеләр. Ә иң аста — кыерсытылганнар... Рәсәй дәүләтендә уңышлы сыналу узган әлеге модельне инде бөтен дөньяга күчереп арканлыйлар...

## ИСЛАМ — «ЦИВИЛИЗАЦИЯ», КЕМ КЕМНЕ?

Исламга каршы һөҗүмнең сәбәпләре җитди. Иң әүвәле ислам карактан, талаучыдан, илбасардан курыкмаска, аның белән сугышырга куша, шәһид китәрсең, ди. Бу бит чит һәм үзебезнең «цивилизатор»ларыбызның иң төп коралын сафтан чыгара. Алар өчен исә безнең куркып, калтырап яшәвебез отышлы. Аракы, сыра сатып табыш алуны «цивилизацияле» хөкүмәт даирәләре ачыктан-ачык хуплый һәм кайгырта. Ә нарко, порно, шоу-бизнес белән югары даирәләрнең «тыгыз элемтәдә» торуы хакында детектив жанрда эшләүчеләр язып арыды.

Ислам дине хәрамны тыя; моның белән ул никадәр илләрдә хәмер җитештерүчеләрнең, фәхешханә тотучыларның, сутенерларның, порнобизнесменнарның һәм тагын әллә кемнәрнең миллиардлаган табышлы базарын чикли. Тик шуның аркасында гарәп кызлары элеккеге СССР кызлары үрнәгенә иярә алмый! Ислам дине бер өлкәдә дә чиктән чыгуны хупламый. Ә бит мода дигәннәре — киенүдә, гурманлык исә, ашауэчүдә чиктән чыгу. Димәк, исламнан модель һәм ресторан бизнесына да зарар. Комарлы уеннарга да ул яктылык вәгъдә итми. Ә иң хәтәре, ислам рибачылыкны, финанс спекуляциясен тыя, ягъни «цивилизацияле» илләрнең калган дөньяны имеп яшәү механизмына куркыныч тудыра. Димәк, аңа каршы чара күрү, «цивилизацияле» дөньяның «изге» бурычы. Чарага керешкәнче сәбәп табып, җәмәгать фикерен әзерләү зарур бит әле... Кайчандыр «татар игосы»н уйлап табучылар өчен, исламга яла ягу ике тиен бер букча булып чыкты, «халыкара терроризм» дигән менә дигән бүкәй уйлап таптылар.

## МӘНФӘГАТЬЛӘР УРТАКЛЫГЫ

Ислам илләре югары даирәләренең җинаятьчеләр белән уртак мәнфәгатьләре булмавы, алардагы законнарның аяусызлыгын һәм җинаятьчелекнең юк дәрәҗәсенә төшүен тәэмин итә. Демократия мондый «кыргыйлыкка» каршы төрлечә, шул исәптән пресса, телевидение ярдәмендә бик актив көрәшә. Ә демократия чәчәк аткан Рәсәйдә, кеше үтерүчеләрне әйткән дә юк, дистәләрчә сабый баланы көчләгән маньякны да ничәдер елдан соң ирекkә чыгаралар һәм ул үзенең сөйгән шөгылен тотылганчыга кадәр янә дәвам итә ала. (Уфада сабыйларны көчләп, күзләренә без белән кадаучы маньяк та ирекkә чыкмады микән инде.) Ни өчен алай соң? Чөнки бездә җинаятьчелек халык белән хакимият арасында барьер ролен үти. Әйтик, карт-корының хәтта үлемтеккә дигән акчаларын да талау әмәлен тапкан хакимияткә күсәкнең ботаклысын бик күтәрәсе килә, әмма башыңа андый уй төшкәнче, сине эшеңнән кайтканда типкәләп атулары мөмкин. Милиция җинаятьчеләрне эзләми, эзләсә, тапмый, тапса, берәр түрә үтенечен тыңлап, прокурор коткара яки суд, эшне кабат тикшерүчегә аткарып, йә адвокатлар алыштырып, вакыт суза-суза түзүченең гаделлек өчен көрәшкә өметен сүрелдерүгә ирешә. Кыскасы, уртак омтылышлар, мәнфәгатьләр һәм рухи кардәшлек хакимиятне җинаятьчеләргә мәрхәмәтле булырга этәрә.

Гитлерны җиңгән дәүләтнең җинаятьчелекне авызлыклый алмавы ышандырмый. Шулайдыр, җинаятьчелекнең һәр тармагыннан, хәтта сутенерлыктан, фәхештән килгән табыштан да хакимият өлешсез түгелдер. Ә менә бер капчык терлек азыгы урлап тотылган, бушка диярлек эшләүче колхозчыга карата дәүләт шактый аяусыз кылана, чөнки андый урлашудан хакимият кесәсенә берни таммый.

Армиядәге «дедовщина»ның тамырын корыту өчен дә даһилык кирәкмәс. Әнә бит ничәмә солдатны хезмәттәше атып үтерсә дә, әле бер генералны да, хәтта полковник дәрәҗәсенә дә төшергәннәре юк. Чөнки «дедовщина» бик күпләр өчен файдалы. Беренчедән, хөрәсән офицерларга эш җиңеләя. Икенчедән, медкомиссияләргә һәм военкомнарга ришвәт китерә, ә алар, керемле эш урыннарын югалтмау бәрабәренә, өстәгеләр белән бүлешми калмыйлардыр. Өченчедән, армиядән куркып, һәр егет диярлек вузга барып, күп акчалар түгә. Бу акча агымыннан да хакимияттәгеләргә өлеш чыга булса кирәк. Югыйсә уку йортларындагы имтихан-зачет сатып алуларга карата сүз чынлыгы өчен генә түгел, ә реаль чаралар күрелер иде. Ректорларны билгеләү, азат итүләр дә шулкадәр ажиотаж тудырмас иде.

## ӨЧЕНЧЕ КИТКА ҺӨҖҮМ

Ә халкыбыз — искиткеч! Рәсәйнең хәтсез калаларында мәчетләр салып чыгуы гына да ни тора! Мондый эшне провослав Рәсәйдә азат, бай һәм бәхетле бер халык та ерып чыга алмас иде. Ә бит халкыбызга фанатикларча диндарлык, гомумән, хас түгел, мәчетләрне дә ул урыс диңгезендә рухи һәм милли оазис, ышык зарурлыгыннан чыгып төзи. Аның дөнья бәйгеләрендә беренче килгән Рудольф Нуриев, Софья Гобәйдуллина, Ирек Мөхәммәдов, Марат Сафин, Алсулары бар, ә Илһамнарын Ростроповичлар зурлый. Аның бөтен дөнья баш ия торган галимнәре күпме? Аның Җәлилләре, Тукайлары, Әсгать Жиһаншиннары, Әсгать Галимҗановлары бар. Аның Петр Гавриловлары, Гази Заһитовлары бар һәм алар бездән беркая да китмәде! Халык күңелендә яшәгән хакыйкый, мәңгелек белән бәйле татар пирамидасы ифрат биек һәм аның очында Кол Шәрифләр, Сөембикәләр тора! Әмма бүгенге түрәләр күзаллаган сюрреаль татар пирамидасы ифрат тәбәнәк... Ә җыр сәнгатебездән чыгып караганда ул тагын да кечерәя бара... Шуңа дадыр Лима Кустабаева, Хәйдәр Бегичев, Таһир Якупов һәм башка шундый нәкъ Салих Сәйдәшев һәм Фәрит Яруллиннар кебек читкә тибәрелә.

Ходайның хикмәте, әле бездә чын, профессиональ композиторлар бар! Ләкин бүген Җыр сәхнәсен «Супершарманка-Ямаха-сан» артына баскан «композитор-музыкантлар» һәм микрофон «капкан» фанерачы җырчылар тоту сәбәпле, чын композиторларга һәм хакыйкый җырчыларга зарурлык юк. Аһ, элек җырчының тавышына игътибар итә һәм бәһали белә идек. Илһам Шакиров, Фәридә Кудашова, Габдулла Рәхимкулов, Рафаэль Ильясов, Гөлсем Сөләйманова, Таһир Якупов, Рәшит Ваһапов... Руслан Дәминов, Зилә Сөнгатуллина... Болар — дөнья сәхнәләренә чыгарырлык асылташтай кыйммәт, гүзәл тавышлы җырчылар. Ә хәзерге җырчыларның кайсының тавышы бар, һәм аларны татарныкыннан башка кем сәхнәсенә чыгарып була инде? Җырларның текстлары хакында моңарчы да сүз күп булды, аларның, нигездә, шигърияттән ерак, мәгънәсе шикле рифмалы сүз тезмәләре генә булуын кабатлап йөрәкне бозмыйк, әйдәгез, көйләр хакында да сөйләшик. Мәгълүм булсын, сәхнә түребезне яулаган «Ямаха-санны» музыкаль протезлар банкы дип атасаң да ярыйдыр; аның хәтеренә төрле-төрле көйләргә ярашлы, төрле инструментлар башкаруында, төрле жанрда башлам, очламнар һәм ритмнар тупланган; теләсә кайсы халык яки хакыйкый композитор әсәреннән музыкаль һәм шундагы бер ритм кысасына кертү «көй» хасил итә.

Бер көн автобуста матур гына бер җыр тыңлап барам. Көй яңа, әмма таныш кебек. Тыңлый торгач барып җитте, бу бит җитмешенче еллардагы Шарль Азнавур башкарган шлягердан үзгәртелгән нәрсә, ягъни беркадәр мелизмнар, интонацияләр өстәп ясалган өтек вариант. Ягъни янә алга китеш. Почему, потомушто, әле бит «композиторлар» чимал сыйфатында моңарчы татар һәм урыс җырларын гына ботарлыйлар иде, инде Франция белән эш итәбез...

Ят моңнарны гыйбадлаштырып «көй» әвәләү һәм рифмалы сүзтезмәләр белән укмаштырып «җыр» чыгару күптән техника эшенә әйләнде, ә бер үк көйнең кырыкмаса-кырык вариантыннан җыр әтмәлләү эпидемия төсмерен алды. Татар, урыс башка халык көйләрен, хакыйкый композитор язган әсәрләрне фрагментларга таркатып, һәм шуларны төрлечә теркәп корама көй «тегү» бүген гаепкә саналмый, андый җыр Бөтендөнья татар конгрессы кунакларына да тәкъдим ителде. Сырага аракы өстәгән сыман. «Ямахага» баян кушып уйнау, «көйгә» тереклек чаткылары иңдерә, әмма мондый музыкаль ерш та күпләрне үтләткән булырга тиеш. Һәрхәлдә, музыкадагы мондый шыртлакачылык белән чын сәнгать арасында уртаклык була алмый.

Кайсы көйнең каян урланганын ачыклый торган компьютер программасы төзеп була булуын, әмма аның әлегә һичкемгә кирәге юк. Әлбәттә, мондый «әсәрләр» хәтердә калмый, күңелдә яңармый, аларны отып җырлап та йөрмиләр, һәм мондый трансплантация җимешләреннән озын гомер таләп итү дә урынсыз.

Әмма аның каравы болай җыр ясауның җитештерүчәнлеге югары һәм төшеме әйбәт. Әйтик, кайбер бай оешмаларның профсоюзлары билетның берсен, мисал өчен, йөз тәңкәдән сатып алалар да, сигез йөз сум дип бәяләп, эшчеләренә бушлай өләшәләр. Барлык яклар да ота.

Авыл районнарына «фанера» төяп килгән төркемне бәхилләтергә акча алу өчен иң җайлы урын — районның май заводы кассасы. Колхозчыларның ел буе сөт тапшырып җыелган акчасын ике сәгатьлек чыгышлары өчен концертчы шабашчыларга биреп җибәрү артистларга да, тамашачыга да ифрат отышлы. Ә бит ул акча барыбер авыл кешесенә барып җитмәскә мөмкин.

«Ямахалы» продукцияне өзми-куймый пропагандалау да эзсез узмый дип уйларга кирәк, моның белән махсус радио һәм республика телевидениесе вакыт җәлләми шөгыльләнә. Күрәсең, бер-бер концерты фәлән мең китерүче мондый чыганактан файда күрүчеләр хөкүмәт даирәсендә дә юк түгелдер.

Тәнкыйть юклык музыканы гына түгел, әдәбият-сәнгатьне дә, гомумән, рухи тормышыбызның һәр тармагын, шул җөмләдән милли хәрәкәтне дә регресска сөйри... Аннары эш шунда, Шукшинның «Калина красная» фильмы герое Иван Прокудин сыман, халкыбызның «күңеле бәйрәм тели, ул аны озак көткән». Ә хоккей, баскетбол кебек спорт тамашалары татар өчен чын бәйрәм була алмый, чөнки татар уенчылары аларда бик аз, юк дәрәҗәсендә, ягъни командаларны тартып-сузып та татарныкы дип булмый. Алар да әрмәннәрнең, шабашчы бригадалары сыман, зур хакка ялланган һәм яллаучыларын да, шәт, «рәнҗетмиләрдер». Икенчедән, тамаша урыс телендә бара, тамашачы да урысча акыра-бакыра «ял итә». Бары тик татарча шоу-концертлар гына татарны аерып туплый, чөнки аларга башка милләт вәкилен трактор белән дә өстерәтеп кертә алмыйсың, ягъни аның сыйфатсызлыгы «өстенлеген» тәэмин итә. Аяныч, татарның үз оркестрлары, ВИАлары юк дәрәҗәсендә, ә бушлыкны тутыру «Ямаха-санга» кала. Күңелем белән бүгенге эстрадабыз йолдызларын: Айдар Галимов, Салават Фәтхетдинов, Хәния Фәрхи, Бәширә Насыйрова, Гайфулла Авзалов, Сәгыйть Гыйбашев, Нәфкать Нигъмәтуллинны, кыскасы, барысын-барысын Шукшин фильмындагыча өстәл буенча утыртып чыгам. Ә бу Татарстанның азатлык, суверенлык алган көннәре, имеш, һәм залга, бәрхет халат киеп, Иван Прокудин сыман каударланып, милләтебез килеп керә...

Хуш, ә нигә кирәк булды соң бу өлкәгә шулкадәр тәфсилле тукталыш? Мәгълүм ки, татар халкын, шартлы рәвештә әйтсәк, өч кит тотып тора: дин, тел һәм моң. Әмма динебез ныклап торып аякка баса алмый, телебезнең хәле аяныч, һәм, ниһаять, моңыбызны дөмбәсләргә дә чират җитте. Кош фабрикаларында тавыкларны туендырган төсле, күңелләргә басым белән чүп тутырып, «Гөлҗамал», «Тәфтиләү», «Кара урман» моңнарын мәңгегә күмәргә маташалар. Комбиазык телле, ярым-йорты динле, башка халыклардан урлап гыйбадлаштырылган көй-моңны үзенеке санаучы масса, халык дип аталуга лаек булмаска да мөмкин көннәрдән бер көнне.

## ЮНӘЛЕШЕБЕЗ — КЫЙБЛА

Татарның котылу юлы кайда соң? Безнең кайбер зыялыларыбыз татарга шундый бул, мондый бул дип киңәш бирергә махсуслашты. Әйтик, яһүд төсле бул, диләр. Моның өчен безгә, һичьюгы, фәлән мең ел рибачылык белән шөгыльләнергә, иткә дигән малны кошер кухнясы ысулында җәзалап суярга, һәм байлык җыйнау максатын тормышыбызга байрак итәргә кирәк. Әрмән төсле булыйк, диючеләр бар. Монысының да татар өчен бик тә хәтәр яклары юк түгел. Кемдер төсле булу, ул бабайларның дөнья тетрәткән җиңүләреннән, милләтебезнең шанлы чорыннан баш тарту да дигән сүз. Татар милләтен шәп бер агачка тиңләсәк, аның юан куәтле өлеше Алтын Урда чорына караса, корый башлаган оч — безнең бүгенге хәлебез. Милли агачыбыз яшәсен өчен, шартлы итеп әйткәндә, кояш, һава, дым һәм ашлама җитми. Безнең яфраклар башкалар туфрагын ашлый, ят идеаллар, әйтик, йомранлык инстинкты рухыбызны боза, вөҗданга таянмыйча, белемгә, сафлыкка һәм, кояшка омтылмыйча, иҗат итү музыкабыз, әдәбиятыбыз, сәнгатебез һәм фәлсәфәбезне гарипли, милли агачыбызның сутын дөм коргаксыта. Аннары без ялганлыйбыз. Ә ялган милләтнең һәр күзәнәген агулый. Эштә дә, гаилә мөнәсәбәтләрендә дә, хәтта иҗатта да хәрам катыша. Урысны да шул харап итә, ә табутка аны татар һәм үз тарихы турындагы ялган кертәчәк. Урыс һаман Киев Русе турында әкият сатса, халыкара кануннар буенча аңа тора-бара яшәү өчен юридик яктан расланган пространство-биләмә калмаячак. Бердәнбер дөрес юл — «татар-монгол изүе» дигән сафсатаның тарихи ялган икәнен тану һәм үзен татар-монгол-урыс кофедерациясе булган Чыңгыз империясенең варисы дип таныту, янә сепаратист әмир Мамайны Куликово орышында тар-мар итеп, уртак ватанны саклап калуда хәлиткеч роль уйнавы, һәм татарларның ханлыкларга таркалып, бөтен уртак ватанны югалта башлаулары сәбәпле, шул дәүләтнең шанлы байрагын күтәрергә мәҗбүр һәм хакы булуына ышандыру. Аннары көн тәртибенә Белоруссиягә генә түгел, ә монголларга да, кабат берләшик дип, кул сузарга мөмкинлек туа. Һәм ул очракта урысны агрессорлыкта гаепләп булмый башлый. Чечня гына түгел, хәтта Әфганстан өчен дә, гомумән, барлык яулап алу сугышларын да, ил суверенитетын кабат торгызу дип акларга җай чыга!.. Ул чакта Кытайга Рә-

сәйдән биләмә дәгъвалау юлы киселә. Киресенчә, Рәсәй эчке Монголия, эчке Төркестаннарны кире кайтару турында сүз кузгатып, әлеге куәтле дәүләтнең үсә баручы аппетитын чикли, ташламаларга барырга этәрә алачак. Менә Рәсәй сәясәте шушы, үзен исән калдыру юнәлешеннән китмәсен өчен дә, аның үз асылларын оста яшерә белүче дуслык битлеге киеп эш итүче җәлладлары татарга яла ягу, аны урысның мәңгелек дошманы итеп калдыру өчен җан аталар һәм уңышка да ирешүләрен танырга тиешбез. Әлбәттә, урыс безне туган дип таныса, яшәвебез өчен бу конфортлы булыр да, әмма ахыры аяныч бетәчәк. Яманлыкка түзсәк тә, яхшылыкка без чыдый торган халык түгел. Шуңа күрә бүгенге вазгыять өчен зар елау, мескенләнү мин фәкыйрьгә һич тә аңлашылмый. Без шушы шартларда җиңеп чыгарга тиеш. Шундый җиңү генә безнең киләчәгебезне тәэмин итәр.

Ильф һәм Петровның үлмәс герое Остап Ибраһим улы Бендерның Яңа Васюки авылы халкын канатландырганы шикелле, һәр татарны интернетка ялганган компьютер белән кораллandыру, инглизнеке төсле латин графикасына күчү ярдәмендә милләтне исән калдыру, хәтта ки әйһи вәссәлләм аны алгарышка ирештерү турындагы фикерләр күңелләргә сары май булып ягыла. Бу проектны милли байларыбыз финанслап тормышка ашыруына өметләнү күңелне тәмам нечкәртә. Тик бүгенге элита милләт өчен мондый зарур эшләргә кул тыгармы, аны моңа нәрсә этәрер? Бармы берәр мотивация?

Милләтебезнең котылу юлын пәйгамбәребез Мөхәммәт саллаллаһы галәйһи вәссәләм әллә кайчан өйрәткән инде. Әлбәттә, өмет тик Аллаһы Тәгаләдә генә. Бары тик динебезне торгыза алсак кына исән калуыбыз һәм алгарышыбыз өметле. Һәм ниндидер яңа проектлар планлаштырганчы, безне чүпкә чыгарырга көйләнгән механизмнардан котылырга иде. Әйтик, Рәсәй тарихчылары казакларны качкын җинаятьчеләрдән чыккан урыслар дип ышандырмакчы. Әйе, Рәсәй үз адәм актыкларын казаклар җиренә күпләп юллагандыр һәм казаклар канына аларныкы да кушылгандыр. Әмма татар, коми, удмурт яшәгән җирләрдә дә төрмә тибындагы учреждениеләр күпләп үрчетелде, гигант төзелешләр сылтавы белән урысның байтак бу тип «элитасы» милли территорияләргә күчерелде. Һәм, мөгаен, ерак киләчәктә татарларны да җинаятьчел урыслардан чыккан төркем дип игълан итү күздә тотылгандыр. Татарстанда (90 нчы еллар башында) «Казан феномены» атлы күренеш барлыкка килде. Мотлак, бу безнең өстә барган экспериментларның «уңай» чишелеше иде. Ә милли мәктәпләр, милли гимназияләр ачу шушы проектны тормышка ашыручылар мәсләгенә каршы килә һәм аларны җәнҗал кубарырга этәрә. Ә кемнәрдер, җәнҗалны безнең милли сыйфатыбызга бәйләп, халкыбызга яла яга. Милләт оешмый, уянмый, көрәшми, дип, гаеп ташлаулар нигезсез. Тарихтан билгеле: көчле һәм акыллы лидер юк чакта урыс та, серб та, француз да, башкасы да үзара сугышкан. Менә безнең мөстәкыйль дәүләтле ханнарыбыз флот төземәгән, нәтиҗәдә, башта Болгарны җимергәннәр, Казанны коткару өчен дә флот булу зыян итмәгән булыр иде. Ә бүген ярым-йорты суверенитет шартларында Татфлот бар! Рәсәйгә иң шәп корабларны Казанда төзиләр. Вертолет, самолетлар да бездә ясала. Кирәк вакытта татар халкы бик әйбәт берләште, референдумны да менә дигән итеп кичтек. Дөресен әйткәндә, Рәсәйдә башка халыкларның республикаларына Татарстан булганга гына түзеп торалар. Губерналар белән дә субъектлы уен Татарстан булганга гына уйнала. Ни өченме? Чөнки бүген безнең акыллы лидерыбыз бар һәм халкыбыз бердәм!

Милләт оешмый, көрәшми, уянмый, дип, гаеп ташлаулар нигезсез. Милли хәрәкәтнең таяну плацдармнары һәр төбәктә оешты, ә Ленин өйрәткәнчә, бер оешмада әгъза булып торучы, взнос түләүче һәм отчет бирә торган профессиональ көрәшчеләр оешмасы булмау, ахыр чиктә хәрәкәтне төкәнүгә китереп җиткерде. Моның өчен дә халкыбызга ачуланыргамы? Минемчә, концерт, балет, опера кую яки КВН уздыру өчен генә түгел, ә мәйданнарда милли хәрәкәт спектакльләрен күрсәтеп тору өчен дә кертемнәр кирәк... Булды еллар, милли хәрәкәт, Иттифак фиркасы хакимият файдасына һәм бер тиенсезгә, җитмәсә, шуның ук тарафыннан тукмалып, ихлас, зарур санап эшләде. Хәзер инде җүләрләр юк, Татарстанда да, башка милли төбәкләрдәге шикелле, җитәкче постлар, аның артыннан мөмкинлекләр милли кадрлар кулыннан ычкынмасын өчен, хакимияттәгеләргә дә селкенергә вакыт.

Латинга күчү Ельцин заманында ук бер каршылыксыз хәл ителә ала иде. Әмма аны дистә елга Рәсәйдә моңа каршылык өлгергәнгә кадәр суздылар да бар гаепне вертикальче Путинга, Думага һәм депутат Әхмәтхановка өеп калдырдылар. Хуш, Татарстан мөстәкыйль булсын өчен нишләргә соң? Без Мәскәүгә шундый таләп куябыз, ә ул аны, табигый ки, оятсызлык дип кабул итә. Минтимер Шәрип улының гадел федерация төзүгә омтылышы да урысларда әллә ни энтузиазм уятмый. Татарстанда кырый көчләрнең бетерелүе, «Алтын Урда» гәзитен ябып, Иттифак фиркасын хәлсезләндерүдә, депутатлыкка кандидат булып теркәлгән Фәүзия Бәйрәмованы кара төндә юлда япа-ялгызын машинадан төшереп калдыру да хакимиятнең үзе утырган ботакны кисүе булды, ягъни ул үз тырышлыгы белән «крайний» булып калды... Бу уңайсыз хәлдән чыгу өчен, югары даирәләргә Татарстанда ашыгыч рәвештә, һичьюгы, бутафор булса да, күпсанлы кырый көчләр оештырырга кирәк. Әйтик, Мәскәүнең Америкага да теләсә нәрсә кычкыручы, ә кирәк чакта

гел хакимият кушканны шыпырт кына эшли торган Жириновский партиясе бар. Кызыгырлык үрнәк, минемчә. Безнең парламентта «кырый көчләрнең» депутатлары ашка суган ничек булса, шулай кирәк.

Практика шуны раслый, илебез тәэминатчысы, әйтик, йөз данә нәрсәдер кайтуын теләсә, ике йөзгә заказ бирә һәм, нәтиҗәдә, илле данәгә ирешсә, шөкер итә. Заявкага әйберне әз язсаң, гадәттә, сызып кына аталар. Безнең милли хәрәкәт-партияләрнең максаты да бәләкәй булмаска тиеш. Әйтик, берәрсе Казан — башкала булып, Рәсәй Алтын Урда дип аталсын өчен көрәшсен.

Юкса Рәсәйгә фәрештәгә тиң җитәкчеләр килсә дә, без сорый дип, Татарстанга мөстәкыйльлек бирмәячәкләр. Ә таләбебез Алтын Урда кысаларында булса, мәгез, тамагыгыз тыгылсын дип, сораганнан бик күпкә ким, ягъни Татарстанны «ыргытулары», ал шартлар әзерләнсә, бик ихтимал. Президент Шәймиев хезмәтен танымый мөмкин түгел: форсат кына чыксын, республика бүгеннән мөстәкыйль яшәп китүнең әзерлек сызыгына куелган. Халкыбызга азатлык килерме соң? Әлбәттә, киләчәк, иншалла. Ходай Тәгалә бер җай чыгармый калмас дип өметләник.

Әнә бит Американың, Кытай белән көндәшлеге аркасында, ирек өчен әллә ни көрәшмәгән килеш тә Дөнья Хуҗалары Мәскәүгә Казагыстан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Төрекмәнстаннарны ычкындырырга боерды. Кытай җәелмәсен өчен барьерлар кирәк, ә урыслар бүген кими. Димәк, Кытайны җәймичә, Америка хәрби базалары ярдәмендә, бергәләп бөяп тору өчен кардәшләребезгә азатлыкны бүләк иттеләр. Инде, Ходай кушып, кардәшләребез мантып китсеннәр иде. Садри Максуди да, безгә азатлык көнчыгыштан киләчәк, дигән.

Безнең урамга бәйрәм барыбер киләчәк, чөнки без аны, Иван Прокудин әйтмешли, озак көттек. Чөнки дөньяга кемнәрнеңдер нөхсәсе түгел, ә кабатланмас татар кирәк!

Ә гомумпирамида белән нишләргә? Глоболистлар фикеренчә, ул пирамиданың өлешен «алтын миллиард», ягъни үзләрен цивилизацияле дип белдерүче халыклар биләп, калган кешелек черек нигез тәшкил итәргә, чиргә, хәерчелеккә батып, боларны күтәреп торырга тиеш була. Әмма һәртөрле бозыклыкларга вә хыянәтләргә матур атамалар биреп, аларны яшәү нормасына әйләндергән «алтын миллиард», балык башы сыман, үзе алдарак череп таркалуга мәхкүм түгел микән? Мондый тотрыклылыгы шикле корылышка бәлкем берәр альтернатива бардыр?

Әлбәттә, бар. Кешелекне һәлакәткә барудан туктатырлык чара, көч, юл — ул сафлык һәм ихласлык байрагы күтәргән ислам.

Мәгълүм ки, аскы кирпечләргә өскеләренең авырлыгы төшә. Ә ислам корылышында һәр күңелнең Аллаһы белән бергә багланышта булуы аны рухи күтәрелештә тота, һәм өскеләрнең аскыларны изү шартын һәм сәбәбен юкка чыгара...

Мәктәптә электр тогын электроннарның юнәлешле хәрәкәте дип аңлатканнар иде. Мөселманнарның да юнәлеше бер, ул — кыйбла, ә ислам тудырган рухи энергия — реаль.

...Кәгъбә тирәли тәваф грандиоз генератор эшчәнлеген хәтерләтә. Әгәр Җирдә бар Кешелек тәваф башласа, туган куәт аны, мотлак, күкләргә ашырыр...

*32 апрель, узган ел*

## БЕЗ — ФИРГАВЕН ТОКЫМЫ

Казан ханбикәсе — Сөембикә, ә Мисырныкы Клеопатра булган. Исемнәрен таркатсак, Сөем-бикә һәм Клео-патра килеп чыга. Ягъни Көлия яки Гөлия — исем, ә патра — бикә сымак титул икән. Татарда батыр калу өстен, җиңүче, ягъни беренче булуны белдерә. Димәк, Мисырның Гөлия (Көлия) исемле гүзәле, беренче яки җиңүче дигән мәгънәдә батыр (патр) титулына ия булган. Бәлкем ул чорда батыр яки патрның батра (патра), ә матурның матура кебек төрдәшләре дә булгандыр... Клеопатра һәм Антонийны тозакка төшереп харап иткән Гармахисның да чын исеме, мөгаен, Үрмәкүч булгандыр. Димәк, заманында Мисырда татар яшәгәч, без — фиргавен кавеме булып чыгабыз. Мисырда яшәгәч, Мәккә каласында да булганбыздыр дигән фикер туа.

Һәм, ниһаять, Александр Македонскийның милләтен ачыклау сәгате сукты. Әйе, аны әл-Искәндәр Зөлкарнәйн дип атаулар булды... Исеме ярасын да ди, фамилия ягы якын да килми интектерде. Инде бар да тәртиптә, бу, чыннан да, Искәндәр, ә фамилиясе — Мәккәдәнски, Мәккә татары булып чыга, ягъни мәсәлән.

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫН ЧӘЧӘК АТТЫРУ ӘМӘЛЕ

Әдәбиятыбыз дип аһ оручылар күп, котылу юлын күрсәтүчеләр юк.

Мәктәпләрдә балаларга мәгълүм бер текстны укыйлар да шуның нигезендә бәян яки инша яздыралар. Боларны һичкем оригиналь әсәр сурәтендә редакцияләргә тәкъдим итми, чөнки һөнәри язучыларыбыз булуы итәкне тота. Ә музыкада эш рәхәт, профессиональ композиторларыбыз бетү чигендә, шуңа күрә хакыйкый композитор, яки халык көйләрен нигез итеп әтмәлләгән музыкаль язма иншаларның иң пүчтәк дигәннәрен дә сәхнә яки радио-телевидение аша гамәлгә тәкъдим итеп була. Драматургиядә дә эшләр рәхәт.

Балалар язучысы Н.Носовның «Белмәмеш маҗаралары» әсәре герое Чәчкәйский Белмәмешне язучы булырга өйрәтә. Әсәр язу өчен лыгырдамышны (магнитофонны) кешедә «онытып» калдырасың да, тасмага язылганнарны кәгазьгә төшерәсең, дип төшендерә остаз.

Яңа радио һәм телевидениебез нәкъ Чәчкәйский рецепты буенча эшли башлады түгелме? Музыкаль иншалар белән телефон аша ыкты-шыкты сүз кайтарышуны аралаштырудан гыйбарәт ләбаса бүгенге тапшырулар.

Күрәбез: радио-телевидениебез дә, эстрадабыз да шул рәвешле чәчәк ата. Ә инде әдәбиятыбызның да алар шикелле чәчәк атуын теләсәк, профессиональ язучыларыбызның тамырын корытасы бар икән.

## ЛАТИН ИМЛАСЫ ЮЛЫНДА — ПОСКЫН!

Татарстан бәйсезлеге турында Декларация кабул иткән депутатларыбызны милли каһарманнарыбыз дип танып, аларга һәйкәл торгызсак та урынлы. Алар кабул иткән документ, милләт өчен киң мөмкинлекләр ачып, латин графикасына кайтуны да көн тәртибенә кертте. Зарур карар проектын әзерләүне тел галимнәренә йөкләү берәүне дә пошаманга салмады. Голәмәләребез әлеге проектны әйтелгәннән алда әзер тотканнардыр дисәк, мөхтәрәмнәребез кайсы хәрефкә нинди койрык тагу хакында дистә елга сузылачак бәхәс оештырып, Рәсәй Думасы «кириллицадан ни уңга, ни сулга» дигән канун кабул иткәнгә кадәр латин имласы ябырылуына каршы героик оборона тоттылар. Боларның мантыйгын аңларга тырышыйк. Мәгълүм ки, Татарстанда татар телендә камил сөйләшүчене көндез чыра яндырып эзлисе. Хәтта гомерен шул тел ярдәмендә ризык юнәтеп үткәргән язучы-журналистларыбызның да күпчелеге мөкәммәл сөйләмнән мәхрүм. Татар мәктәбен тәмамлаучылар өчен рәттән ике татар җөмләсе төзеп әйтү — проблема... Беренче сыйныфка кергәндә теттереп татарча сөйләшкән балаларга мәктәптә нинди зәхмәт кагыла соң? Әлбәттә инде, мәктәптә укыганда иң алдынгы укучыларны да аңгы-миңге итә ала торган предмет — татар теле... Андагы чит тел атамаларына (телчеләребез термин дияр иде) бай, кургаштай авыр, озын кушма җөмләләрнең очына барып чыкканда, башында ни хакында сүз барганы, әлбәттә, онытыла. Тел галиме (алар үзләрен филолог дип атый) үзе өйрәнгән телне шул телдә бәян итә алмый икән, яки мондый телнең, яки мондый галимнең базар көнне бәясе сукыр бер тиен. Татар теленең камиллеге дөньякүләм таныла икән, соңгы вариантка туктарга туры килә.

Әгәр нинди дә булса колонизатор яки колонист, абориген халыкның теле турында хезмәт яза икән, ул, әлбәттә, үз теле закончалыкларын өлге санап, аның кагыйдәләре кысасына куып, турылап, шуның атамаларын эшкә җигеп, ягъни илдәшләре, илдәш кулланучылары аңларлык итеп язар һәм мондый әсбап аборигеннарның үзләре өчен дәреслек була алмас иде. Ә татар телен өйрәнүче татар баласы өчен дәреслекне ниткән колонизатор язган һәм кайсысы шулкадәр «оста» тәрҗемә иткән? Абажур — абажур, ляпсус — ляпсус, синоним — синоним, синтаксис — синтаксис һ.б. гыйбарәт татарча-урысча һәм, киресенчә, «сүзлекләр» төзегән филологлармы?

Дәреслекләр, кем күпме мөмкин, шулай «мудрить» итеп төзелгән. Әлбәттә, имла кагыйдәләре — грамматика, тыныш билгеләре кагыйдәләре — пунктуация, җөмлә һәм сүз төзелеше — морфология һәм синтаксис дип тәгаенләнгән. Ә синтаксик синоним дигәне нәмәкәй тагын? Иманым камил, әгәр телебезне өйрәнү өчен шушы әкәмәт гыйбарә зарур икән, аның татарча мәгънәдәше, әлбәттә, бар... Һәм, аңлашылса кирәк, безнең балакайлар инша һәм бәян түгел, ә сочинение һәм изложение язарга мәхкүм.

Күренә ки, тел галимнәребезнең татар балаларын туган телдән биздерү юнәлешендәге тырышлыклары шушы көнгәчә лаеклы бәя алганы юк. Минемчә, алар күптән Алексей II атакай һәм Александр Проханов бүләкләвенә лаеклар. Әгәр латинга күчсәк, телебезне өйрәнү юлына болар үстергән чытырманлыклардан уптым илаһи котылган булыр идек. Әмма гыйльми исемнәр китергән әлеге чытырманнар галимнәребез өчен артык газиз шул, һәм үз хезмәт җимешләрен саклап калу форсатыннан нигә әле аларга рәхәтләнеп файдаланмаска ди?..

## ЧИКЛӘВЕК ЮКӘДӘ ҮСӘ

Онытмыйлар һәм оныттырмыйлар бабаларыбызны. Хәтта татарларга тиңләп, немец-фашист гаскәрләре турында да «фашистские орды» дип туглыйлар. Әллә җәмәгатьчелек фикерен «һәрвакыт әзер» тоту, татар-

га карата «Ч» сәгатендә бер-бер хәл кылу нияте барлыгына ишарәме? Юк, әлбәттә. Искә төшерик, атаклы тарихчы Н.М.Карамзин бер чит ил кешесенең «Сезнең Рәсәйдә бүген нишлиләр?» дигән соравына:

— Урлыйлар, — дип җавап биргән.

Ул мондый сорауга бүген дә шулай дип җавап бирер төсле.

Рәсәйдә ничә гасырлар дәвамында татарны сүгәләр, миллион тиражлы дәреслекләр, «тарихи» романнар, «тарихи» фильмнар өзми-куймый безне «фаш итә». Югыйсә «иго» дигәннәре нибары ун процент налогны тәшкил иткән. Эш нидә соң?

Бөек Чыңгызхан «минем олуг дәүләтемдә кеше, башына алтын тәңкә тулы тәлинкә куеп, бер читеннән бер читенә бернинди талау-урлашуларга юлыкмый уза ала» дип горурланган. Алма агачыннан ерак төшми, аның оныгы Бату хан да бөек бабасы эзеннән киткәнгә охшап тора. Ягъни урыс халкы, рухына хыянәт итеп, урлашуларсыз өч йөз ел җәфа чиккән булып чыга! Әлбәттә, ул моны оныта да, кичерә дә алмый...

## УРЫСЛАРНЫҢ МИЛЛИ АЗАТЛЫК ХӘРӘКӘТЕ...

Рәсми тарихта Пугачев явы крәстиян фетнәсе дип тамгалана. Асылда, бу немец шпионкасының, Петр IIIне үтертеп, ил башлыгы булып алгач, баскын хакимияткә каршы халык күтәрелеше иде. Әмма урыс аксөякләре арасында милли азатлык хәрәкәтенә җитәкче булырлык патриотлар табылмау аркасында, хәрәкәт Суворов һәм Михельсоннар тарафыннан тар-мар ителде. Тора-бара Романов дип тамгаланучы килмешәк хакимият кул астына кергән урыс аксөякләре Рәсәйдә яшәүче бер халык белән дә, шул исәптән урысларның үзе белән дә исәпләшми башлап, урыс теленнән баш тартып, француз теленә күчтеләр, ягъни ил халыкларыннан тәмам аерылдылар. Һәм урыс организмы өчен кирәкмәгән, ят, паразит тәнгә әйләнделәр. 1917 елны автоном рәвештә череп баручы бу өлештән сәламәт организм баш тартты, һәм яһүд хирурглары ярдәме белән аннан арынды. Әмма изге урын буш тормый һәм җитәкчелекне «коткаручы» яһүдләр эләктерде. Нәтиҗәдә — яһүд башлы, Алтын Урда бәдәнле, совет халкы дигән әзмәвер барлыкка килде.

## АВТОРНЫ ТАНУ ӘМӘЛЕ

Хәзер кем генә һәм нәрсә генә язмый, һәр язманы «авыру тарихы» дип карап, авторга диагноз куярга мөмкин. Әмма аның наданмы, мокытмы икәнен тәгаенләгәндә, буталулар дәвам итә. Моннан котылу өчен «мокытлык» һәм «наданлык» сүзләрен кояшка куеп карыйк: берсенең эченә «кытлык», икенчесенекенә «дан» һәм «данлык» оялаган.

Димәк, аң дефициты, акыл кытлыгы сизелеп торган мәкалә, әсәр, язмалар — мокытныкы, мин — фәлән, дип кукраеп, фәнни төсмер бирергә көчәнеп, катлауландырылган сафсаталар артында — надан автор.

## СУКМАКЛАР ЮГАЛМАГАН

Безнең палатада, тәрәзә буенда, экс-архитектор ята. Бик күп белгәнгә күрә эләккән ул монда. Аның сөйләнгәннәре истә калган: «Архитектурабызның мәңгегә юк ителүен күңел күтәрми. Иманым камил, юк ителгән архитектурабызны кире кайтару юллары калдырылган. Криминалистлар бер чәч бөртегеннән дә әллә никадәр мәгълүмат «сыгалар». Ә безнең бит әле чәч кенә түгел, башлар да исән. Арада Роальд Сәгъдиев, Гата Камский кебекләр дә очрый. Безнең мең бизәкле гаҗәеп сабан туебыз исән! Ак сөлгеле аксөяк көрәшебез исән. Тарихи ядкарьләребез арта тора. Һәрнәрсәдә мәгълүмат йөге бар. Татар кулы тудырган йорт-җир, каралты-кура, тегү-чигү эшләре, кабер ташлары... Болар бит һәммәсе мәгълүмат чыганагы! Тукаебыз сихерле көзге дип санаган халык җырлары... Алар бит туган туфракның кайдалыгын, нәселебезнең каян таралуын кычкырып әйтеп торалар! Дөрес, татар җырының Кытай, Корея, Лаос, Япон, Вьетнам моңнары белән чагыштырганда үзенә генә хас аерымлыгы ярылып ята. Монысы, мөгаен, туган җирдән алынган моңыбызның ислам аһәңе белән сугарылуыннандыр. Чын татар җыры башкарылганда, тамашачылар, җырчы тынып калгач та, үзләренең кайдалыгын абайламый гаҗиз тора, ә аннары... дәррәү алкышларга керешә. Күрәсең, моңыбыздагы ислам аһәңе күңелләребезне кыйблага түндерә... Бу дәһриләр динне тыйган елларда да күңелләребез сәҗдәне онытмаган дигән сүз. Инде дошманнарыбыз да моңа төшенде һәм бүген моңыбызга каршы чып-чын аяусыз сугыш бара.

Тагын бер байлыгыбыз исән, ул — туган тел.

Бүгенге компьютерга бер телдә яңгыраганны икенче телгә авыштыру берни тормый. Мәйданга яңаданяңа компьютерлар килә тора һәм беркөн музыка яки поэзия телен архитектура теленә «тәрҗемәләргә» сәләтлеләре дә килү ихтималы юк түгел...»

## ТАТАРНЫ НИШЛӘТЕРГӘ?

Янәшә койкадагы икенче күршем дә суга төшкән тавык кына түгел, ә кандидат наук! Ул гыйльми дәрәҗәгә «Ла-лә кушымчаларының нык үскән социализм шартларында сугышчан роле» дигән темага диссертация яклап ирешкән. Ә менә докторлык үрен алырга теләп язган хезмәте барып чыкмаган. Аның «Лар» кушымчасы фашистлар, урыслар яки коммунистлар сүзендә дә бер үк функция үти» дигән нәтиҗәсе кемнәргәдер ошамаган... Зарар юк, ул шушыннан торып та Гыйлем Тулгаков кушаматы астында төрле гәзитләргә мәкаләләр җибәреп ята, берсен бер калдырмый басалар. Аның белән бәйле бер әңгәмәне бәян итәм...

+ + +

— Йосыф Акчура, Фатих Әмирхан, Галиәсгар Камал кебек ак якалар татарга үзенең кемлеген танытырга базмадылар. Әмирхан Еники, Мөхәммәт Мәһдиевләр дә мескен татарны сокланып сурәтләүдән арына алмадылар. Дөреслекне ачып салырга президент та, ул куйган башлыклар да йөрәксенмәде. Бары тик халкыбызның фәкыйрь катламыннан, тормышның төбеннән күтәрелгән зыялыларыбыз гына икейөзләнмичә һәм курыкмыйча: «Татар — хөсетле», «Татар башын татар ашый» кебек аксиомаларны милләтнең чыраена чәпи алдылар!» — дип башлады сүзен Гыйлем Тулгаков.

Архитектор булып озак еллар эшләп, бер тапкыр да архитекторлыгын эшкә җигә алмаудан кәңкәйгән бүлмәдәшебез, галимне бүлдерергә җөрьәт итә:

— Бу аларның үз даирәләреннән чыгып ясалган уңышсыз фәлсәфәсе.

Тулгаков моның авызын тиз каплады:

— Татар бүген дуңгыз асрый, безнең авыл малайлары бер әбине көчләде, ә әбинең оныгы фәхишә булырга хыяллана, менә ул синең татар рухың! Архитектор мәгълүматлы, эшсез йөреп күп укыган.

— Әйтик, статистика үз-үзенә кул салуларны күбесенчә угро-фин халыкларына хас дип яза... Ә синең әби мәсьәләсендә Россия халыклары башка кыйтгалардан әлегә нык калыша. Мондый төр җинаятьләр һәм фәхишә булырга талпынулар белән татар рухы арасында бәйләнеш күрмим, — ди.

Алай гына җиңәрсең кандидатны...

— Күзеңне ачыбрак кара. Әнә гәзиткә берсе яза, мәчеттә урысча вәгазь укыйлар икән.

Архитектор да үҗәт.

— Элек җыелышта бер урыс булса, йөз татар урысчага күчәргә мәхкүм иде. Әлеге тарих мәчеттә кабатланмасмы, урыс теле мәчет түренә бер үтсә, аннан татар телен мәңгегә сөрмәсме соң? — ди.

— Нинди тар караш, — дип, башын чайкый кандидат. — Безгә яһүдтән үрнәк алып, үз идеологиябезне башкаларга сеңдерергә кирәк.

— Яһүдтән үрнәк аласы булгач, нигә Талмудка яки яһүдләрнең яшәү кодексы «Кицур шулхан арух»ка тотынмаска? Бит, яһүдкә дә охшап, Коръәнгә дә тотыну абсурд, бу монафикълыкка өндәү түгелме?

— Хак мөселман булып яшәү әллә рәхәтме?

— Монафикълар тибә бүген дөньяның арт шәрифенә! Татарга бердәнбер дөрес юл — ул да булса, монафикълык! Дәүләтебез даирәләре дә шул юнәлештә тырыша түгелме: мәчет төзүне дә яклыйлар, аракысыра бизнесын һәм дуңгызчылыкны чәчәк аттыру өчен дә җан аталар!

Әлбәттә, архитектор бәхәсне оттыра. Ә кая барасың, хакыйкать үҗәт бит ул...

## ӨЙГӘ ТАШУ

Әле кайчан гына кеше өчен төп инстинктны Шароун Стоун төшкән Америка фильмы бәянынча кабул итәләр иде. Татар галиме Альфред Мостафин ул теорияне чәлпәрәмә китерде, баксаң, төп инстинкт-конкурентлык, көндәшлек инстинкты икән.

Сүз дә юк, алда телгә алынган инстинктлар кеше өчен бик мөһим, әмма иң төп дигәне, минемчә, тегесе дә, монысы да төп түгел, ә өйгә ташу. Бал кортлары, йомран-әрлән генә түгел, кеше-бахырның да гомере өйгә ташу әвәрәсеннән гыйбарәт ләбаса.

Тарихка күз салсак, барлык яу чабуларның асыл максаты, ганимәт малын өйгә ташуга кайтып кала. Хәтта балаларның өйгә кайтып әләкләшүе, ир-атның эштәгене хатынына кайтып сөйләве, Американың, демократия байрагы күтәреп, Гыйракка баруының асыл максаты да, төптән уйлаганда, өйгә ташуга кайтып кала.

Рәсәйнең кай түрәләре байлыкларны чит илгә, чит ил банкларына озаталар икән, димәк, адреслары үзгәргән, шул илләрдә йорт җиткезгәннәр.

Хәтта Сталин ГУЛАГында утыручыларның исән калган кайберләре буш кайтмады һәм кичерешләрен китапларга әйләндерә алды. Җәлил шигырьләренең Моабиттан өенә-иленә озатыла алуы да бер могҗиза. Баксаң, юләрләр йортыннан да буш кайтмаска була икән...

## КӨН ТӘРТИБЕНДӘ НИ?

2003 елда узган Ислам конференциясендә Малайзия премьер-министры Махатхира Мөхәммәд (аның чыгышын интернеттан табып була) мондый сүзләр әйтте.

«...Үзегез уйлап карагыз, безгә уйлы, фикерле кешеләр (сүз яһүдләр хакында бара) каршы тора. Алар 2000 ел дәвамындагы погромнардан кара-каршы сугышып түгел, ә уйланулар аша исән калдылар, эзәрлекләнүләрдән котылу һәм тигез хокуклардан файдалану өчен социализм, коммунизм, демократия, кеше хокукларын уйлап таптылар һәм эшкә ашырдылар. Шулар аша дөньядагы иң куәтле илләрне контрольгә алдылар. Һәм ул, шушы бәләкәй халык, дөньякүләм көч булып әверелде...

Мин, әлеге форумның эчтәлегенә үтеп, якларны хупларга яки гаепләргә базмыйм. Күңелне кайдадыр көн тәртибенә милләтләр язмышы куелып тикшерелүе җәлеп итә. Дөрес, безнең дә җыелыш күргән бар, әйтик, авыл җире җитәкчеләре, шәп машиналарда кыр казларыдай тезелешеп, күчмә семинарлар уздырырга ярата... Көн тәртибенә иген уңышы күләме яки дуңгызларның баш санын арттыру мәсьәләләр күтәрелә. Чиновниклар шәһәрчекләренә әйләнгән район үзәкләрендә оешмалар бихисап. Крәстияннең юка кесәсен капшауга көйләнгәннәре дә байтак. Ә менә авыл халкына эшләгәне өчен рәтле түләү оештырылмаган шартларда хет шәхси хуҗалыгында үзе җитештергән ит, сөт, бәрәңге кебек продукциясен кыйммәткәрәк сатарга булышучы, төрле базарларга юл ача торганнары юк. Республиканың югары даирәләре, чит төбәкләргә һәм илләргә чыгып, төрле килешүләр төзиләр, ул төбәкләрдә вәкилләребез дә утыра, әмма алар да авыл халкыбызны милекче итү турында кайгыртмый, базарларга юллар ачмый... Мөгаен, җир милек буларак алдарак завод-фабрикалар, рудниклар сыман «лаеклы» затларга беркетелеп беткәч, хәл үзгәрер. Ул заман ит, сөт, бәрәңге бәяләре дә, газ, бензин, электр тогы сыман текә күтәрелер һәм тиз үсә торган булыр...

«...Татар түрә булса, чабатасын түргә элә», «Урыс барда, милость бар», кебек мәкальләр әйләнештә. Әллә урыс түрә татар коллегасыннан әйбәтрәкме? Беләм, «әйе» диючеләр, мисаллар китереп фикерен дәлилләүчеләр табылачак. Хикмәт нәрсәдә соң? Ул шунда, түрә булам дигән урыстан, һәрхәлдә, коммунистик хакимият чорында, үз милләтенә карата хаинлек, битарафлык таләп ителмәде һәм бу җәһәттән караганда, әлбәттә, ул кеше буларак «интернационализм»га мәхкүм милләттәшебез түрәдән югарырак рухи баскычта торды.

Мәгълүм ки, Якутстан һәм Чукотка тәхетенә мәскәүләр менеп утырды. Инде Башкортстан тәхете өчен тарткалаш бара. Димәк, чират безгә килеп төртелгән һәм көннәрдән бер көнне без дә президент итеп мәскәүлене сайлап куймагаек. Бәлки ул, милләтчелектә гаепләнүдән курыкмыйча, татар телен Рәсәйдә икенче дәүләт теле статуслы итә алыр, Казанда юк. Татар университетын Мәскәүдә ачып җибәрер, Сөембикәгә, Сәйдәшкә һәм Казанны яклаучыларга лаеклы һәйкәлләр салдырыр, шәп проспектларга исемнәрен бирдерер?.. Югыйсә сары киемле шпал күтәргән татар хатыннары язмышына турылапмы, җир астын казучы машинага Сөембикәбез исемен чәпәгәннәр. Хәер, элегрәк, Яшел Үзән каласындагы бер спорт командасына да «Сөембикә — Зилант (Җылан)» исемен биреп, ханбикәбезне һәм аны сагынучы халкыбызны «олылаганнар» иде... Җөмһүриятебездә хакимлеккә мәскәүле утырса, безне бәлкем бу кадәр хәкарәтләмәсләр? Айһай... лүк... Күреп торабыз, телебезне, хәтта президент булу хакына да өйрәнәсе килми татар түгел кандидатларның, черәшеп, милли республика президенты ике дәүләт телен дә белергә тиеш дигән нормага каршы көрәшәләр. Ә моны ничек аңларга соң? Безнең мәхәббәтебезне казанып, тавышларыбызга өмет баглаучы бу кандидатлар шулкадәр риясыз ки, телебезгә, димәк ки, үзебезгә карата да асыл мөнәсәбәтләрен вакытлыча гына да томалый алмыйлар дипме? Шунсы анык, әгәр Татарстанга ятлар хуҗа булып алса, «Рубин» асрап интекмәбез, чукчаларныкы шикелле безнең дә Европаның берәр илендә үз «Челси»ебез уйнар.

## ТАТАР ҺӘМ ҺӘЙКӘЛ

«Сәйдәшкә һаман һәйкәл юк» дибез, ә ул халкыбыз күңелендә әллә кайчан бар, мәһабәт һәм күркәм. «Бер кирәкмәгән фәлән-фәләннәргә һәйкәлләр салынды» дип сукранабыз, ә халык күңелендә кемнәр, нинди генә мөнбәрләрдән бөек, даһи дип кодаламасын, андыйларга анда урын юк, булмады һәм булмаячак... Чөнки Дәрдемәнд әйтмешли, «ил мөмәез, аңлар ул тиз, син аны сизмәс димә...» Әйтик, Сәйдәшне, Солтан Габәшине, Фәрит Яруллиннарны яраттыру өчен халыкны үгетлисе юк, ә бәгъзеләрне ничек кенә күкләргә чөймиләр, ә нәтиҗә нүл... Җирдәге һәйкәлләр, халык күңелендәгесенең гәүдәләнеше... булырга тиеш. Ха-

лык күңелендә һәйкәле юк шәхескә, иң биек урында күкләргә ашып торган истәлек корылма күтәрсәң дә, аның барлыгы шәйләнми икән ләбаса.

Ахрысы, бүгенге вазгыятьтә шәхес халык өчен никадәр сөекле, шуңа кире нисбәттә һәйкәле күтәрелү ихтималы ерагая... Яки халык күңелендәге һәйкәл никадәр зур һәм биек, аның җирдәгесен булдыру шулкадәр авыр һәм катлаулы. Һәм, киресенчә. Алайса ничек Тукайга салынган соң дияр, хөрмәтле укучы. Мәскәү раслаган норма буенча, бөек урыс халкына — фәлән, союздаш статуслы кавемнәргә — төгән, ә икенче сорт автономияле халыкларга, шул исәптән татарга да (башкалардан ни дәрәҗәдә түбән куелуын һәр мөмкинлектә, хәтта шушы бүленеш аша да искәртү зарур дип табылган) бер-ике шәхесенә һәйкәл салырга рөхсәт бирелгән... Алда бәян ителгән тәңгәл килү аркасында әлеге һәйкәл башкалардан нурлырак һәм биегрәк тоела. Рөхсәт бирүчеләр «ялгышларын» тиз төшенгән, ләкин бер салынган һәйкәлне кире сүтү матур түгел. Шуңа булганының дәрәҗәсен яртылаш төшерү максатында, Тукайга, опера-балет театрының кеше күрми һәм бик йөрми торган ягындагы комырыкка тыгып, тагын бер нөхсә һәйкәл булдырылган... Сәйдәшкә һәйкәл салынмау кайчандыр Мәскәүнең аңа бюст корырга гына рөхсәт итүе, аның халкыбыз күңелендә артык биек урын биләве һәм талантының хакыйкыйлыгы аркасында...

## «САСЫКБАЕВЛЫК ЗӘХМӘТЕ»

Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы? Татарның җелегенә төшкән шушы четерекле сорауга Достоевскийның мәшһүр «Бертуган Карамазовлар» әсәре азмы-күпме җавап бирә шикелле. «...Ул чакта (сүз 1812 елгы сугыш хакында бара) французлар җиңсә әйбәт кенә булыр, акыллы милләт мокыт милләтне үзенә кушар да... бөтенләй башка тәртипләр урнашыр иде...» Әлеге роман персонажы Смердяков шулай фикер йөртә. Ватанын, милләтен дошман күрүченең чыгышын да, язмышын да бөек язучы җирәнгеч һәм кызганыч итеп сурәтләгән. Смердяков — азгын бариннның «Смердящая», ягъни Сасы кушаматлы, сукбайлыкта йөрүче юләр хатынга төшкән «мәхәббәт» җимеше, социаль статусы — лакей. Кыскасы, фараз шундый — милләтебез үлмәгән дә, йокламаган да, аңа «смердяковщина» дигән чир, үзебезчәгә тәрҗемәләп әйтсәк, «сасыкбаевлык зәхмәте» кагылган. Әйтелгәнне дәлилләү максатында кайбер фактларга күз төшерик. Үз балалары яисә оныклары белән урысча гына аңлашып, аларны аңлы рәвештә туган телләреннән мәхрүм итүче әти-әни, әби-бабайларыбыз... Бакчаларда, шовинистлар таккан программага эт тугрылыгы саклап, балаларны милли рухтан аралаучы милләттәш тәрбиячеләр...

Кабалевский кабаласы ярдәмендә милли моңнан аралаучы музыка мөгаллимнәребез.

Аудиториянең күпчелеген татарлар тәшкил иткәндә дә (100% саф татар аудиториясенә ирешеп булмый, чөнки без бандустанда яки резервациядә яшәмибез) «кайсы телдә сөйлик микән» дип, кәнтәй хатыннар сыман боргаланучы җитәкчеләребез...

Башка телләрне туган тел нигезендә өйрәтү урынына, табигый акцентның тамырын корыту аркылы, ни урысча, ни татарча мөкәммәл сөйләм культурасыннан мәхрүм милли гермофродитлар әвәләүче мәгариф системабыз һәм алгы флангта атлаучы урыс теле укытучылары. Соңгылары, укыту эшенә баш булып алып, туган телебезне, гореф-гадәтләребезне, язуыбызны мәктәпләрдән сөрү белән генә канәгатьләнмичә, ата-аналардан балалары белән хәтта өйдә дә туган телдә сөйләшмәүне таләп итүгә кадәр барып җиттеләр. Кызык, нинди стимул аларны үз милләтләренә, туган телләренә дошманлыкта шул дәрәҗәдә ашкындыра икән? Совет чорында татар балаларына урыс теле укытучыларына өстәмә утыз тәңкә акча түлиләр иде. Утыз тәңкә көмеш... Бу бит Иудага түләнгән хак... Миңа калса, күп кенә милләттәш урыс теле укытучыларында «сасыкбаевлык зәхмәте»нең котырган формасы күзәтелә...

Дәвалауда мөһим шарт буларак, пациент белән тәмле итеп үз туган телендә сөйләшү зарурлыгын медицина таный. Ә Казан медицина институты татар телендә камил дәрәҗәдә аңлаша алырлык табиблар әзерләүне үз бурычы итеп санамый...

«Сасыкбаевлык зәхмәте» юлларда йөргәндә аерата күзгә ташлана. Тәре конструкциясенә беркетелгән күрсәткечләр бихисап. Атамаларыбыз да, бала чакта артына салам кыстырып, атлы уйнаган кызыл таракан мисалында. Җыр канатларында яшәүче Сарман — Сарманово, Кукмара — Кукмор. (Әле ярый анысын Кикимора, ә Казанны — Казаново дип тәгаенләмәгәннәр!) Курсабаш авылы Корсабаш булган... Баксаң, татарның У хәрефе урысча О, имеш. Ә татарның Я хәрефе? Апас ягыннан бер танышым Ябалак авылыннан булуын һәм документында авылы исеме бер хәрефкә, «Я»ның «Е»га үзгәртеп язылуын сөйләгән иде. Бәлкем ул шаярткандыр да, әмма «Я» ның «Е» га тәрҗемә ителүе Саба районында да раслана. Яблаштау авылының урысчасын Евлаштау, ә татарча исемен Явлаштау иткәннәр. Татарчасын төзәтмәсәң, шуны урысча язганда ямьсез сүз чыга, имеш.

«Сасыкбаевлык зәхмәте» күптәнге чир. Шаһгали, Камай морзалар да әлеге зәхмәт корбаннары. «Революция җиңсен өчен бер милләтне корбан итәргә дә була» дигән «теория» (сүз татар хакында) белән коралланган Сәетгалиев фамилияле җитәкчебез дә булган безнең... Аның исемен кадерләвебез, мәйданнарга, мәдәният сарайларына биреп, мәңгеләштерүебез дә хак... Зур химияле, КамАЗлы, АлАЗлы, АЭСлы итеп, килмешәкләр ташкынына юл ачып, татарны үз җөмһүриятебездә азчылыкка калдыру юнәлешендә аерата күп тырышкан җитәкчеләребезне дә хөрмәтлибез...

Җитәкче дигәннән Чыңгызхан, Аксак Тимер, Наполеон, Ленин, Сталин, Гитлер, Суворов, Кутузов һәм башка бөекләр өчен йөз меңнәрнең гомерен кыю берни тормаган. Кечерәк җитәкчеләр дә үз кәнәфиен, ягъни үз биләмәсен саклап калу, киңәйтү өчен көрәшә. Көн дә! Әгәр шул юлда алар кемнәрнедер рәнҗетә яки харап итә икән, бу бик тә табигый, чөнки барысы да бер камырдан, үлчәм-масштаблар гына төрле. Бакчы, Башкортстан тәхете өчен көрәш ничек аяусыз башланып китте. Әмма минем карашымча, моңарчы анда эшләгән «лидерлар»ның гамәлләре дә шуны раслый, кем генә җиңеп чыкса да, тәхет иясеннән бер нәрсә, милләтебезгә золым күрсәтү таләп итәчәкләр. Аерма тик шунда, берәүләр моны теләр-теләмәс, теш кысып, ә бәгъзе «сасыкбаевлар», рәхәтләнеп, тәм табып һәм кушканнан арттырыбрак та башкарыр...

Парламентыбызның татарча исемен алыйк: «Югары Совет». Урысчадан тулы канлы калька булса да, ул «Югары Киңәш» дип аталыр иде. Шулай тәрҗемәләргә дә куәте җитмәде бит безнең депутат-сасыкбаевларыбызның.

Ассызыклап шуны әйтергә мөмкин: урыслар, җиде ятка табынучы үз Смердяковларын яратмасалар да, башка милләт Смердяковларын интернационалист дип олылыйлар...

## АК КАЕННАР АЕРМАСЫ...

Ак каеннар бездә төз, матур, ә Карелиядә бәләкәй һәм бөкре булып үсә. Аерма — Швеция һәм Рәсәй социализмнары төслерәк. Рәсәйдә башкалар үрнәгенә карап иҗтимагый стройны үзгәртү көткән нәтиҗәне бирми. Хикмәт шунда, Герцен әйткән һәм Ленин тәгаенләгәнчә, хактан да, Рәсәй — халыклар төрмәсе... Социализм атлы җәмгыять төзү аның асылын түгел, ә андагы режимны гына үзгәртте. Совет чорында хәтта халыкларны төрмә иерархиясе принцибында сортларга аеру рәсмиләштерелде... Демократия матур яңгырый, ә төрмәдә демократия урнаштыру беспредел тудыра, һәм мәхбүсләр өчен барыбер дисциплина кулайрак... Сталин, Андроповларны сагыну артында шул ята... Халыклар төрмәсендә һәрвакыт гадел паханга өмет баглыйлар. Горбачев — үзен бу сыйфатта раслый алмады һәм аны әлеге рольгә яраклы Б.Н.Ельцин «кесәсенә салды». Ә В.В.Путин бер җөмләсе белән әлеге постка очраклы рәвештә килмәвен раслады!

Рәсәй колониализмы башкаларныкыннан, шул ук инглизләрнекеннән принципта аерыла. Инглизләр, бездән аермалы буларак, зек менталитетыннан ерак, алар гомер бакый хөр халык. Инглиз җәмгыятендә закон каршында һәркем тигез. Шушы үрнәкне күреп, буйсынудагы халыклар да азатлыкның шундыена омтыла. Буйсындыручылар да, бигрәк тә аның зыялылары мондый омтылышны хупламасалар да, аңлап кабул итәләр. Нәтиҗәдә — азатлык котылгысыз. Бездә хәл үзгә. Урыс азат түгел, һәм ул иң борынгы зек. Һәм ул башкаларның азатлыкка омтылышын, минем белән бер казаннан ашарга «за падло что ли» диебрәк кабул итә. Армиядә дә солдатларның ярты ел дәвамында өлкән иптәшләреннән шакшы золым күрүе, аннары золымчылык эстафетасын кабул итеп алып, яңа килгән солдатларга карата күчереп арканлавы — закончалыклы процесс. Балалар бакчаларында, мәктәпләрдә төрмә әлифбасын үтеп килүчеләр биредә практика узып, империя гражданины булырга имтихан тоталар.

Рәсәй колонистының рухи портретын Достоевский үзенең китапларында бирә барган. «...Село Степанчиково и его обитатели» әсәрендә ул аны Фома Фомич образы аша күрсәтә. Приживальчик Фома Фомич, туендыручыларының сыртында паразитлык итүе өстенә, алардан үзе каршында биеп торуларын, аны өзелеп ятратуларын һәм мәхәббәтләрен даими исбатлап торуларын таләп итә. Милли республикалардагы шовинистларның гамәлләре бүген шундыйрак.

«Җинаять һәм җәза» романындагы Мармеладовның рәнҗетелүче позасына басуның рәхәтлеге турындагы фәлсәфәсе! Безнең парламентта Татарстан мөстәкыйльлегенә каршы чыгучылар шул позага басарга ифрат яраталар.

Рәсәй тарихы матур итеп язылган. Әмма вакыт-вакыт тарихи дөреслеккә дә юллар ачылып куя. Хикмәт шунда, Горгоны тораташ итүнең юлы — аңа үз-үзен күрсәтү. Узган гасыр башында коммунистлар, ә азагына җиткәндә демократлар, аңа асыл кыяфәтен күрсәтеп, параличладылар.

...Һәр проект этаплар аша тормышка ашырыла. Әйтик, Рәсәйне кулга төшерү өчен иң әүвәле «долой царя» шигаре тормышка ашырылды. Халыкның, халыкларның нигезен авыл тотып тора, димәк, эшне «долой помещиков» дип дәвам итү муафыйк булган. Аннары чират «долой кулаков»ка барып чыккан. Ә бүген

авылда калган, калдык өлешнең язмышы хәл ителә. Хезмәт хакы түләмиләр икән, димәк, проектта шулай каралган дип аңларга кирәк... Данлы эшче сыйныфы да элекке сәләтеннән ерак, чөнки ул инде «потомственный» түгел, ә күпчелеге маргинал, кичәге крәстиян... Татар халкының да төп проблемасы — затлы катламнарының кат-кат юк ителүендә, һәм бу процесс туктамаган.

Халыкка золым итүнең иң ансат юлы — эш башына талантсызны, затсызны, наданны утырту. Шулай эшләгәндә әлеге «шәхес» барлык талантлыларга, белемлеләргә, затлыларга каршы сугыш ача... Бездә граждannar сугышының әнә шундый төре дәвам итә. «Мин — начальник, син — дурак, син — начальник, мин — дурак!» дигәннәре дөреслеккә туры килми. Гади кеше дуракланып кына карасын, аны хәзер акылга утырталар. Ә менә начальниклар кыланып күрсәтә... Аларга мөмкин, номерлары үтә...

## ҮЗГӘРТЕП КОРУ ДӘВАМ ИТӘ...

Диктатура белән демократиянең аермасы нәрсәдә? Миңа калса, икенчесе беренчесенең югарырак формасы, беренче очракта халык-сарыкны бүре тотып ашаса, икенчесе шартларында халык-кролик питон авызына үз «ихтыяры» белән барып керә... Ә кешенең ихтыяры белән идарә итү, аңын манипуляцияләү функциясе массакүләм матбугат чараларына йөкләнгән. ОМП (оружие массового поражения) дигән аббревиатураны татарчага күпләп яки массакүләм юк итү коралы дип тәрҗемә иткәннәр. Дөресе, минем карашымча, массакүләм җимерү коралы. ГОны (гражданнар оборонасын) кайгыртучылар мондый кораллар исемлегенә иң куркынычларын, аңны һәм рухны агулый, җимерә торган, массакүләм мәгълүмат чараларын, һәм рок, поп-музыканы кертми калдырганнар. Әлеге кораллар дөньяның теләсә кайсы почмагына урнашкан теләсә кайсы илен «утка тотып», гражданнарының ихтыярын параличлый, чарасыз калдыра ала. Рухи җимерү төрләренә бирешмәүче халыкларга каршы коралның физик яктан юк итә-җимерә торганнарына мөрәҗәгать итәләр яки комплекслы кулланалар.

Рухи җимергеч коралларның төп төрләре (музыкаль юнәлештәгесе хакында сүз алдарак булыр) чишмә башында демократик әдәбият һәм шуның теле-кино чыганаклары торуын искә төшерик. Әйтик, Һиндстанда төп халык касталарга бүленгән һәм әлеге структура ятларның бу ил хакимиятенә үтеп керүенә күп дәверләр киртә булып хезмәт иткән. Димәк, боларны буйсындыру, мөлкәтләрен таларга омтылучы ятлар өчен әлеге милли саклану чарасын идеалда милләтнең үз кулы белән җимерергә кирәк. Ярдәмгә «демократик әдәбият» килә. Һәм демократ язучы илдә яшәп килгән дин-йола аркасында бәхетсезлеккә, фаҗигагә дучар булган саф мәхәббәт турында кыйсса яза. Шул әсәр нигезендә фильмнар төшерелә. Нәтиҗәдә, җирле халык күңелендә, яшәп килгән дин-йолаларга, ә асылда, үз милли дәүләтчелегенең яшәү шартына каршы агулы протест орлыклары чәчелә. Әлеге сюжет барлык халыкларның «демократик әдәбиятларында» да җирләштерелгән. Татар милләтен харап итү өчен иң кулае, саф мәхәббәт хакына катнаш никахны яклау, татар хатынын «азат итү» өчен, милли гадәткә, дингә, динчеләргә каршы көрәшү иде. Татар демократик әдәбияты нәкъ шул юнәлештә үзен тапты, һәм бүген ул чәчкән орлыкларның җимешләре дискотекаларда чишенеп биюче, панельгә чыгучы, зиначы «милли туташларыбыз» буларак гәүдәләнеш ала... Ягъни «демократик» әдәбият, «демократик» матбугат — болар милләтләрне милләт буларак бетерү, аларның фундаменталь саклану структураларын җуйдыру, милли төсмерсез калдырып, халкын мутантлаштырып, Дөнья Хөкүмәте кабаласына төшерүне күздә тота. Әйтергә кирәк, урыс кабаласыннан соң мондый метоморфоза безгә хакыйкый азатлык булып тоелырга да мөмкин.

Җир шарында кеше бик күбәйде һәм фәнни-техник революция роботларга «җан» өреп тә «артык кешеләр» проблемасын кискенләштерде. Хәер, ник әле ике куянның койрыгын берьюлы тотмаска, нигә дип кыйммәтле материаллар һәм күп акча сарыф итеп роботлар ясап интегергә? Ник аларны ясауда нигез итеп арзанлы һәм дефицит та булмаган чимал, кешенең үзен алмаска?

Хәзерге Америка киноларында робот-монстрларның кешеләргә, кешелеккә каршы көрәше сурәтләнә. Америка киноларын биш минут карагач, аның ничек тәмамланачагына төшенеп була. Миңа калса, ул фильмнар, боевиклар, детективлар, эротика, триллерлар берсе дә кеше өчен түгел, ә ярымкешеләр, биороботлар һәм биороботлыкка рекрутланучылар өчен рухи башак. Үзгәртеп кору чорыннан соң Рәсәй халкы да Америка киносәнгатеннән авыз итә башлады һәм аның яшь буыныбызга тәэсирен киләчәктә күбрәк аңларбыз. Ә Американың үзендә шушы «сәнгатьтә» тәрбияләнүче буыннар кат-кат алмашынган! Халыкларны, кавемнәрне роботлаштыруда музыканың рок һәм попса аты алган мутация җимеше төрләре үтемле чара. Ислам тәгълиматы буенча, кыямәттә бәндәнең һәр әгъзасы хуҗасына бәйсез, ягъни автоном рәвештә үзенең ни кылганын бәян итәчәк, диелә. Бию — шулай ук тел, жестлар теле. Дискотекаларда яшьләрнең әгъзаларын шушы телдә, бер-берсеннән мөстәкыйль, автоном хәлдә «сөйләштерәләр», түгелме соң? Бит биредә, бернинди санитария нормаларына сыешмаган ешлыкта (медицина кая карыйдыр?), атомны электроннар белән бомбалап таркаткан шикелле, кешенең һәр күзәнәгенә тәэсир итеп, аның һәр әгъзасының

мөстәкыйль рәвештә бию трансына бирелүенә ирешәләр... Бер могтәбәр танышым әйтә, «рок — наркотикка каршы» дигән сүз, бензин сибеп ут сүндерик дигәнне аңлата, балаларга сексуаль тәрбия һәм белем бирү, аларны аздыру-бозуны, эротика һәм порнография аермасы хакында дискуссия оештыру, порнографиягә пропаганда өчен эшләнә, ә тәмәкегә һәм аракыга каршы көрәшләр, шулай ук яшерен, үзенчәлекле рекламаны үз эченә ала, ди. Танышым белән килешкән хәлдә, өстәп, милләтне роботлаштыру-мутантлаштыру өлкәсендә бүгенге татар эстрадасының да роле хакында тукталмакчымын. Күптән түгел чын, хакыйкый үзенчәлекле тавышка ия җырчы Фердинанд Сәлаховның концертын карарга насыйп булды. Концерт уртасында ул, «япон тактасын» туктатып торып, баянга, ягъни тере музыкага кушылып, халкыбызның «Бөдрә тал»ын җырлады... Әйтерсең безне электр дулкынлы мич камерасыннан азат иттеләр! «Ямаха»дан тавыш көчәйткеч аша ыргылып, идән-түшәм-диварларга бәрелеп, чәрдәкләнеп рухыбызны атакалаган югары дицебеллы тавышлар фетнәсен көтмәгәндә моң алмаштырды. Шунда ук җанны изеп, кысып, басым астында торткан бинаның түшәмнәре күккәчә, диварлары офыкларгача киңәйде. Аһ, безнең халык җырлары... «Иске кара урман», «Җанкай-җанаш», «Гөлҗамал», «Тәфтиләү», «Кәккүк» — болар җыр, чын җыр, даһи җырлар... Хәзерге җырчылар иске җырларны җырламый, диләр. Ә бит җырлар өчен башта әле җырчы булуың шарттыр... Бүген сәхнәдән җыр дип тәкъдим ителгән күп нәрсәләрнең җырмы-түгелме икәнен, бәлкем, хакыйкый композиторларыбыз, соңгы могиканнарыбыз Шамил Шәрифуллин, Мәсгудә Шәмсетдинова, Ренат Еникеевлар әйтергә өлгерер? Ә минем карашка болар нindидер наркотикка алмаш аракы, сыра рәтендәге акча эшләү өчен кешенең организмын дискотекалар үрнәгендә бию, ритм трансына кертеп исертү чарасы (әлбәттә, «текә» дискотекаларны, исерткеч буларак, алтынны эретергә сәләтле «царская водка»га, ягъни сульфат һәм хлор кислоталары кушылмасына тиңләсәк, боларныкы Минзәлә аракысыннан ерак китми). Бәлане хәерчелегебез дә катлауландыра... Тере оркестрлар, тере инструменталь ансамбльләр чыгымнар сорый, ә шәп музыкаль коллективларны элек-электән корольләр, аксөякләр асраган. Татар аксөякләре соңгы тапкыр 17 нче елда юк ителде, димәк, без фәкыйрьләргә, оркестрга имитация, «Ямаха»да җитеп ашкан... Суррогат «җыр сәнгате» үрнәгендә, татар матбугаты мәйданына шундый сорт гәзитләр дә күренә башлады...

Закон тәртибендә һәртөрле продукциягә дәүләт стандартлары билгеләнгән. Тиешле таләпләргә җавап биргән продукция өчен генә сертификат бирелә. Әгәр җитештерүче брак чыгара башласа, сертификат кире алына. Әйтик, кирпеч дивар өю белән шөгыльләнә торган фирмага лицензия алу өчен, эшчеләренең ПТУ бетергән, прорабының шул өлкәдә белеме һәм эш тәҗрибәсе булуы шарт. Сәхнәгә чыгучылар да нindидер элементар таләпләргә җавап бирергә тиеш сыман. Ягъни лицензия һәм сертификат, кулланучыны намуссыз җитештерүчедән бу өлкәдә дә яклауны тәэмин итәргә, (СССР чорында җырларны ВААП (Всесоюзное агентство авторских прав) экспертиза үткәреп теркәгәч кенә, янә радио-телевидениенең Сәнгать киңәше (худсовет) аша үткәннән соң гына эфирга чыгаралар иде.) концерт эшчәнлеге белән шөгыльләнүче төркемнәрнең дә андый хезмәт өчен лицензияләре булырга, ә репертуарлары мәгълүм бер стандартларга җавап бирергә, халтурага авышкан очракта лицензияләре мәгълүм срокларга, ә кайбер очракларда бөтенләйгә кире алынырга тиеш кебек... Ә бу эшләнми. Димәк, дәүләтне никтер проблема әлегә кызыксындырмый һәм шәхесне урта куллаштыру бу юнәлештә дә кызу темплар белән дәвам итә.

Лицензия дигәннән, күптән түгел «Татарстан яшьләре» гәзите битләрендә «Кыр казлары артыннан» дигән җан тетрәткеч мәкалә дөнья күрде. Анда сүз түрәләрнең, лицензия алып, меңнәрчә чакрымнар очып, безгә, бәби чыгарам дип кайтучы ябыгып беткән кыр казларын, җырларыбыз түрендәге киек казларны атулары хакында бара. Мәкалә авторы гаепләвенә каршы әлеге сунарчылар «чәчүлекләрне таптаучы кыр казларын атарга рөхсәт ителә» дигән язу чыгарып күрсәткәннәр. Әйтерең генә бармы, кая карама Шомбай стиле!.. Димәк, лицензия ярдәмендә генә әлеге үзлеге бәладән котылып булмастыр. Чөнки бу табышлы эшкә дә музыкаль Шомбайлар баш булып алып, чын талантлы кешеләрне сәхнәгә, гомумән, якын җибәрмәскә мөмкиннәр...

## БЕЗ КЕМНӘН КИМ, АРКА ЧОКЫР, КҮКРӘК КИҢ!

Октябрь революциясеннән соң, байтак халыкларга «союздаш» статусы бирелеп, татарны моннан мәхрүм калдыруны голәмәләребез гаделсезлек дип саный, ә андый статуска тиенгән очракта «союздаш халыклар» гына түгел, урыс үзе дә хезмәт сөючән, аек акыллы, тәһарәтле татар фонында әллә ни бөек күренмәскә мөмкин икәнен абайлыйсылары килми. Минемчә, царизм үткәргән геноцидны рухи алыплыгын җуймый кичкән халкыбызның өтек статуска бөкләп тыгылуы, мең ел кулланган язуын үзгәртергә мәҗбүр ителүе, һ.б. шундый ишеләр, һәр җәһәттә тигезлек урнаштыруны максат иткән коммунистик хакимиятнең моңа ярашлы эзләнү-тәҗрибәләре иде. Әмма бернигә карамыйча, татарның Гәрәев, Акчуриннары Рәсәй армия-

сен «тотты», янә бер Акчуриныбызның уч төбендә Рәсәй президенты йөрәге тыпырчынды, Софья Гобәйдуллина, Рудольф Нуриев, Ирек Мөхәммәдов, Алсу, Чулпан Хамматова, Вил Мирзаянов, Марат Сафин, Алисә Галләмоваларыбызны дөнья таныды, ә Роальд Сәгъдиев дөнья лидеры АКШның җиһан белән бәйләнешендә арадашлык итә... Ягъни бүген дә кайберәүләрнең бездән өтек хәлдәге статусыбызны күпсенүе шушы хәлебездә дә күпләрдән түбән тормавыбызны дәлилли... Атаклы немец философы Ф.Ницше, талантларны күралмыйлар, ә даһилардан үч алалар, дип язган.

Хәтергә төшерик, Татарстан белән Рәсәй хөкүмәтләре дәрәҗәсендә Шартнамә төзелгәннән соң, әлеге Килешүнең мәгънәсен җуйдыру максатында Рәсәй хөкүмәте, урыс өлкәләре һәм башка республикалар белән дә охшаш документлар булдырды. Ә бу гамәл Рәсәйдә яшәп килгән республикаларның киләчәктә булу булмавы Татарстанның хәленә, «татар мәсьәләсе»нең илкүләм торышына бәйлелеген ачып салды. Әйтик, күрше кардәш халык «милләтчеләре»нең татарга каршы «көрәше» «җиңү» белән тәмамланган очракта, бу Рәсәйдә татар факторының көчсезләнүенә, һәм, ахыр чиктә, Татарстанның гына түгел, бүтән республикаларның, шул исәптән «җиңүче» халыкның республикасы бетүенә дә, кыскасы, Рәсәйдә милли мәсьәләнең «тулаем уңай» хәл ителүенә китерәчәк.

Әмма ни генә булмасын, татар халкы дәүләтле халык, аның шундыйлыгы кәгазьгә теркәлмәгән килеш тә бик күпләргә мәгълүм. Ельцинның сабан туебызга килеп чүлмәк ватуы, ә Путинның, башын катыкка тыгып, көмеш тәңкә эзләве, урыс лидерларының һәм шуларның йөзендә урыс халкының да моны күңел дәрәҗәсендә тануын дәлилли. Дөньяның мәртәбәле илләрендә дә Татарстанның мөстәкыйльлеген күңел дәрәҗәсендә тану сизелә. Президент Минтимер Шәрип улы Шәймиевны Америкага барамы ул, Франция яки Төркиягәме, бүтәнгәме, хакыйкый президент дип саныйлар, таныйлар һәм моны аңлаган кешегә аңларлык итеп, һәрьяклап сиздерәләр шикелле. Татарстанның мөстәкыйльлеге документларда тиешле дәрәҗәдә чагылыш тапмавы нинди дер вакытлы, узгынчы аңлашылмаучылык кына, сәгать сугар, формальлекләр хәл ителер, реаль, лаеклы статусыбыз рәсмиләшер кебек...

КЕМГӘ ЯЛГАН, МИҢА ЧЫН...

Чөнки халык ни тели, шул тормышка аша... СССРны сүктек — сүтелде, КПССны каргадык — таралды, Татарстанның ирешкән кадәр суверенитетыннан көлдек, анысын тартып алалар.

Халык хыяллары әкиятләрдә теркәлгән. Һәм алар чынга ашучан... Әйтик, батыр ил улының явыз патшаны җиңеп, тәхетен тартып алуы турындагысы. Ленин гади халык теләгәнне эшләде, Балда һәм Шомбайларга байларның, поп, муллаларның маңгаена чиертергә (шул чуттан әдәби-драматик әсәрләр аша да), арт сабакларын укытырга форсат туды. Сталин заманында яшәү тагын да күңеллеләнде, ягъни ул халык теләгенә тагын да киңрәк юллар ачты. Күршеңнең, хезмәттәшеңнең, көндәш коллегаңның башын ашыйсың килә икән, рәхим ит, әләк язасың һәм хыялың тормышка ашты дигән сүз... Ике әкияти батыр, Ленин һәм аның варисы Сталин китергән «җиңүләрнең» бәясе артык кыйбатка төшә башлагач, халык янә хыялларга бирелде, һәм алары да тормышка ашып, ил тәхетенә, нәкъ әкиятләрдәгечә Юләр Иваннар килә башлады. Берсе кукуруз белән мавыкты, икенчесе күкрәгенә тәти тагудан тәм тапты, өченчесе аракыга каршы поход чыкты, дүртенчесе аракыны коткарды һәм оркестрга дирижерлык итте... Патша, шәхес культы, партия диктатурасы үтләткәч, демократия теләгән идек, «мә, ашагыз» дип, табынга китереп куйдылар. Әмма әлеге иреккә гади хезмәт иясеннән, гаделлек турында хыялланучы интеллегенциядән битәр, һәртөрле бандитлар, жуликлар, «зәңгәрләр» һәм башка шуның ишеләр күбрәк зарыккан булып чыкты... Нәтиҗәдә, шәһәр фатирларына төрмә камераларына хас рәшәткәле тәрәзәләр, авыр тимер ишекләр эленде... Хәер, СССР чорында «Свадьба в Малиновке» фильмы героинясы авызыннан, димәк, «ирек вәгъдә итәләр, талаячаклар!» дигән кисәтү яңгыраган иде дә, колак читеннән уздырып җибәргәнбез... Янә искә төшерик, Ильф һәм Петровның «Алтын бозау» әсәре персонажы, вак жулик, каз карагы Паниковский: «Паниковский сезнең һәммәгезне сатып алачак, аннары сатып җибәрәчәк!» — диде. Бик кызык идея бит. СССРны, әлеге дәүләтчелекнең умыртка баганасы булган КПССны таратуга һичкем, ни ата, ни бала коммунистлар, ни гавам карышмады, кулга ваучер тотып, шаккатып тик тордык, ә әлеге идея күз алдыбызда тормышка ашты!

Әлбәттә, әкиятне чынга, хыялны тормышка ашыручылар да бушка эшләми икән, ил кат-кат алтын запаслары белән, җир асты һәм өсте хәзинәләре, хәтта ак каеннары белән түләде һәм түли. Актык исәптә өлкән буынның үлемтеккә дигән маясына да урын табылды... Җитәкче Шомбай токымы гына алдатмады, туннарын-бүрекләрен әйләндереп киделәр һәм кызыл тышлык зәңгәр эчлек белән урын алмашты...

...Кемнәрдер фәхишәлек, фәхешханәләр турында, кемдер аена миллион доллар хезмәт хакы, чит илләрдә типтерү, атау-утрауларда виллалар булдыру хакында хыяллангандыр. Нәкъ чуртан кушуы буенча, һәммәсе дә үтәлеп тора. Дөрес, берәүләрнең хыяллары тормышка ашсын өчен, бик күп башкаларга хезмәт хаксыз, электрсыз, жылысыз калырга, суган суы суырырга туры килә. Рәсәйдә халык санының елына миллион

кешегә кимүе дә әлеге хыялларның тормышка ашуы өчен түләү прейскурантына кертелгән дип уйларга кирәктер. Озын сүзнең кыскасы, ахрысы, дөньяда халыкларның уй-хыялларын өйрәнеп, шуларны тормышка ашыру бизнесын үзләштергән ниндидер транснациональ компания бар һәм чәчәк ата шикелле... Димәк, безнең азатлык турында хыялларыбызның да көтмәгәндә тормышка ашып куюы бик мөмкин. Шунысы гына шомландыра, 37 нче ел бездән ерак китмәде. Күрегезче, урыс патриотик гәзитләре Сталинны юксынган мәкаләләргә юл ача. Бүгенге өметсезлек шартларында моңа аптырыйсы юк. Әмма демократия битлеге астында хакимлеккә килеп, җитәкчелекне үзенә кулдаш итүгә ирешкән, илне һәм халыкны җәяүгә калдыручылар талыйсын талап бетергәч, киләсе талауга кадәр мая туплансын өчен, янә халыкны, ярыштырып, бушка эшләтергә сәләтле тоталитар режимга тиендерергә, ягъни янә бер тапкыр хыялларыбызны тормышка ашырырга мөмкиннәр...

## ҖИКТЕРЕП «ТУЛПАР», КЫРЫМГА!..

*(Сәяхәтнамә)*

Кырымны урысның күренеклеләре җәннәткә тиңләгән. Бу җәннәт белән Татарстан арасын «Тулпар» очу компаниясе ялгый икән. Мәгълүм әкияттә Балданың, күлегезне күккә асам, дип янавында дөреслек бар, ахры, тәрәзәдән күренгән иксез-чиксез кар таулары һәм сахралары булып күренүче җәйрап йөзгән каткат болытлар, асылда, вакытлыча күккә асылган елга-күлләр ләбаса.

Өч сәгать тә үтмәде, без, Казан пассажирлары, Украина составындагы Кырым Автономияле Республика башкаласы Симферопольгә аяк бастык. Кала — гадәти урыс өязе шәһәре булып яши, бирредә урысча гына сөйләшәләр һәм базарларында, гривна белән беррәттән, Рәсәй акчасы да әле әйләнештә.

### УРЫС ТАРИХНЫ ҮЗЕНЧӘ ЯЗА

Республикадагы мәктәпләр өчен тарих китабы да иҗат ителгән һәм ул «Наша Родина — Крым» дип ачылып китә. Ягъни монда яшәүче урысларның ватаны Рәсәй түгел, ә Кырым икән, ә республика — алар ия булган дәүләтчелек формасы... Бирредә бик күптөрле төп халыклар тарих дәвамында бер-берсен алмаштырган һәм әлеге алмашыну урыс чираты җитеп тукталган... Татарстан тарихы китабындагы сыман, фәнни төсмер бирү зарурлыгыннан, бу китап та Кырымда элек кыргый кешеләр гомер сөргәнлеге хәбәреннән башлана. Аннары безнең эрага кадәр фәләненче гасырда, кавемнәре нәмәгълүм кимерияләләр яшәгән, диелә. Әмма грек тарихчысы Геродот алар хакында «бия савып көн итүче, дөньядагы иң гадел кешеләр» дип язып калдырган. Ә бияләрне төркиләр, ягъни казакълар, башкортлар һәм Мөслим районының Татбүләр авылында савалар түгелме соң? Өстәвенә кимерияләләр патшаларын тәңречелек кануннары буенча — төркичә, курганнар корып җирләгәннәр. Әмма дәреслек авторлары өчен хакыйкать мөһим түгел, чөнки асыл максат — әлеге җиргә урысларның хуҗа булуларына кануни җирлек әзерләү. Кимерияләләрне (бәлкем камәр ияләрендер?) скифлар алмаштырган, боларын һинд-ауропалылар дип тәгаенли дәреслек авторлары. Әмма грекның борынгы тарихчысы бәянында скифлар үзләренең башлангычы дип «Апи» һәм «Папай»ны саный, өстәвенә «праздник плуга» уздыралар, ә патшаларына «Атей» дип дәшәләр...

...Атилла дәүләте таркалгач, күпмедере бирегә, ватанына кайткан һуннарның төркилеген дәреслек авторлары таный тануын, әмма аларны килмешәкләр һәм Кырымга зур зарар китерүчеләр дип тәгаенли. Кыскасы, дәреслек авторлары бирредә төрле чорларда яшәгән кимерия, скиф, һун халыкларының бер уртак төрки кавемнән булуын танырга теләми.

Греклар Кырымны Таврика, Таврида, җирле халыкны таврлар дип атаган. «Таврлар» диңгез буендагы тауларда яшәгән, һәм үзләрен төркичә «таулы» дип таныштырганнардыр да, әмма китап авторлары фикеренчә, «таурос» грекча үгез дигән сүз икән, һәм боларның атамалары кай яктандыр үгез белән бәйле булырга тиеш... Гректан соң Кырым, Рим, аннары Византия империясе составына эләгә — болары исә, тарихчы фикеренчә, начар түгел. Әмма монгол-татар явы нәтиҗәсендә Кырымның Алтын Урда составында калуын ул ошатмый һәм мактамый.

Әби патша чорында Кырымдагы татарча атамаларның күбесен бетереп, грекча исемнәрен «торгыза» башлыйлар. ...Акмәчет каласын «тарихчы» Симферопольнең «предшествиннигы», ягъни элгәре дип атый, һәм аны булган да, беткәнгә чыгарып, Симферополь каласына нигез 1874 елның 8 февралендә салына, дип тәгаенли. Бу җәһәттән караганда, безгә язмыш мәрхәмәтлерәк булган икән: Казанны 1552 елның 15 октябрендә нигезләнелә дип тарихка кертмәгәннәр бит.

## ДИҢГЕЗЛЕ ТАУ ИТӘГЕ

Җитмешенче елларда иң шәп юл-күперләрне Кырымда, ди торганнар иде. Бүген вазгыять бүтән, әлеге мәсьәләдә Кырым Татарстанга көндәш түгел бугай инде. Хуш, автобуска утырып, Фороска, Ялтага таба кузгалабыз. Форос — грек сүзе, ясак дигәнне аңлата, баскынчы греклар өчен ул кайчандыр ясак җыю ноктасы булган. Татар ханлыгы чорында аның исеме үзгәрмәгән. Урыслар килгәч, бу төбәккә светлейший князь Потемкин хуҗа булып тора. Аннан ул Кузнецов, анысыннан якташыбыз Ушков фамилияле (Алабуга каласыннан күчеп килә) эре сәнәгатьче кулына күчә. Өйләнүе аша соңгысы белән икенче якташыбыз — атаклы җырчы Шаляпин туганлаша һәм 1916 елны ул биредә М.Горький белән очраша. Пролетар язучы аның исеменнән истәлекләр язуга алына. М.Горький биредә утызынчы елларда да ял итә (иптәш Сталин кемне кая юлларга кирәген яхшы белгән).

Бүген Форос — өч мең чамасы кеше яши торган бистә. Анда элек партаппаратчылар ял иткән санаторий һәм балалар ял итүе өчен биналар комплексы урнашкан. Яңа гасырга кергәнче балалар лагере булган бер комплекс Рәсәй хөкүмәте тарафыннан арендага алынып, таш коймага төреп, үзгәртеп корылган. Шунда чагымда анда Касьянов һәм Черномырдин очраша дип сөйләделәр. Ул көн диңгездә сак корабы торды һәм төн уртасында искитмәле фейерверк күзәттек. (Заманасында Әби патша килгәч тә Кырым шәп фейерверк шаһиты булган.) Форосның көнчыгышында, әлеге резиденциядән бер ара киткәч, кайчандыр татарныкы булган Мухалатка авылы тирәсендә — Кучма әфәнде биләмәсе. Ә бистәбезнең көнбатыш юнәлешендә, диңгез ярында, элек Максим Горький, аннары космонавтлар хозурланган «Теселли» (грекчадан тынлык дип тәрҗемә ителә) атлы урындагы яшел түбәле дачалар Татарстан карамагында. Гидыбыз зур горурлык белән биредә Шәймиев Минтимер Шәриповичның да ял итүен хәбәр итте. Президентыбыз ял иткән комплекска терәлеп, тарихка СССРны таркату символы булып, Горбачев дачасы исеме астында кергән мәһабәт корылма кукраеп утыра. Бу урынны Раиса Максимовна ошатып сайлаган икән һәм 50 гектар биләмәле «дача» 1988 елны өлгертелгән булган. Кыскасы, М.С.Горбачевка атап, «ил утырганда галошка, сарай салган Фороста» дип такмак әйтергәме, инглизнең «кем яхшы замок салдыра, анда яшәмәс...» дигән җырын шыңшыргамы, белми аптырап торасың...

Бу төбәктә җирләр сатылып бетеп бара. Гидның әйтүенә ышансак, тиздән биредә балалар лагерьлары калмаячак. Тау битендәге урманнарны кыркыштырып, яңа хуҗалар, яңа колонистлар — киевләннәр өчен егерме сигез данә биек йортлар салыначак. Чөнки аларның да диңгездә дельфин сикереп уйнаганын күзәтәсе килә икән. Ә монда җирләшкән иске колонист урыслар (коммунистик хакимият чорында, кырым татарлар сөрелгәч, монда аларны Потемкин чоры «аборигеннарына» өстәү өчен вербовка тәртибендә чит өлкәләрдән партия-партия китереп, ссуда, тораклар биреп төпләндерәләр) «дикарьләргә» фатир, тору урыны тәкъдим итүне кәсеп иткән.

Бер-ике урында төзелеш бара. Прораблар әйтүенә караганда, биредә аена 200 долларга төзүче эшче табып булмый башлаган. Ерактан, бүтән калалардан китертергә туры килә, диләр. Фатирга кертеп, тир түкми генә ансат акча табарга бер күнеккәч, чын эшкә кул тартмый, күрәсең...

Форос искиткеч матур урында. Ул зәп-зәңгәр диңгезнең ташлы яры һәм таш кыялар тезмәсе арасындагы яшеллеккә чумган тау итәгенә киртләчләнеп кереп урнашкан. Биредә тау, урман һәм диңгез һавасы. Әлеге таш кыялар үзгәрешсез 18 миллион еллар торалар, имеш... Әгәр үзеңә сиздерми генә бирегә китереп ташланган булсаң, кайда, кайсы чорда, нинди планетада икәнеңне аңларлык түгел. Каршыңа динозаврлар килеп чыкса да, куркуын куркыр, әмма аптырамас идең. Тау-кыя очларына болытлар утырып, кайбере тиздән ата башлаячак тере вулканга охшап кала; борынгы Помпей фаҗигасе кабатланыр төсле. Җир тетри калса, тау итәгендә яшәүчене афәт көтә. Әмма ни генә булмасын, диңгезле тау итәгеннән һичкем китәргә теләми генә түгел, монда берегергә теләүчеләр арта гына бара... Шәп тормыш символы — яхталар, зур түрәләр яшәп яткан дачалар тирәсендә күзгә чалына...

## КИПАРИС ТА ГЕНОЦИД КОРБАНЫ

Форостагы паркта нинди генә агачлар, чәчәкләр, үсентеләр юк: Кытайдан да кайтартып утыртканнар. Төньяк Африкадан да, башка кыйтгалардан да, һәм иң гаҗәбе, бары бу төбәкне генә кипарисларны юк итү афәте урап узган. Бермәлне Кырымда Сталин әмере буенча кипарисларны юк итү компаниясе башланып, һәр җитәкче көн саен ничә кипарис юк ителүе хакында хисап биргән. Сталинның үлеме генә әлеге гүзәл агачка каршы геноцидны туктаткан. Без Кытай җитәкчеләренең чыпчыкларга каршы көрәшеннән көлгән булабыз, ә бит Мао бу җүләрлеккә, илдә ашау мәсьәләсе авыр чорда, икмәккә экономия ясап булмасмы бераз дип, аптыраганнан һәм изге нияттән чыгып бара. Ә биредә — бүтәнчә. 2003 елны Симферопольдә дөнья күргән «Форос, очерклар, истәлекләр һәм фотолар» дигән китапның 64 нче битендә Сталин гамәленә

шома гына бәя бирелгән. 1944 нче елны, Ялта конференциясендә очрашкач, Рузвельт Сталинга, Кырым зиратны хәтерләтә, бездә кипарисларны зиратка гына утырталар һәм табутларны да шул агачтан ясыйлар, ди, имеш. Мондый аңлатма, андый сөйләшү булмаган очракта, зеклар телендә «подстава» дип атала. Ә булган очракта — «акыллы әйтте, тиле йөгерде»гә килеп чыга һәм берсе дә «юлбашчы», «халыклар атасы» файдасына түгел. Ә аның ата исеме алуында плагиат ярылып ята, чөнки аннан алды бер Атей булуы хакында алдарак язган идек.

Кырым татарлар күңеленә урыс телле гәзит аша шундый, минем карашка, легенда бикләтелгән. Кем белә, бәлкем ул чындыр да. Имеш, 1943 елны Тәһрандагы очрашуда Рузвельт яһүдә хатыны тәэсирендә көн тәртибенә яһүдләргә дәүләт төзү мәсьәләсен керттерүгә ирешә. Өч вариант тикшерелә: Палестина, Уганда һәм Кырым. Сталин шушы максаттан Кырымны татарлардан тазартырга йөкләмә ала. Нәтиҗәдә, әлеге җинаятьчел килешү төзегән «цивилизацияле дөнья» җитәкчеләре Сталинның Кырым, һәм берочтан, форсаттан файдаланып, Кавказ мөселманнарына каршы үткәргән геноцидына бармак аша карарга мәҗбүр булалар. Сталин, үзенә кирәген эшләгәч, тегеләрне хәзерге тел белән әйткәндә, «кинул», ягъни төп башына утырта: Кырым урынына, мыскыл иткән сымак, Ерак Көнчыгышта Яһүд Автономияле Округы оештыра. Яһүдкә, Кырымга ия булу омтылышы өчен үпкәләп тә булмый, нәкъ шул максат җилкендергән итальян, грек, немец, урыс яки бүтәннән ул киммени?

Кырымда, кипарислардан тыш, XVI гасырдан бирле кулланып киленгән чирәп түбәләр дә законнан тыш дип игълан ителә. Әлеге «татарник»ны юк итүчеләргә бушлай шифер өләшенә. Хәзер Кырымда табигатенә ятышлы тузу-искерүне белмәүче кызыл чирәп түбәләр бик сирәк очрый. Ә иске, каралып черегән шифер түбә, кала-авылларны шөкәтсезли, урманлы таулар һәм бакчалы үзәннәрдән гыйбарәт гүзәл Кырым җиренең котын качыра. Биредә урыс авыллары нәкъ бездәге сыман «матур». Калалар да әллә кем түгел, һәм килгән халык биредә әллә ни мантыган димәс идем.

Бүген базарларда кырым татарлар да сәүдә итә. Форостагы базар сәүдәгәренең берсе югары категорияле теш технигы, икенчесе радио-релече инженер, өченчесе педагог... «Эш юк, урнаша алсаң — штат кыскара, һәм кыскартылганнарның татар булмаганнарына гына эш табыла», — ди яңа танышым, Үзбәкстаннан кайтып төпләнгән Рөстәм Аббазов. Биредә аларны радио-телевидение аша «депортированные», «татары», хәтта «наши татары» дип тә атыйлар, тик кырым татарлары дияргә генә телләре әйләнми... Кырым татарлары ничектер рәхәтләнеп, тәм табып сәүдә итсә, урыс сатучылары карашында аптырау һәм өметсезлек бар шикелле. Алар Кырымның Украинаныкы булуына бер дә риза түгел.

Кырым колхоз-совхозларында «төп халык» — урысларга пай җирләре бирелгән, ә күптән түгел каяндыр пәйда булган татарларга — шымытыр. Җирне арендага бирү дә «абориген» хуҗалар ихтыярында. Татар аренда хакы түләп үстергән җимешне базарда сатып яши. Әле шул шартларда үстергән бакчаларын дә өлкән туган вәкилләре «чистарткалап» тора икән...

## БАЛЫКСЫЗ БАЛАКЛАВА

Ак теплоходта Балаклава шәһәренә сәяхәт кылдык. Бу каланы борынгы Римнең яшьтәше, диделәр. Гомернең «Илиада» поэмасында телгә алына әлеге төбәк. Диңгездә давыл, поэма каһарманнары корабыбыз белән таш ярларга бәрелеп чәлпәрәмә киләбез дип торганда, кинәт кыялар арасында бер култык ачылып китеп, болар шул гаваньга кереп, исән калалар. Европа сәяхәтчесе биредә хәерчеләр дә ифрат тук булуын, шәһәрдә балык исе аңкуын, хәтта йоклаган йорт кошлары авызыннан ашалып бетмәгән балык чыгып торуын язып калдырган. Төрекләр әлеге төбәкне «Балык юве», ягъни балык өне дип тәгаенләгән, ә урыска болай әйтү кыен булган (гид шулай ди) һәм яңа хуҗалар кала исемен, Кукмараны Кукморга үзгәрткән шикелле, Балаклава дип төзәткән. Биредә СССРның атом-төш су асты көймәләре урнашкан булган, шул сәбәпле экологиягә зур зарар килеп, чупырдап торган балык өнендә балык корган. Бүген исә яшерен объектларны салкын сугыш музеена әйләндермәкчеләр. Хәер, Фороста да балык базары юк, ашханәдә Ерак Көнчыгыштан кайтартылганын тәкъдим итәләр. Алай да базарда берсе-берсе 200—300 сумлык кипкән җирле балыклар да очраштыргалады.

Телевидениедән күреп беләбез, диңгезле илләрнең яр буйларында кырыкмаса-кырык төрле балык, башка диңгез продуктлары сатыла. Истанбул яры буенда андый базарны үземә дә күрергә туры килгәне булды. Ни хикмәт, әүвәлге СССР биләмәсеннән бәрәкәт качкан, иксез-чиксез басулары була торып, икмәкне читтән ташый, ә диңгезләре буенда балык юк. Хәйдәр исемле танышымның үз начальнигы хакында: «Бу эт асрап карый, алган бер эте йә кача, йә үлә, аквариум белән мавыкты, балыклары яшәми, ә без түзәбез, ялагайланабыз, мактыйбыз үзен», — дип сукранганы искә төшә.

Кырымда халык үтә провослав, үтә дини төсле, күбесенең муенында тәре. Санаторий тирәсендәгеләр нүлгә калып баручы коену кәчтүменнән йөрсә йөри (арттан караганда киемнең барлыгы күп очракта шәй-

ләнми дә), аның каравы муеннарында тәре ялтырап тора. Ягъни болар өчен материя мөһим түгел, беренче планда — рух! Форос бистәсе каршындагы бер кыяга да чиркәү кунаклатканнар. Тау арасындагы юлларда да адым саен тәреле часовня. Кырым татарлары мең бәла белән җир алып салган «Ватан» һәм «Кайту» исемле кафелар янәшәсенә дә урнаштырганнар андыйларны. Хәтта юл читендә, юл билгесе шәкелендә дә тәре очратырга туры килде. Хәер, Татарстанда да кайбер район яки хуҗалык исемнәре тәре сыман конструкциягә беркетелгән. Ахры, олугларыбыз арасында Алексий-2 атакайның яшерен фанатлары да юк түгел...

## АНДА ЧАТЫРДАГ, БЕЗДӘ ЧАТЫР ТАУ

Кырым ханлыгының башкаласы Бакчасарай бүген Малмыж төслерәк бер урыс каласы булып калган. Дөрес, хан сарае урнашкан музей бар. Пушкин данлаган фонтанны да күрдек. Ак күлмәк, кара яка дигән сыман, ак мәрмәр фонтан янәшәсенә шагыйрьнең кап-кара бюстын утырткannar...

Яхшы пәлтәнең затлы мех якасын сүтеп алып, матур көймәләрен тупас каптырмаларга алмаштырып, сазга манып, элеп куйсаң, андый кием һичкемдә соклану уятмас. Хан заманы корылмалары белән охшаш хәл. Үтә очсызлы буяу белән буялган идән һәм диварлар. Соңгыларын Екатерина заманы солдаты ясаган тонык сурәтләр бизи... Юлдашым кырым татары Рөстәм Аббазов, элек биредә гидлар татарга каршы агу чәчәләр иде, хәзер алай түгел икән, диде. Мәчеттә реставрация бару сәбәпле, кереп булмады. Алай да манарадан азан яңгыравы күңелгә хуш килде. Музейдан чыккач, Рөстәм Аббазовның төзелеп бетеп килгән өенә киттек. Карасана, Бакчасарайның бер ягы кырым татарлары салган ике катлы коттеджлар бистәсеннән гыйбарәт икән ләбаса хәзер! Йортлар арасында өр-яңа мәчет тә матур булып калкып күренә. Ирексездән безнең як кияве Әхмәт Гаделнең шигъри юллары искә төшә:

Урыс җиренә чиркәү килешә,
Мөселманныкына — мәчет.
Урыс җирен чиркәү калкыта,
Татарныкын утыра яньчеп...

«Без бу җирләрне митинглар ясап, көрәшеп алдык», — ди Рөстәм. Җирле хакимият әлеге «басып алу»га каршы ОМОНнар һәм бульдозерлар ярдәмендә көрәшкән. Әмма кырым татарлар кислород боллоннары, бензинлы канистралар белән коралланган, «башта мине тапта» дип, трактор көрәге астына керә башлаган. Хакимиятнекеләр дә төшеп калган кешеләр булмаган, кызылармияче тапкырлыгы күрсәткәннәр: төзелеш мәйданының ике ягыннан берни булмагандай, ике авыр машина килә, ә уртадагы юан, корыч аркан күренми, һәм ул юлына туры килгән һәрнәрсәне искәрмәстән җимереп уза. Әмма мондый алымнар да кардәшләребезнең рухын сындыра алмаган. Бүген Бакчасарайның бу ягы — татарныкы. Арада беркатлы тәбәнәк коттеджлар бар, алары Литва ярдәме белән салынган. Мостафа Җәмилев йорты янында шундый бер йортка медпункт урнашкан.

Кырым татарлар быел июль аенда (2003) җир дәгъвасы белән митингка чыккан булганнар һәм таләпләре үтәлгән сыман да тоелган: җирле телевидение алып баручысы, зур канәгатьсезлек белән, Милли Мәҗлес хакимиятне якадан алырга тәмам остарды, җир башкаларга да кирәк, ә татарлар таләбе генә үтәлә, дип сукранды. (Әмма ел азагында Кырымда элеккеге СССРдан башка чыккан кайбер илләр катнашкан форумнан соң, Рәсәй телевидениесеннән кырым татарларга диңгез буендагы җирләр тәтемәячәк дип «сөендерделәр».)

Телевидение янә татарларның үзләре салган өйләрендә балалар бакчасы ачуын күрсәтте һәм бер-ике кырым татар җырчысын тыңлау-күрү бәхетенә ирештерде. «Фанерачы» шабашчыларны түгел, чын, классик җырчыларны! Шуны аңладым, биредәге кардәшләребез эшчән, матур һәм батыр кешеләр, алар бердәм булып, яшим дип яшиләр һәм бетәргә бер дә җыенмыйлар.

Чечняда — чеченнар, Башкортстанда — татарлар, биредә — кырым татарлар яшәү, исән калу өчен җан тартыша. Безләргә каршы явызлыкның чишмә башы кайда соң? Кырымда бу сорауга да җавап таба алдым шикелле. «Голос Крыма» гәзитенең (2003 ел) 20 июнь санында тарих фәннәре докторы, Санкт-Петербургның Меньшиков исемендәге институт директоры Валерий Возгринның «Кырымны аннексияләү һәм урыс расизмы» дигән мәкаләсе басылган. Изге Русьнең беренче кенәзе Владимир булып, шул ук шәхес урыс изгесе буларак канунлаштырылган. Мәкалә авторы Владимир кенәз биографиясендәге кайбер моментларга тукталa. «Святой» кенәз, күрше Полоцк кенәзлегенә басып кереп, шундагы кенәз кызы Рогнеданы әтисе, туганнары күз алдында көчли. (Көчләүчесен үтерергә омтылганы өчен, соңрак шул кызны хөкемгә тарттырып үтертә.) Мондый «батырлыкны» беренче Рәсәй христиан патшасы Иван Грозный да кабатлаган. Тагын бер рухи ориентир: Петр Беренченең асылда кемлеге һәм ниндилеге хакында «Звезда Поволжья» гәзитенең (2003) 30 санында атаклы совет кинорежиссеры Юрий Ильенко Лев Толстой бәянында искәртә. Әлеге мантыйк буенча китсәк, Юрий Буданов та урыс изгеләре сукмагында. Фән докторы Валерий Возгрин фикерен-

чә, мондый изгеләштерүләрнең төбендә элек тә, хәзер дә яшь буыннан җәзасыз калуга инанган көчләүчеүтерүчеләр әзерләү зарурлыгы ята. Ягъни хикмәт урысларга хас ниндидер абстракт явызлыкта түгел, ә аларга гасырлар дәвамында тагыла килгән куркыныч рухи ориентирларда, ахры...

Өч атна үтте дә китте. Урыслар оҗмах җирләре дип сокланган кардәшләребез ватаны Кырымны калдырып, шул ук урыслар «подрайские», ягъни җәннәт тирәсе дип тәгаенләгән үз ватаным Татарстанга кайтып киттем. Йа Хода! Безнең яклар да бик матур икән! Аерма тик шунда: тегендә матурлык кыргый, ә бездә кулга ияләшкәнрәк... Бездә дә бит Идел һәм Кама кушылган урыннар — диңгез сыман. Ярындагы Болгар каласы калдыкларын күргәч, бабайларны янә сокланып искә аласың. Сайлый белгәннәр урынны: хет Рим, хет Истанбул төзе, вәт ичмасам зәвык! Шундагы хәрабәләрдән чыгып, кайчандыр нинди кала җемелдәп торганын чамалавы да кыен түгел. Һәм хыялда торгызылган кала — реаль, ә аның янындагы бистәнең чынбарлыктагы черек шифер түбәле, диварлары түл белән тышланган өйләре, күкрәп тигәнәкләр үскән урамнары сюрреаль, ниндидер начар әкияттән сихер ярдәмендә барлыкка китерелгән төсле. Сихер кайтыр, һәм Идел ярында кабат гүзәлләрдән гүзәл шәһри Болгар нур чәчеп торыр төсле. Иншалла, ул шулай булыр да әле. Ник дигәндә, күрегез, Казан ничек үзгәрә! Кол Шәриф мәчете калабызны ничек күтәрде! Аллага шөкер, үзебез сайлап куйган президентыбыз үз татарыбыз. Премьер-министр — якташ, Саба төбәгендә туыпүскән егет, әле кайчан гына бездәге «Сельхозтехника» берләшмәсендә инженер-диагнозчы вазифасын башкара иде. Чыңгызхан исеме белән эшкуарлык итеп, бизнес өлкәсендә зур уңышлар казанучы егет тә безнең якныкы. Ә Кырымда бу шанлы исемне Татарстандагы кебек зурлау, югары күтәрү — киләчәк эше. Элек татарның бәкләре яхшы атларда җилдергән, дөньяның иң шәп җайдаклары алар булган, бүгенге солтанат егетләребез дә машинада җилеп, Европада җиңү яулый!

Таулар, диңгез, төрек әйтмешли, чок гүзәл. Ә Татарстанда иксез-чиксез сихри болыннар бар. Идел, Кама, Ык, Мишә буе болыннары... Тау чишмәләре — үзенчәлекле, әмма безнеке — сандугачлы бит. Ә иң мөһиме — кешеләребез матур, тырыш, күркәм. Чын эш, чын хезмәт кешеләре һәм иманлы булгангадыр, аларның йөзендә самими яктылык бар. Кыскасы, халкыбызның искиткеч катлаулы, Мәскәү адым саен «күлегезне күккә асам» дип өркетеп, кисәтеп торган шартларда, рухын хезмәт белән савыктырып, җир җимертеп яшәп яткан көне...

# ЮМОРИСТИК ПАРЧАЛАР

## ТАЗАРГАН

Сыйныфташым Фәритнең, армиядән абыйсы салган фотосурәткә ымлап: «Апый тазарган, бүреге баш очында гына тора», — дигәне истә калган.

## БӘХӘС

Байлар Сабасы интеллектуальләре бәхәс куерта, ә сүз музыка хакында. Нинди эшкә тотынса да булдыра, һәм инде югарырак күтәрделәр диган көннәрдә «ычкынып» китә торган ике югары белем дипломына ия Рәшит абый Ибраһимовның исән чагы. Ул инде, татарның иң бөек композиторы — Сәйдәш, ди. Әмма райкомда эшләүче Гариф абый килешми:

— Сабага килгәч Нәтән Рәхлин әйтте, татарның чын бөек композиторы Нәҗип Җиһанов, әле аны халык аңлап җиткерми, әмма тора-бара аңлаячак, диде, — ди.

Рәшит абыйны әлеге раслау чыгырыннан чыгара, ул Җиһанов турында ишеткән-белгән тискәре мәгълүматларны эшкә җигә, хатыны марҗа икән, Солтан Габәши, Латыйф Хәмиди, Фәрит Яруллиннарның язмышында уйнаган роле дә, ул сөйләгәннәрнең аз гынасы дөрес булса да, һич күркәм дип булмый. Ләкин Гариф агай нык кеше, таш кыядай тора һәм карыш та чигенми, һаман Натан Рахлиннан этенеп, үз дигәнен алга сөрүен белә. Рәшит агай Сәйдәшне түбәнрәк баскычка куюны күтәрә алмый, ярсый башлый һәм райкомга карата күңелен тутырган моң-зар, үпкәләргә дә чират җитә.

— Кем соң син? — ди ул, оппонентын ашардай булып. — Син бит райком бәндәсе, А хәрефе белән Б хәрефе арасында бүтән хәреф юк дип утыручы! Һәм тагын ниләрдер әйтә дә, Сәйдәшнең беренчелеген танымаучыларга үпкәләп, дулап, бәхәс мәйданын калдырып, рәнҗеп китеп бара...

## АЛАЙ ТҮГЕЛ УЛ...

Малай чак, кичке уеннан соң кемнең кем белән, ничек кавышуын күзәтеп, егет булырга өйрәнеп йөргән заман. Авылыбызның «кунак кыз директоры» Фәрхәд абый бер «тутый кош»ны карт тал ышыгында кочкан, ә тегесе разый түгел.

— Торасың да күкрәккә үреләсең, нәрсәсен табасыңдыр, ит бит инде ул, — дип үпкәли.

— Алай түгел ул, Фирдания, — ди Фәрхәд абый, авыр сулап.

## BLƏDIƏ

Истанбул каласын гизгәндә, шуңа игътибар иттем: паркларда утыргыч-диваннарның барысына да юәһәr blədiəse дип язганнар. Сорашып белдем, бләдия дигәннәре администрация дигәнне аңлата, ягъни утыргычлар шәһәр администрациясе милке икән. Аһ, мин әйтәм, төреккә әрәм, безгә туры килә ич бу атама...

## ИСЕМНӘРЕҢ КЕМ КУЙГАН...

Эшкуар абыем Радик белән икәү Истанбулга килдек. Йомыш төшеп, төрекләр белән танышабыз.

— Рөстәм.

— Рөстәм бәй, — дип, кулым кысып, үз исемнәрен атый яңа танышлар.

Ә абыйныкы яңгырагач, уңайсыз тынлык урнашты. Берәрсе үзен: «Тузик», — дип тәкъдим итсә, бездә дә, мөгаен, шундый киеренкелек туар иде. Әңгәмәдәшләребез, аптыраштa калып, бер-беренә караштылар, аннары, ялгыш ишеттек, ахры, дип булса кирәк, абыйдан кабат исемен әйтүен үтенделәр.

— Радыйк, — диде, килеп туган мәсьәләнең асылына тиз төшенгән абый.

Садыйкка охшатып әйтеп, авыр хәлдән чыкмак булды ул. Әмма хәйлә барып чыкмады, итагатьле яңа дусларыбыз үзара киңәшеп алганнан соң:

— Ярар, без сиңа Зариф бәй дип эндәшербез, — дип елмаештылар.

Безнең колакка ятышлы Рафинат, Роберт, Рубис, Флүр, Флүс, Регина, Кристина кебек кайсы мутант, ә кайсы христианга баглы «татар» исемнәренең кем өчендер сәер яңгыравы да ихтимал икән...

## САЛАМ БӘХЕТЕ

Безнең колхоз ирләре жирәбә салып салам бүлешкәндә, Хәертдин агайга мулрак өлеш чыккан. Бригадирның:

— Бәхет бар икән үзеңдә! — дип, тел шартлатуына каршы агаебыз, моңсу көрсенеп:

— Әй энем, салам бәхете генә бит ул! — дип куйган.

Бүген авыл кешесенә салам бәхете дә гел тәтеми, җитәкчелек, җир сөреп тир түккәнгә хисапланган тишек тиеннәрне дә салам исәбенә тотып кала, ә саламның колхозчыдан арткан мул өлеше һәр язны яндырыла...

## ВАҺҺАБИТ

Милиция бүлегендә участковый Нариман агай бер укучы малайдан сорау ала. Гаепле баланың әтисе дә шунда, бөкшәеп ишек катында басып тора.

— Нишләп ут төрттең эскерткә?

— Абый, вимве?

Малайның әтисе карлыккан тавыш белән ачыклык кертә:

— Минме дигәнне шулай әйтә ул...

— Син, әнәңне эт җыккыры малай, билгеле, син, менә бит кесәңнән шырпы чыкты! Бәхетең, безнең як басуларда, җир астында газ торбалары юк, югыйсә террорчы-ваһһабит дип, аягыңны җиргә дә тиермәсләр иде...

## ТАКТИКА

Миңзифа апа үз тиңен кырыкка җиткәндә генә тапты. Ул утызның ар ягына чыгып барган Җәгъфәр исемле егет белән икесе хакында «йөриләр икән» дигән сүз таралуын бик теләде. Әмма авыл халкының болар мәхәббәтенә әллә ни исе китмәде. Беркөн Миңзифа апа, кәнсәләргә керешли, шул тирәдә бер көтү гавам өелеп торган мәлдә, урамның икенче ягыннан чабып баручы кечкенә малай Рәискә кычкыра:

— Рәис!

— Нәрсә, Пипа апа?

— Син Мәүли кызы Наилә белән йөрисеңме әле?

Алты яшьлек Рәис мондый үртәүне гафу итә алмый һәм урамны яңгыратып:

— Үдең соң, үдең соң, Җәбехәр, Җәбехәр, — дип такмакларга керешә.

## АЙ-ҺАЙ, ХАҖИ...

Хаҗиәхмәт агай — аучы. Дусты Нигъмәтулла абзый белән алар һәр кышны бер булса да, ак халатлар киеп, киң чаңгы тагып, мылтык асып, басу әйләнеп кайтучан. Кышның матур бер көнендә болар ауга җыеналар, әмма Хаҗиәхмәт агайның эте Алабайны ияртмәскә булалар. Чөнки файдасыннан зыяны күп, әллә нигә бер очраган киекне барыбер тотмый, ә өркетә генә. Болар Алабайны абзарга кертеп, ишегенә лом терәтәләр һәм ауга китәләр. Йөриләр-йөриләр, әмма ни куян, ни төлке очрамый. Арып-талып кайтырга чыксалар, күрәләр, өсләренә ыжгырып бүре килә! Нигъмәтулла агай мылтыгын корырга онытkan була, кабаланып, хатасын төзәтергә маташканда, патроннарын карга чәчеп җибәрә. Әле ярый Хаҗиәхмәт агай югалып калмый, мылтыгы да корулы икән, бер аякка тезләнә төшеп ата бу, һәм теге мәлгунь тәкмәрләп барып та төшә. Искә-аңга килгәч, аучылар табышлары янына ашыга, барып карасалар, ни күрсеннәр, Алабай җан биреп ята. Күрәсең, кайсыдыр абзарга кергән дә Алабайны азат иткән һәм тугры җан иясе хуҗасы янына ашыккан. Хаҗиәхмәт агай елап җибәргән. Ә Нигъмәтулла абзый, дустын юатырга теләпме:

— Ай-һай, Хаҗи, бүре түгел микән, койрыгы бик озын, — дигән, имеш...

## МИКИ

Кибеттә кеше шактый, ә сатучы хатын, бу күптән тора инде дип, юеш борынлы малайга хезмәт күрсәтә:

— Кем малае син?

— Мики.

— Нәрсә ул кулыңда?

— Кики.

— Нәрсә кирәк соң сиңа?

— Шики.

Мин, бу авылныкы булмагач, төшенмим, ә авылдашлары моны тиз аңладылар. Баксаң, ул Микаил атлы кешенең улы булып, бер дистә йомырка алып килгән, шикәр алырга икән исәбе.

...Әлеге авылда да хезмәт хакы түләү онытылган, малайның әтисе эчә, әнисе дә кырыйга куймый, кыскасы, авыл халкын «микиләштерү» бирелдә дә зур уңыш белән бара икән...

## ТАШ

Минем апам артыннан бер сабантуй батыры чапты. Ә бер тапкыр ул, апама үпкәләп, төнлә ишегалдыбызга әкәмәт зур таш кертеп куйган. Минем үсмер чак, дуслар белән күтәреп карыйбыз, була торган түгел. Иртән-иртүк безгә Миңзифа апа кергән иде, әни, бик гарьләнеп:

— Мортаза безне мыскыл итеп ишегалдына таш кертеп куйган, — дип зарланды.

Безнең өй кәнсәләр каршында гына, анда бик еш ир-ат өелеп торучан, Миңзифа апа шунда ашыкты һәм Мортазаны табып алып:

— Ай-һай, энем Мортаза! Ничек күтәрдең син ул ташны? Ул ташны күтәргәндә фәләнең җиргә тигәндер... — дип башын чайкаштырды.

Ир-атлар күтәрелеп бер көлделәр, ә Мортаза тизрәк таю ягын карады.

Икенче көн иртән торуыбызга ихатабызда теге таш юк иде инде...

## НИ СӘБӘПЛЕМЕ, НИЧЕКМЕ?

Прокурорларның хәле элек тә авыр иде. Әйтик, әрмән шабашчылары белән уртак тел тапкан колхоз рәисләренә буй җитми, хезмәт алдынгыларына дип кайткан аз санлы җиңел машиналарны җылы як бригадирларына сатып файда тапкан башкарма комитет рәисе белән дә шаярып булмый. Ә нәрсә дә булса эшләргә кирәк һәм аны район җитәкчеләре табып та бирә! Әйтик, фәлән колхозда «дуңгыз малайлары» кырылган: тап гаеплене һәм чара күр. Тикшерә башлагач, колхоз рәисе: «Мин бөтенесенә дә каян җитешим, белгечләрдән сорагыз», — дип кыяклый, белгечләр югары белемле. «Без фәлән-фәлән чаралар күрдек, менә журналга язылган», — дип, җаваплылыктан тайпыла һәм, ахыр чиктә, гаепле булып, тездән саз ерып, ярым бушка эшләүче авыл апалары торып кала һәм зыянны шулардан эзлисе... Безнең колхозда бер елны бозаулар кырылды һәм гаепле булып бозау караучы өч апа калды. Икесенә түләү ясагач, чират Миңзифа апага җиткән.

— Йә, апа, ничек үлде бозаулар? — дип сорый икән прокурор.

— Ничек дип, энем, башларын Сатыш авылы ягына каратып тагаракка салдылар да үлделәр инде, — дигән бу.

Прокурор шиккә калган.

— Бу апа бик тулы түгел мәллә? — дип, зоотехниктан сораган.

— Акыллы кеше колхозда эшләми инде, — дигән зоотехник.

Прокурор Миңзифа апага түләү салмаган. Миңзифа апа көлә:

— Ул бит ни сәбәпле үлде дими, ничек дип сорый, — ди.

Ул бәхетле, чөнки бу юлы аны дәүләт дурак калдыра алмады!

## ҖЫР ИСЕ

Гали ага Ильясовның нәсел ыруы безнең авылга тоташканга күрә, ул Юлбат авылына эзен суытмады. Безгә Казаннан кайту бик җайлы, олы юлда төшеп калгач, таудан түбән ике генә чакрым тәпилисе. Бер кайтуында ул малай чагы дусты, «Искра» колхозының ат караучысы Зариф абыйга юлыккан. Зариф агай, ат җене кагылган шәхес, машинага исе китми, җиде чакрым ераклыктагы район үзәгенә дә ат җигеп чыгып китә торган иде.

Кыскасы, Зариф агай моңа клевер түшәп, өстенә брезент җәелгән арбага утырырга тәкъдим иткән. Атта бару Гали агага охшаган, күрәсең, ул юл буе җырлаган. Әмма моның бер җыры Зариф абый күңеленә хуш килмәгән.

— Тукта, энем, менә монысын берүк җырлама, монысыннан каз тизәге исе килә, — дигән ат караучы абый.

Язмыш җилләре шул агайны күңеле тартмаган калага китеп яшәргә дучар итте. Кызык, ул заманча, клоун җырлар турында нинди фикердә икән? Хәер, аңа каз тизәге исе хәзер тансык тадыр әле...

## ДӨРЕС ҖАВАП КОТКАРЫР

Хәзер бизнесмен дип саналучыларны элек спекулянт дип атыйлар иде. ОБХССта эшләүче дустым Риф агай әйтүенә караганда, мондый җинаятьне фаш итү югары бәяләнгән. Бермәлне ул шундый гамәлнең эзенә төшә. Зур җитәкченең бер туганы Актаныш районындагы колхоздан сыер сатып алып кайта да Мөслим районындагы хуҗалыкка тапшыра. Арзангарakка ала, кыйбатка сата. Моны җавапка тарту өчен, Риф агайга сыерны керем алу өчен сатып алынуын исбатларга кирәк, шунсыз җинаять составы булмый. Риф абый кулына касса документлары, теге агайның кайчан кая чыгып киткәнен һәм кайтып кергәнен раслаучы шаһитләр дә бар. Ә теге гаебен танымый:

— Сыерны үзем өчен алдым! — ди.

— Үзең өчен алгач, ник соң син аны абзарыңа да кертеп тормыйча, «Октябрь» колхозына алып киттең? — дип кыса милиция хезмәткәре.

— Юлда кайтканда сөзде ул мине, шуңа гайрәтем чикте дә илтеп саттым!

— Кыйбаткарак саттым диген.

— Бәяне алар шулай куйды, арзангарак куйсалар да, сата идем, — ди теге, күзен дә йоммыйча.

Әгәр сыердан сорау алып булса, ул, бәлкем, «сөзмәдем» дияр иде дә... Нәтиҗәдә, гафу үтенеп кайтарып җибәрергә туры килә Риф агайга әлеге бизнесменны.

## ФӘЛИХ

Өмә белән эшләү күңелле. Минем студент чак, чиста су кертеп, юынтыгын чыгарып түгеп торам, әни һәм аның авылдаш дус хатыннары өй юа. Түшәмне, бүрәнәләрне, бүлмә такталарын шатыр-шотыр ышкый-ышкый юа болар. Үзара төрле шаян сүзләр әйтешеп, көлешеп-эләгешеп тә алалар. Шау-гөр килеп эшләп ятканда, ишегалдыбызга, акырып елап, бер кыз бала килеп керә. Әниемнең дусты Миңниса апа кызы янына ашыга.

— Нәрсә булды, ник елыйсың? — дип, кызын тыкырдата.

Тегесе:

— Фәлих, — ди дә тончыга. Тагын: — Фәлих!.. — ди һәм тагын тончыга.

— Әйдә читкәрәк барыйк әле, нишләтте Фәлих? — ди, коты алынган Миңниса апа.

...Ә эш болай булган. Ләйсән урамның бер, Фәлих икенче ягыннан килә икән. Шуннан Фәлих, кыз белән тигезләшкәч, һич көтмәгәндә, тиз генә чалбарын төшергән һәм кире күтәргән. Ләйсән, балакай, шуңа гарьләнеп елый икән. Кыйссаның асылына төшенгәч, Миңниса апа тынычланды, янә күзләре очкынланды.

— Нигә юкка үкерәсең, дөрес күрсәткән ул, — диде. — Менә Рөстәм абыең студент билеты чыгарып күрсәтә. Атаң комбайнчы, тракторчы, монтер праваларын күрсәтә. Ә Фәлихнең бүтән күрсәтердәй әйберсе булмагач, ул шуны күрсәтә. Бар, өйгә кайт, атаңа ашарга әзерлә, юкка аптырап йөрмә, — дип, итагатьле кызын озатып җибәрде...

## САИЛЧЕ КИЛЕН КӘСАФӘТЕ

Бер бай егете бик матур бер саилче кызга өйләнгән. Матур киемнәр дә кигәч, яшь килен башта күз явын алырлык булып күренгән. Әмма тора-бара бу көннән-көн сула, бетеренә башлаган. Бик күп табибларга, им-томчыларга йөрүләр уңай нәтиҗә бирмәгән. Аптырагач, яшь ир:

— Сиңа ни җитми? — дип сораган.

— Әйтсәм ышанмассың, әмма минем сиңа килгәннән бирле тамагым туймый, — дигән кәләш.

— Алайса, юлыңа ак җәймә, — дигән моңа ире һәм өеннән куып чыгарган.

Хатын, елап, капкадан чыгып барганда, урам як бакчасына караган тәрәзә ачыла. Ире моңа бер түтәрәм кара икмәк суза икән. Хатын йөгереп килә дә әлеге ипигә тешләрен батыра һәм «ә» дигәнче ашап та бетерә. Һәм моның йөзенә янә алсулык иңә. Ә берничә көн шул рәвешле туклангач, бу әүвәлгедән дә матураеп китә...

...СССР таралгач барлыкка килгән кайбер мөстәкыйль илләр кабат Мәскәүгә елышалар. Күрәсең, аларга да әлеге кәсафәт хас...

## КОММУНИСТЛАРГА УҢ КУЛЫМ

Миңниса апа сөйли, имеш, Ленин бабай үлем түшәгендә ятканда моның янына гавам җыелган, бар да елый, кайгыра.

— И Лилин бабай, син китәсең инде, син үлгәч нәрсә булыр? — дип сорыйлар икән.

— Коммунистларга уң кулым, комсомолларга сул кулым, — дигән Ленин бабай.

— Ә пионерларга? — дип кызыксынган бер малай.

— Пионерларга — китабым, — дигән даһи юлбашчы.

— Ә беднең ише эшче-крәстиянгә нәмә булыр соң? — дип кызыксынган бер Минзәлә ягы кешесе.

Юлбашчы:

— Кхххх, — дип нәрсәдер әйтергә теләгән, әмма әйтә алмыйча шул мәлдә өзелгән.

Миңниса апа, күзләрен кыса төшеп:

— Ни әйтергә теләгән икәнен шушы көнгәчә беркем белми икән, — дип, сүзен очлый.

Миңа калса, аның ни әйтергә азапланганын үзгәртеп кору заманы җиткәч бик шәп аңладык...

## НИШЛӘП АЛАЙ СУН УЛ?..

Һәр якның үз сөйләме. Әйтик, Шәмәрдән бистәсендә берәр гүзәл ханым:

— Нишләп алай сун ул? — ди икән, моны «нишләп алай соң ул?» дип аңларга кирәк.

Яшь чакта бер табында утырганда яныма туры килгән мишәр кызы:

— Кая, йөрәк маем, авызыңны себерим әле, — дип, ирен читләремне тастымал белән сөрткәләгән иде.

Безнең Саба төбәгендә муенга аса торган догалыкны, бөти, диләр, ә институттан соң эшләргә туры килгән Мөслим якларында бу сүзнең мәгънәсе гел бүтән.

Бер көн Казанның Бауман урамыннан барам, каршыма берәү колач җәеп килә. Баксаң, Мөслим кешесе, күптәнге танышым.

— Сәлам, туган, нәмәшләп йөрәйсең? — ди бу.

— БТИҮгә барыш, — мин әйтәм.

— Парин, мин монда беркемне белмим, син әйткән әйбер миңа да кирәк ие, иярим булмаса, — ди бу.

— Рәхим ит, — дим. — Тик сиңа бәлкем БТК кирәктер?

— Менә, менә, — дип җөпли танышым.

— Ярый алайса, — дип килешәм моның белән. — Тик башта «Аксакаллар Шурасына» гына кагылып чыксак, каршы килмәссеңме?

— Бик рәхәтләнеп. Түлке, ниме соң? Бик карт түгелме?

— Кем?

— Шура дидең түгелме соң? Шура дигәч, теге тешсез җырчы кыз күз алдына килә.

— Нинди Шура?

— Бәй, аксакалларга хезмәт күрсәтә дидең ләбаса.

Мин дустымның хатасын аңлап алам һәм тырышып елмаеп:

— Агайне, син дөрес аңламагансың. «Аксакаллар Шурасы» — ул иҗтимагый оешма, — дим. — Шура — совет, киңәш дигән сүз, — дим.

— Ә нәмәшләп кеше башы бутайлар соң? Аксакаллар киңәше дисәң ярамаймы? Стоп. Ә бетиү дигәнең дә иҗтимагый оешма түгелдер бит?!

— БТИҮ — бөтендөнья татар иҗтимагый үзәге, — дим мин, гаепле елмаеп.

— Ә бетеке? — дип ысылдый танышым.

— БТК — Бөтендөнья татар конгрессы.

— Харап икән. Бигрәк данлы юл узган икән милли хәрәкәт: БТИҮдән БТКкә. Парин, безнең юллар шушында аерыла. Бигрәк юк эш белән йөрисең икән, сау бул!

Һәм танышым минем яннан ашыгып китеп барды. Ә мин торам урам чатында аптырап. Кая бара идем соң әле? Шура... Шура... Беләм мин андый исемле туташны...

## НУРОЛКА

Салиха апа гомер бакый азык-төлек кибете мөдире булып эшләде. Тормышы төзек, йорт җире җитеш, фил гәүдәле бу ханымга йортка керүчеләр элек тә булгалады, тик берсе дә артык озак тоткарланмый иде. Ә менә Нурулла агай килгән җирендә таш булды. Тора-бара моның юка гәүдәсе, калыная төшеп, пинҗәгенең өченче төймәсен бүксәсе төртеп тора башлады. Ә бер кышны Салиха апа аны бер Бәкер курортына сәламәтлеген ныгытырга озатты. Нурулла агай монда югалып калмаган, гәүдәсе Салихасыныкыннан кайтыш булмаган бер марҗа белән дуслашкан. Санаулы көннәр тиз уза, Нуруллага алданрак китәсе икән. Боларның Бөгелмә вокзалындагы хушлашуына безнең якның кемнәредер шаһит булган, гайбәтләре кайтып та иреште.

Имеш, Нурулла вагон ишегеннән китми, тегесе аста икән. Икесенең күзләрендә дә мөлдерәмә яшь.

Менә марҗа түти түзми:

— Нуролка! — дип кычкырып җибәрә.

Нурулла шундук аска сикерә һәм гашыйклар бер-берсенең кочагына ташланалар. Әмма икесенең дә бүксәләре алга чыгып тору сәбәпле, иң әүвәл бүксәләр чәкәшеп, болар бер-берсенә тотынырга өлгермичә егылып китәләр һәм карда яткан килеш ничек кирәк алай, кочаклашып-сөешәләр. Бераздан Нурулла янә вагонга күтәрелә. Әмма озак та үтми, арттан янә үзәк өзгеч аваз яңгырый:

— Нуролка!!!

...Нурулла агай кайту белән Салиха апага ни булганын сөйли дә.

— Рәхмәт, Салиха, син миңа әйбәт хатын булдың, әмма мин мәхәббәтемне таптым, мине тоткарлама, — дип, теге бәләкәй чемоданын эләктереп чыгып китә.

Кыш үтә, яз җитә. Һәм кояшлы матур бер көндә Салиха апалар турында, урамның икенче ягында бер йөк машинасы килеп туктый. Кабинадан җитез сикереп, бәләкәй чемодан тоткан Нурулла төшә... Ул җиргә тезләнә һәм, тезләрен шудыра-шудыра, урамны аркылы чыгып, таныш капкага юнәлә. Бәлкем Салиха апа да, Нурулласын юксынып, тәрәзәгә килгән булгандыр. Сөеклесенең хәленә ул битараф кала алмый, билгеле, ашыга-кабалана күлмәкчән генә урамга атылып чыга. Нурулла тезләнгән хәлендә аның итәгенә башын куя һәм:

— Гафу ит мине, Салиха, мин ялгышканмын, — ди.

Киң күңелле Салиха апа, әлбәттә, аны гафу итә...

# ДРАМАТУРГИЯ

## НИ МАМЫК, НИ КАУРЫЙ

ЛИРИК ТРАГИКОМЕДИЯ, ӨЧ ПӘРДӘДӘ.

Катнашалар:
Гали (Гали Галиич) — зур түрә.
Эт — Галинең икенче мине.
Фарис (Фарис Әхмәтович Йомаголов) — үсә торган кадр.
Фарис-2 — Фарисның «икенче мине» (гел үзгәрә).
Наилә — яшь һәм тулы тәнле кыз.
Зәйтүнә — нәфис гәүдәле кыз.
Камил — галим, 33 яшьтә.
Нәҗия — сәркатип кыз.
Надия — сәркатип кызның «икенче мин»е.
Әби.
Кунаклар, №1 гозерче һәм №2 гозерче.

### БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

*Беренче күренеш*

Яшелчә базасы. Рельслы юл, склад авызы һәм вагон чите күренеп тора. Вагон йөргән, техника эшләгән тавышлар ишетелә, эшкә бәйле плакатлар, күрсәткечләр, җирдә төрле яшелчәләр ауный. Фарис — эш киемнәрендә, агач әрҗәгә гәзит җәеп, ашарга әзерли.

Фарис. Бушатырга керешкәндә алтау идек, икегә калдык, дүрт егетебезнең хәле төкәнде, бер вагоннан артыкка дәрманнары җитми мескеннәрнең. Камил һич аруны белми, берсен бетермәдек, икенчесен юлларга торып чапты. Их, кайчан кавын-карбыз кайта башлар, бәрәңге белән суган бушатудан тәмам гарык *(кулларын караштыра)*, сетка капчыклар өзә, кисә бармакларны.

Камил керә.

Камил. Маневровый электровоз каядыр олаккан, карабрак торыгыз, вагон сезгә язылды, дүртенче складка куябыз, диделәр. Уһу, кишер. Табыныгызда кишер дә юк дип әйтеп карасын берәрсе. *(Ашарга утыра.)*

Фарис. Алайга китсә, күкәй дә бар безнең! *(Пешкән күкәйләр тезә.)* Суган, тоз, бәрәңге һәм эпи. Әх, авыр эштән соң гап-гади ризыклар да патша сые булып тоела, валлаһи, кәҗә маең чыкмыйча ашарга утырасы да түгел.

Камил. Күр теге хөрәсәннәрне *(бармагы белән төртеп күрсәтеп)*, безнең белән башладылар, ә һаман очына чыга алмыйлар.

Фарис. КИСИ егетләре. Төзүчеләрне үзең беләсең, иртә башлыйлар, соң тәмамлыйлар. Элек минем правый рукалар иде алар. *(Кул изәп аларга эндәшә.)* Сәлам, егетләр! Аларның вагон ишекләре складныкыннан ерак калган, ташырга җайсыз, минем дә шулай туры килеп, иза чиккән бар. Икенче вагонны бушатышырга алабызмы үзләрен?

Камил. Безнең темпка түзәрләрме соң?

Фарис. Соң, һәркем дә синең шикелле җен булмастыр.

Камил. Безнең шикелле дип сөйләш.

Фарис. Иртәгә дә көн бар, югыйсә нәрсә нәфселәнәсе булдык әле без?

Камил. Иртәгә минем көн буш түгел шул, туган көн, эштә билгеләп үтми ярамый. Бүген тырышасы иде. Акча кирәк, дус, акча...

Фарис. Карале, нәрсәгә сиңа шулкадәр акча?

Камил. Нәрсәгә миңа акча?

Фарис. Алимент түлисең бардыр.

Камил. Ядрәң сөткә китте.

Фарис. Хатының явыз, һаман акчага туймый.

Камил. Мин буйдак.

Фарис. Син трудоголик. Һәм акча яратучы. Шуңа армый-талмый кәкрәясең.

Камил. Сине уздыручылар юк әле монда.

Фарис. Ә кая барасың? Институт укытучылары тәмам котырды. Зачетына каералар, имтиханына умыралар, атланып имәләр инде мескен студентны!

Камил *(көлеп).* Риторик сорау туа: ә закон кая карый?

Фарис. Прокурор булам дип укучылар да түли ясакны, агай-эне. Ришвәтче остазга ришвәт бирә-бирә укы да аннары гаделлек сакларга алын, бичаралар... Юк, түлисен түләп, тизрәк укуны тәмамларга да, ничек тә рәхәт тормышка чыгасы иде...

Камил *(утырган бүкәненә ябылган капчыкны алып, Фариска суза).* Тот... Киңрәк тот шуны.

Фарис *(капчыкны тотып әйләндерә).* Аңламадым.

Камил. Капчыгыңны киңрәк тот. Менә боларны да учла инде алай булгач. *(Кишер белән күкәй суза.)*

Фарис *(көлеп).* Камил абый, куй әле шул тилегә чыгара торган гадәтеңне! Болай да биш минут саен дурак калдырып торалар: имтиханга керсәң — укытучы, техникага утырсаң — ГАИ хезмәткәре, тулай торакка кайтсаң — комендант.

Камил. Ә ник авылыңны калдырып килдең соң?

Фарис. Авыл халкын тилелектән, гомумән, чыгармыйлар...

Камил. Безнең илдә яшәү шарты шуңа кайтып кала шул, энекәш... Гомер бакый шулай бара.

Фарис. Ә мин гомер буе тилегә салынырга да, авыр эштә бөкремне чыгарып, гел-гел тиле калырга да җыенмыйм. Рәхәткә чыгу юллары күп ул, эзләнергә генә кирәк.

Камил. Крутой җинаятьче булырга мөмкин... Хәер, ришвәт — авыр җинаять, ә син таныдың, укытучыларны сатып аласың икән, димәк, шул юлга тәпи баскансың да инде.

Фарис. Ә кем бар тәпи басмаган, кем бар? Шунсыз судья, прокурор да булып булмый бүген. Нәрсә кыз булып кыланасың, әйт, кайда саф калып була?

Камил. Вагон бушатуга ничек карыйсың? Беләккә авыр, ә йөрәккә җиңел, рухың гарипләнми, исәп-хисапны да тиз өзәләр.

Фарис. Бу сезонлы, вакытлы эш, «картаеп каткач буыннар, вагон бушату уңайсыз ул» дигән Тукай абзаң да. Даими табышлы, переспективалы, хутлырак кәсеп кирәк. Берәр бизнес. Яки түрә булу...

Камил. Бизнеста криминалдан тайпыла алмыйсың. Кемнедер таптамыйча, измичә, өстеннән атлап чыкмый исән кала алмыйсың. Исән калуың — кешелегеңне корбан итү бәрабәренә.

Фарис. Ә түрә булу? Түрә булу бик шәп бит.

Камил. Урыс әйткәндәй, керән тормадан баллы түгел. Түрә булу ул микрохан, микропатша булу дигән сүз. Үз биләмәсен, мөмкинлеген киңәйтү, тәхетен-кәнәфиен саклап калу өчен тегеләре дә, болары да кеше гомерен чүпкә дә санамый. *(Җирдән кәбестә алып урталай яра.)* Патшалар йөз меңнәрне харап итә, түрәләрнең мөмкинлекләре чикле, корбаннары кимрәк, хәл кадәренчә. Ә сине юк итәргә көче җитмәгәне — тормышыңны, елыңны, аеңны, һичьюгы, көнеңне агулый.

Фарис *(хыялланып).* Гап-гади егетләр әллә кемнәр булып бетте, шаклар катарсың...

Камил. Хакимият пирамидасы биек, әмма аның очына кош рухлылар күтәрелә алмый, аларны бөтенесе дә күрә, һәм астан атып төшерүче табыла. Очка үрмәләү өчен хәшәрәт булырга кирәк.

Фарис. Кеше кеше инде, кош төсле, хәшәрәт төсле дип пичәт басып утыру субъектив бәя генә, димәк, гадел дә, дөрес тә була алмый.

Камил. Кешенең тышкы кабыгыннан тыш, рухи сурәте, рухи проекциясе дә була, аны без күрмибез, ә ул бар... Әгәр күрсәк, хакимият пирамидасының гарип-горабалар кунсткамерасы икәнлеге бөтен шәрәлеге белән ачылыр иде.

Фарис. Шуннан нәрсә? Йә, шуннан нәрсә? Пычранудан куркып, үз-үзеңне ниндидер комлыкка куып кертеп, вагон бушатып йөрү әйбәттер дә бәлки, әмма бу юл түгел, ә аннан читкә чыгу — кырыйда калу. Өскә менәргә һәм үзең өчен дә, милләт, халык өчен дә нәрсәдер булдыра алганыңны эшләргә кирәк.

Камил. Кунсткамера нөхсәләренә, ягъни карьеристларга халык та, милләт тә, аның асыл музыкасы, асыл әдәбияты, сәнгате, гомумән, бернәрсәсе дә кирәкми. Милли сабантуйларны нәрсәгә әйләндереп бетерделәр бит, адәм тәганәсе...

Фарис. Ә нишләргә кушасың соң? Туктале, син кайда, кем булып эшлисең? Бармы төп эшең? Бәлкем, төп эшең булмаганга шушылай чапаланасыңдыр? Укыгансың, анысы күренә, бәлкем әле кызыл диплом да алгансың?..

Камил. Укыдым. Кызыл диплом да алдым.

Фарис. Вузда калдың?

Камил. Вузда кал, диделәр, ә минем эштә сыналасым килде. Әмма көн дә тилегә чыгару режимына озак түзә алмадым, кабат институтка кайттым.

Фарис. Фәнни даирәләрдә тилегә чыгарулар юкмыни?

Камил. Адым саен. Әмма производствода син коры җир кешесе сымак, һәм рухыңны гүя тар бер биләмәдә, таш койма белән коймалыйлар. Ә фән — диңгез төсле, анда олы дөньяга чыгу җайлары җитәрлек...

Фарис. Кая күргәнем бар дим, синең фотоңны яшьләр гәзитендә бастылар, ниндидер конкурста җиңгәнсең. Син галим! Һәм институтта укытасың бугай әле?

Камил. Бар андый гөнаһ.

Фарис. Нәрсә, студентларны имү генә җитмимени? Яки син студенткалардан натуралата гына түләтәсеңме? Эх, булмады шундый эшләргә эләгеп, ну, бу башның юкалыклары...

Камил. Бәлкем ышанмассың да, әмма мин хәләл белән хәрәмне бутамыйча, рухка хыянәт итмичә яшәү тарафдары. Син дөрес чамаладың, вагон бушату ул үзенә күрә бер ышык, комырык. Гомумән, татар даими изелүгә дучар рухын авыр хезмәттә савыктырып җан асрый.

Фарис. Анысы хак, чиста яшәүләргә ни җитә. Әле үзем дә, Зәйтүнә исемле кыз белән танышканнан бирле, тәмам тәртә арасына кердем. Ыкты-шыкты беркая атлаган юк. Кыз дисәң кыз, төсе-бите, буе-сыны бер дигән, һәм иң гаҗәбе, шулар өстенә акыллы да. Хәтта сыра да чөмерми. Хәйран инде йөри башлаганга, ни үрелдерми, ни тотындырмый да, пажалый, шуңа өйләнәсе булыр дип торам. Ә синең түтиләр күптер... Менә ни өчен җәфа чигәсең — шуларга акча төткәзә алмыйсың син.

Камил. Кемгә нәрсә, кәҗәгә кәбестә. Миңа эш өчен ашыгыч рәвештә иң кәттә компьютер алырга кирәк. Чит илдән фәнни журналлар алдырам, интернетка түлим, бар инде чыгымнар. Ә ир-ат һәм хатын-кыз мөнәсәбәтләре, минем карашча, чын мәхәббәт нигезендә корылырга тиеш.

Фарис. Ә нәрсә соң ул? Син кайсы заман кешесе? Кемең дә булса бардыр бит?

Камил. Бар иде.

Фарис. Ул башканы сайлады. Синнән мокытракны?

Камил. Шулай да булсын, син кая бөгәсең?

Фарис. Акыллы кешегә чыдау авыр, эшкә каты булмасаң, мин дә синең янда озак түзмәс идем. Хәзер кем ... кемнәр белән чиерттерәсең?

Камил. Нәрсәне күздә тотасың соң син?

Фарис. Егет һәм кыз арасында була торган нормаль мөнәсәбәтләрне.

Камил. Хәзерге нормаларның офыклары бик киң...

Зәйтүнә керә һәм боларның әңгәмәсен вагонга ышыкланып,
кызыксынып тыңлый.

Фарис. Кызлар белән биергә, җырларга, уртак табыннарда утырырга, учаклар ягарга, походларга чыгарга кирәк, агай-эне, менә ни әйтергә телим мин. Калганын үзең чамалыйсың.

Камил. Миңа кайчак иске күршем Наилә кереп чыккалый. Тик ул яшьрәк, без аның белән әйбәт дуслар. Ә беләсеңме, ул зур бер түрә кызы, «феррари»га утырып чаба, һәм, ышанасыңмы-юкмы, Гали Галиичкә туган да тиешле.

Фарис. Кит аннан?! Гали Галиичкә?! Булмас! Нәрсә кош тотып йөрисең соң алай булгач? Правасы бар икән, ничек яшь булсын, инде пешкән, җитлеккән. Ул сине ошатмыймы?

Камил. Киресенчә.

Фарис. Бик котсызмы?

Камил. Алай димәс идем...

Фарис. Эш нидә соң?

Камил. Үзем дә аңламыйм. Наилә чакырган бер мәҗлестә Гали Галиич белән янәшә туры килдем, әңгәмә дә кордык хәтта. Икенче бер мәлдә искәрәм, ул сеңлесеннән минем хакта: «Каян таптың бу мозглякны?» — дип сораштыра... Нәкъ шул мизгелдә мәгъшукам белән карашларыбыз кисешә һәм абайладым, Наилә тач Гали абзасына охшаган!

Фарис. Охшаса ни?

Камил. Шул охшашлык аны миннән ерагайтты.

Фарис. Ә менә мин, киресенчә, ул кызга, Гали Галиич сеңлесе булганга, аңа охшаганга күрә, үзен күрмичә дә колактан гашыйк булдым. Карале, таныштыр мине шуның белән, ә. Туган көнең иртәгә диең бит?

Сызгыру тавышы.

Камил. Әнә маневровый килгән, вагоннарны өләшеп йөри, юк белән баш катырма, бар, вагонны куйдыр.

Фарис. Әмма әңгәмәне дәвам итәбез, Камил дус. *(Йөгереп чыгып китә.)*

Камил, рюкзактан радиоалгыч алып, кирәкле дулкын таба. Анда җыр.

Меңнәр арасында син бердәнбер,
Син бер генә дөнья йөзендә. —
Бер гомер ул нәрсә, мөмкин булса,
Бирер идем унын, йөзен дә.

Зәйтүнә җыр тыңлаучы Камилне борчырга базмый тора.

Син кайларда хәзер, син кайларда,
Җир шарының кайсы төшендә?
Нинди билгеләрдән танып дәшим,
Очрата калсам төшемдә?

Дуслар, таныш, иптәш, якыннардан
Бармы кешең абый диярлек?
Син беренче идең, син бер генә,
Сеңлем итеп башым иярлек.

Зәйтүнә. Исәнмесез.

Камил *(борылып һәм торып басып).* Бик әйбәт без, үзегез ни хәлдә?

Зәйтүнә. Әйбәт. Гафу итегез, ярты базаны әйләндем, шушы якка күрсәттеләр, мин курсташым Фарисны эзли идем.

Камил. Зәйтүнә?

Зәйтүнә. Сез мине беләсез?

Фарис. Белмәскә. Әле генә сезнең хакта җыр тапшырдылар лабаса...

Зәйтүнә. Ышандыра яздыгыз.

Камил. Фарис хәзер килер, утырып торыгыз. Безнең тыйнак табыннан җитешерсез, бәлки. Әнә кишереннән. Тукта, менә монда алмалар да бар ич безнең. Зинһар, хет менә бу кызылын алыгыз. *(Алма тоттыра.)* Үзегезнеке кебек итеп тешләгез шуны.

Зәйтүнә. Кирәкми иде, йә ярар, рәхмәт, алайса, бу бит, чынлап та, мин тыккан алмалар. Уф, Фарис ниләр ялганлады икән инде минем хакта?

Камил. Ул сезне ярата дип аңлашылды.

Зәйтүнә *(кызарынып).* Яңалык...

Камил. Гомере озын булыр. Әнә үзе дә.

Фарис керә.

Фарис. Камил әкә, вагонны куйдылар, кәкрәергә әзер бул. *(Зәйтүнәне күреп.)* Зәйтүнә? Ничек биредә? Нинди җилләр ташлады?

Зәйтүнә. Синең имтихан берсекөнгә түгел, ә иртәгә икән, аны күчергән булганнар, белдерүе деканат каршында эленеп тора. Шуны күрдем дә йөгердем.

Фарис. Инәңнең койрыгы... Грамм укымаган. Җитмәсә, башланмаган вагон бар... Тукта, синең имтиханың бүген иде, ничәгә тапшырдың?

Зәйтүнә. Керергә өлгермәдем, сине эзлисе булды дим бит.

Фарис. Чап алайса. Бәлкем, җитешерсең.

Камил. Иң яхшысы — икегез дә элдертегез.

Фарис. Ә вагон?

Камил. Борчылма, егетләр җитәрлек монда, әнә синең правый рукаларың да эшләрен тәгәлли.

Фарис. Бу минем Камил дус, вузда укыта, өметле галим.

Зәйтүнә *(көлеп).* Өметсез шайтан гына, диләр.

Камил. Рәхмәт. Иртәгә имтиханнан соң кичке җиделәрдә минем туган көнне уздырып алмыйбызмы соң? Мин элекке күршем Наилә туташны дәшәрмен дип торам, сез икегез килсәгез, бик күңелле булыр төсле. Фарис әфәнде, уртак табыннар корырга кирәк, ди әнә.

Зәйтүнә. Фарис үткен егет, уртак табыннарда да шәхси мәнфәгатьләрен онытмый.

Фарис. Рәхмәт, туган, мин инде чакырмассың дип курыккан идем. Килмәгән кая. Тик берүк адресыңны әйтә күр.

Камил. Ә сез?

Зәйтүнә. Энә кайда, җеп шунда...

Камил. Шулай укмыни?

Зәйтүнә. Фариска күз колак булып та таманга туры килә, сез дә сак булыгыз, сөйгәнегезнең башын-күзен әйләндерә күрмәсен.

Камил. Ай-һай, янында сез булгандамы? Адресым... *(Гәзит ертып, читенә язып, Фариска суза.)* «Ни мамык, ни каурый» диләр бит әле. Ни пуха, ни пера инде сезгә, ягъни мәсәлән?

Фарис. К черту.

Зәйтүнә. Шайтан хозурына юнәлегез, Камил әфәнде!..

Китәләр. Камил аларны артларыннан карап озата. Мефистофель ариясеннән өзек яңгырый.

*Икенче күренеш*

Камил фатиры. Ул, алъяпкыч ябып, «җырлар» шыңшып, табын әзерләп йөри.

Камил. Мәхәббәт один раз,
Килми ул много раз,
Как сандугач, как сандугач, каждый яз...

«Күпме күзләр күреп онытылган» җыры мотивына күчә.

Сколько раз гүзәлләрне күреп,
На минутку хискә исердем...

Әллә нишләп ардыра әле соңгы араларда. Бу вагоннар да эт итә. Тәк, бар да бар кебек. Вакыт әле түзәрлек, печтеки генә ял итеп алмый да булмас.

Диванга шул киеменнән барып чүмәшә. Бераздан йокыга тала. Серле музыка.
Ишектә кыңгырау чылтырый. Камил торып утыра.

Камил. Керегез, ачык! *(Наилә керә, киеме заманча, кыю, кулында букет һәм төргәк.)*

Наилә. Исәнмесез, саумысез, нигә чыгып алмыйсыз? Салют. *(Бер кулына чәчәк, икенчесенә төргәк тоттыра һәм үбеп ала.)* Син туган көн дигәч, кызыксынуым җиңде, бөтенесен ташлап чыгып чаптым. Ни булды? Ник әле исеңә төшердең, син әле яшь, мин инде картлач, фәлән-төгән дип сайрый идең ләбаса.

Камил. Әйе, мин өлкән, һәм син миңа сеңел кебек. Без элекке күршеләр, дуслар. Кунакка чакыру өчен бу азмы?

Наилә. Аз да түгел, күп тә түгел, бер ияләнгәч... ничек әле?

Камил. Чүп тә түгел.

Наилә. Ә тагын кемнәрне дәштең? Ученый мирдыр инде? Уф, җанны ялкытачак инде ул күңелсез сөмеки кавем...

Камил. Минем белән кул алмаш вагон бушатучы Фарис студент килә. Спортсмен. Һәм...

Наилә. Һәм? Нигә тынып калдың?

Камил. Аның йөргән кызы Зәйтүнә.

Наилә. Аһ, Зәйтүнә... Бар да аңлашылды. Дустыңның сөйгәненә тәпиеңне сузасың түгелме, Камил әкә...

Камил *(каушап)*. Шулай ук сизеләме?

Наилә. Исемен әйткәндә, кыяфәтең ахмакланды. Ә минем белән сөйләшкәндә, син гел акыллы. Әмма бел, мин сиңа ярдәмче түгел, егетен нейтральләштерүне миннән көтмә, чөнки сине берәүгә калдырырга да риза-бәхил түгел.

Камил. Мин синекеме?

Наилә. Син әле берәүнеке дә түгел. Бир әле алъяпкычны. *(Алъяпкыч ябып, эшкә керешә.)*

Камил *(өстен алмаша. Ак күлмәк кия, галстук бәйли).* Ак күлмәк, кара яка... Ә юк, кара галстук.

Наилә. Синең духовкада ни ул?

Камил. Чикмәнле бавырсак.

Наилә. Бавырсак?

Камил. Әрчемәгән бәрәңге.

Наилә. Туган көн табының артык тыйнак түгелме, дустым? Әни, кирәге чыкса дип, бәлеш салып калды, ун минутлык юл, берара урап килербез... Дусларыңны аулакта калдырып... Аларга бу ошар. Әни дә сине ярата, сәлам әйтте.

Камил. Вәгаләйкем сәлам. *(Өстәлне барлый.)* Тәк, тоз бар. Иң мөһиме — кишер белән күкәй онытылмаган. Торт алынган, шәмнәрен ничек тезәседер, шайтан белсен...

Наилә. Ансын миңа калдыр. Менә бу күчтәнәчләрне дә урнаштырыйк әле... *(Консервлар, шешә, төрле ашамлыклар чыгара.)*

Камил. Наилә туташ, минем сый-хөрмәтне күләгәдә калдырыр ич болар?

Наилә. Киресенчә, ачып җибәрер. Берәр имтиханда берәр танышыма бишле куеп бәхилләрсең. Ә бусы — сәгать.

Камил. Алтын?

Наилә. Бүләк атның тешенә карамыйлар. Булды, авыз ачма, үзең дус дисең, бурычлы булудан куркасың, ә куркаклыкның нинди дә ир-атка килешми. Бу туган көнеңә бүләк, бетте-китте. *(Битеннән үбә.)* Минем туган көнгә «мерседес» бүләк итсәң дә, карышмаска вәгъдә бирәм.

Ишектә кыңгырау чылтырый. Камил каушый, нишләргә белми тора, аннары ишек ачарга китә.

Наилә. Чыннан да, моның түбәсе кузгалган бит...

Камил тавышы. Әйдүк, түрдән узыгыз. *(Камил, Фарис, Зәйтүнә керә.)* Таныш булыгыз, Наилә туташ. Ә болар — Фарис һәм Зәйтүнә.

Наилә. Салют, Зәйтүнә! *(Кочаклап ала. Аннары Фарисны баштанаяк күздән кичерә һәм кулын суза. Фарис Наиләнең кулын үбеп күрешә.)* Аһ, менә нинди икәнсең син, Фарис…

Камил. Чемпион. Вагоннар бушату буенча.

Фарис. Кем чемпиондыр әле? Мин үземне призерга гына чутлыйм. Туган көнең белән, дускай. Менә бу кейс бездән, докторлык диссертацияңне ташып йөрергә.

Зәйтүнә. Ә монысы — чәчәкләр. Котлыйбыз сезне.

Камил. Рәхмәт барыгызга да, әйдәгез табынга утырыйк. *(Чәчәкләрне Наиләгә бирә, анысы вазага утырта.)*

Наилә. Мин Зәйтүнә дигәнне ишеттем, сезнең исемне Оливия дип тә тәрҗемә итеп була икән. Фарис, фамилиягезне, атагызның исемен атамассызмы?

Фарис. Әхмәт улы. Йомаголов.

Наилә. Әхмәт — ә, Йомаголов — кыска и, ә һәм кыска и. Әй килеп чыга. Димәк, сезгә Фарисәй дип эндәшергә була.

Камил. Наилә кушамат тагырга ярата, түзәсе булыр инде. Сез аның миңа таккан кушаматын белсәгез...

Наилә. Булды, туктадым. Әмма башка бер уй кереп чыкты, әгәр Зәйтүнә фамилиясе Йомаголова булып куйса, аны Зәйтүнәй дип атап булачак.

Зәйтүнә. Әгәр синеке шундыйрак хәрефкә башланса, Наиләй буласың.

Наилә. Бик ихтимал... Тәк, шампан шәрабын кем ача? Фарис, күрсәт егетлегеңне. Йоклама, зинһар, йоклама.

Фарис шампанское ача, бокалларга коя.

Фарис *(тост әйтеп)*. Хөрмәтле дуслар! Бүген без өметле галим Камил дусның туган көненә җыелдык. Аңа бүген 33, ягъни гомеренең өчтән бере үтте дигән сүз.

Камил. Мине 99лы диюгә ишарәме инде бу?

Фарис. Киресенчә. Син — акыл иясе. Әмма гел алай яшәү, бердән, үзеңә кыен, икенчедән, бүтәннәрне дә ардырасың, синең янда акыллы булып күренү, әйтик, мин фәкыйрь өчен үтә дә катлаулы, ә бәлкем, мөмкин дә түгелдер. Ихтирам бер нәрсә, ә ярату — башка. Әйе, син ихтирамга лаек. Мәхәббәткә дә лаек буласың килсә, әзрәк ахмаклан. Кыскасы, сиңа бәхет, зур уңышлар хакына әз генә мокытлык теләргә рөхсәт ит!

Наилә. Браво, Фарис. Менә кайда икән аның проблемасы.

Рюмкаларны күтәрәләр. Зәйтүнә тыелырга тели, әмма Наилә уяу.

Зәйтүнә, бирелә ак карга булып утырма, зинһар. Рәхәтләнеп, кара карга булып утыр. *(Камилнең колагына иелә.)* Фарис — класс, бәлкем әле мин сиңа ярдәм дә итеп куярмын.

Зәйтүнә. Фарис бик юмарт кеше, үзендә артык нәрсәне башкаларга тәкъдим итүчән. Әмма ләкин ничек кенә булмасын, мин дә сезгә ак бәхетләр килүен телим! *(Рюмкасын күтәрә.)*

Наилә. Шулай булсын. Тәк, унсигез секунд үтүгә, рюмкаларны кабат тутырасы. Менә бу затлы виноны авыз итәсе иде. Сез беләсез микән, безнең дустыбыз Камил әфәнде җырлар яза, без аннан берәрсен башкаруын үтеник.

Зәйтүнә. Ә тыңлар алдыннан *(рюмкасына вино сала)* моны тотып куюны, шәт, хупларсыз... Фарис, мине күтәреп алып кайтырга туры килмәгәе.

Фарис. Кемгә кемне күтәрәсе ахырдан ачыкланыр.

Наилә. Браво. Сез миңа ошыйсыз, Фарис.

Бар да винодан авыз итәләр. Камил магнитофонга кассета куя.
Музыка яңгырый.

Минус бергә җырлыйсың, димәк. Алайса, без подтанцовка, әйдә әле, Фарис. Йоклама, тиз бул.

Фарис белән Наилә бииләр. Камил Зәйтүнәгә карап җырлый. Наилә утны сүндерә. Зәйтүнәгә Камилне биергә чакырырга ишарәли. Камил белән Зәйтүнә җырны
бергә биеп тәмамлыйлар. Җыр бетә, әмма музыка бераз дәвам итә.

Якынайган саен ара ерак,
Син — зәңгәр күктәге ак болыт,
Йөзәсең омтылып, ә мин торам
Шул болытка карап, онтылып.

Болыт китте узып, ә күңелдә
Зәңгәр төндә купкан ак буран.
Буранга уралып, бер биергә
Дәшкәнеңне көтеп мин торам.

Ак буранлы барыр юлларымда
Якты маяк булып балкыйсың,
Якынайган саен ара ерак,
Ераклашкан саен якын син.

Тормыш — ярсу дәрья, ерак ярда
Аккош микән, әллә син микән?
Ак өметем минем, ак хыялым,
Дулкында тирбәлгән ак җилкән...

Наилә, Фарис, Зәйтүнә кул чабалар.

Фарис *(Камилнең колагына иелеп).* Рәхмәт, туган, син инде мине гел шулай прикрой.

Зәйтүнә. Фарис, нәрсәне ябарга кушасың син анда?

Фарис. Кухнядагы аш-суны, буйдак кешенең фатирында таракан булучан.

Камил. Миндә таракан?..

Фарис. Тулай торактан миңа да ияреп килергә мөмкин ул.

Наилә *(ут яктысында Фарис белән бии).* Артык кысасыз түгелме, чемпион?

Фарис. Кысмыйм, ә күңелем белән тартылам бугай сезгә һәм шуны үзем сизмим.

Наилә. Ахрысы, бер күрүдә гашыйк булгансыз?

Фарис. Ахрысы.

Наилә. Әллә тәкъдим ясаргамы исәбегез?

Фарис. Гали Галиичнең туганынамы? Йөрәгем җитми.

Наилә. Куркакларны җенем сөйми. Әйдә алмашыныйк әле.

Камилне ала, Зәйтүнә Фарис белән бии.

Камил. Рәхмәт килүеңә.

Наилә. Ашыкма, бәлки, мин исәп-хисап ясарга килгәнмендер?

Камил. Нинди исәп-хисап?

Наилә. Син минем йөрәккә ут яккан кеше...

Камил. Кочегар дисең инде...

Наилә. Инде минем чират, ничектер сиңа да ут йоттырасы иде!

Прожектор утына Зәйтүнә белән Фарис эләгә.

Фарис. Йә ничек, карлыгач? Ошыймы биредә?

Зәйтүнә. Карлыгач түгел, карга булып күренәмдер төсле, Наиләгә чат ябыштың түгелме, егетем?

Фарис. Көнләшәсең?..

Зәйтүнә. Юк югын, миңа Камил абый белән аралашуы күңелле, шул никтер хәвефкә сала.

Фарис. Булачак даһи галим, Камил дус, кемнедер бәхетле итәргә бик мөмкин. Әгәр аңарга кияүгә чыксаң, мин моны фаразлап кына әйтүем, эшеңдә зур уңышларга ирешәчәгең көн кебек ачык. Ул — академик, син — фән докторы, кызыгыз — кандидат, улыгыз — аспирант, киявегез — корреспондент әгъзасы, гафу ит, әгъза-корреспондент. Ә? Шәп бит.

Зәйтүнә. Тукта-тукта, син кая таба сукалыйсың? Әллә мине яратам дигән тәкрарларыңның көле күккә очты?

Фарис. Мин сине яратам. Син минем якты йолдызым, һәм шуңа да сине бик тә бәхетле итәсем килә.

Зәйтүнә *(көлеп).* Ничек итеп? Өйләнешергә тәкъдимең дип аңларга мәллә моны?

Фарис. Кияүгә чыгарга дип. Миңамы, башкагамы, ансын үзең чамала. Син быел укуыңны тәмамлыйсың, эш тә табарсың бәлкем. Ә хезмәт хакың ташка үлчим булачак. Мин дә артык мантып китәрмен төсле түгел. Ике хәерче өйләнешүдән мәгънә чыгармы? Дөрес, мин акча табармын, ялларда шабашкада эшләргә була, мөгаен, сине ач ук итмәмдер... Сиңа сау бул, хуш диюем түгел, әмма уйла. Бу даһи яшь галимне каптырсаң, тамчы да каршы булмаячакмын, бел, мин сине матур, рәхәт тормышта бәхетле итеп күрәсем килә .

Зәйтүнә *(көлеп).* Шаяртып та карыйсың. Сине Наилә белән кавыштыру хакына әллә ризалашыйм микән? Туй күлмәге кигән кәләшеңне күтәрә алырсыңмы соң, бик калын күренә. Хәер, син ит комбинатында түшкәләр ташып өйрәнгән инде.

Фарис. Булды. Син туема чакырулы. Юкка көләсең, безнең нәселгә хас шаукым бу, минем абый да бер шәп түрәнең «тутый кош»ын алды. Туенда лыкынганчы эчте. Һәм ахырда кәләшенең фатасын харап итте.

Зәйтүнә. Ничек харап итте?

Фарис. Мәҗлеснең иң кызган мәлендә укшыды. Кәләшнең зур урында эшләүче туганнары, гаҗиз калып, кода белән кодагыйдан: «Каян таптыгыз сез моны?» — дип аптыратып бетерделәр.

Зәйтүнә. Җитте, тозсыз шаяртуларыңны туктат, кызык булмый башлады.

Фарис. Дөресен сөйләгәнне һичкем кабул итми!

Зәйтүнә. Фарис, котыртма, дустың Камил абый белән гариза бирдем куйдым булыр.

Фарис. Моны син әйттең!

Наилә белән Камил яктыга чыга.

Наилә. Унсигез секунд узды, табынга барып килик. *(Музыканы туктата, утны яндыра.)*

Камил *(бокалларны тутырып).* Фарис, син хаклы, кешегә аралашу-очрашу, уртак табыннар бик кирәк. Уртак табын якынайта.

Зәйтүнә. Кемне якынайта, кемне ерагайта...

Камил. Тормышыма яктылык һәм ямь өстәвегезгә чиксез рәхмәт. Барыгызга да бәхет телим.

Бокалларны күтәрәләр.

Наилә. Бәлешсез табын табын түгел! Мин әнигә бәлеш салырга кушып киттем бит. Ун минутлык юл. Йорт хуҗасын алып китүгә ничек карыйсыз?

Зәйтүнә. Уңай. Ак юл сезгә.

Фарис. Мин каршы, безгә күңелсез калыр дип куркам. Кем белә, йә кайтмассыз...

Наилә. Алайса, ялгызым гына урыйм.

Фарис. Мин фәкыйрьне иптәшкә алмассызмы?

Наилә. Зәйтүнә мине кәбестәгә, ә сине кәҗәгә санамасмы соң?

Зәйтүнә *(Фариска).* Бар, бар, рөхсәт. Әмма, Наилә туташ, сез кала кызы, белеп бетермисездер, кәҗә тәкәсе исле булучан.

Наилә. Киттек, Фарис, рөхсәт алынды, юл уңаеннан Казанкага бер чумдырып та чыгармый булмас сине. Үземнең дә ай юлы буйлап йөзәсем килеп китте.

Зәйтүнә. Ә Архимед законын беләсезме соң?

Наилә. Казанканы ярларыннан ташытырмын дисеңме? Көл, көл, ә бит мин бүген шундый халәттә.

Зәйтүнә *(кинәт җитдиләнеп)*. Фарис, әллә син чынлапмы?

Фарис *(колагына).* Мин чукынырга ризалашкан татар шәкерте хәлендә.

Зәйтүнә. Үзеңә кара, үпкәләштән булмасын!

Наилә белән Фарис китә.

Зәйтүнә. Бартер барып чыкты дип уйлыйсызмы?

Камил. Бартер?
Зәйтүнә. Миңа кайтырга вакыт. *(Киенә.)*
Камил. Алар бит ун-унбиш минуттан әйләнеп киләчәк.
Зәйтүнә. Шулай дип өметләнәсезме? Хушыгыз, өметле галим.
Камил. Озатып куярга рөхсәт итәрсез бәлки. Сез миңа үпкәлисезме?
Зәйтүнә. Юк, рәхмәтле. *(Чыгып йөгерә. Аңа Камил иярә.)*

*Өченче күренеш*

Туй. Шау-шу. Ишегалдында табын. Татарча бию көе яңгырый. Кунаклар бии. Фарис, биючеләрне ерып, алгы планга чыга, ул кияү костюмында,
түшендә ак роза.

Фарис *(җыр яңгыраган якка борылып кул болгый, «һава үбү»ләр юллый).* Рәхмәт, абыйлар-апалар, сыйга-хөрмәткә, зур кунак иттегез, инде сау булыгыз!
Наилә. Нишләвең бу, бу бит синең туең, акылыңа кил!
Фарис *(җырлый).*

Сезнең ызба блян безнең ызба
Читән блян алянган,
Сезнең йөрәк блян безнең сердца
Ефәк баулар блян балянган.

*(Наиләгә).* Сау бул, персик. *(Чайкала.)* У-у-у-у, нинди калын апа. Үти, үти, үти. *(Китә башлый.)*
Наилә. Фарис, бәгърем, шаштың мәллә? Бу бит безнең туй. Беркая китмисең! *(Барып беләгенә сарыла.)* Йа Хода, әллә чынлап та ычкынды инде?
Фарис *(айнып).* Әйе, бар андый хәл. Бу — сине эләктерү бәхетеннән.
Наилә. Һәм син аек?
Фарис. Аккошым, син янда булганда аракы мине ала алмый икән. Абыем батырлыгын кабатлау насыйп булмады, гаеп итмәссең.
Наилә. Гали абзыйлар китәргә җыенган, зинһар, матур гына озатыйк, алар бит синең кәмиттән аптырап, тукталыбрак калдылар.
Фарис *(залга карап)*. Туктатмый булмый инде. *(Наиләгә.)* Йөрәк маем, мине Гали Галиич белән икәүдән-икәү сөйләштерсәңче.
Наилә. Бәлкем соңрак, туй сәяхәтеннән соң?
Фарис *(залга карап).* Бүтән вакыт мин аның каршында маклер хозурындагы терлек хәлендә торачакмын. Хет өендә булсын, хет кабинетында. Бүген шартлар искиткеч: мин кадерле кияү, ә ул туема рәхим иткән хөрмәтле хөрмә төше.
Наилә. Хәзер, әтигә әйтеп карыйм.
Фарис. Үзең әйтсәң, хәерлерәк булыр. Чөнки син кәләш, ә ул сине зурлап туеңа килгән абзаң. Бар, күбәләгем, оч!
Наилә. Очтым, йөрәк маем, алтын алмам, иккүзем. *(Китә.)*
Фарис *(җырлый).*

Акча ясый торган машинамны
Чыгарып басыгыз герәзгә.
Алмачуар белән Тимер-күкне
Чыгарып сатыгыз кенәзгә.
Ай, Әптелмән купис, кем идең,
Никулай падишага тиң идең...

Галиич, чыгып, Фарисның җырлаганын тыңлый.

Галиич. Ай-һай, кияү, сиңа артист кына буласы калган.
Фарис. «Дөнья сәхнә, анда һәркем артист», — дигән бер бөек кеше. Әмма берәүгә баш, ә берәүгә түш роль тәти. Менә мин, сезнең нәсел башы Әптелмән куписны искә алдым, ә бит мәкаль хак, писердән писер туа, кишердән кишер туа!

Галиич. Кияү балакай, күрәм, сине кишерлек ялкыткан.

Фарис. Мин кемнән ким, арка чокыр, күкрәк киң.

Галиич. Алма пеш, авызыма төш, дип кенә рәт чыкмый бит.

Фарис. Ә мин *(түшендәге чәчәккә кагылып)* кайбер дөрес хәрәкәтләр ясадым шикелле.

Галиич. Алай... Һы. *(Башын чайкый.)* Яхшы. Хуп. Моңарчы хезмәтеңдә алга үрләү булдымы бераз?

Фарис. Вуз тәмамлыйм быел. Аннары табуреткада чалбар төбе шомартасы була инде гомер буе, әгәр берәр җай чыкмаса.

Галиич. Минем абзыйның киявен артсыз урындыкта утырту, агач атка атландыру белән бер, килешәм. Үсәсе килә дисең инде?.. Ә моның өчен сиңа иң әүвәле беләсеңме ни җитми?

Фарис. Үсемлеккә җылы кояш, ә кадрга баш очындагы кара болытларны да җылы яңгырга әйләндерүче җылы караш кирәк.

Галиич. Дөрес, тик бу аз. Әле кадр үссен өчен аның күңеленә бераз ашлама, әйтик, тирес тә кирәк булачак. Сизәм, синең күңел ул малдан дөм буш түгел, әмма тагын кирәк. Аннары бераз агу... Намус, вөҗдан дигән сафсаталар тәэсире астында үрчегән икеләнү кортларын кояр өчен. Әйе, килешәм, өйләнүең алга омтылуыңда беренче дөрес адымың. Әмма киләчәктә әле сиңа шактый кыйммәт түләргә туры киләчәк...

Фарис *(кесәләрен әйләндереп)*. Хатын ярдәм итсә генә инде.

Галиич *(көлеп)*. Синең түләрлек нәрсәләрең бар әле. Синең рухың бүген очар кош шикелле. Киләчәктә шуның йолкынган тавык хәлендә калуы куркытмыймы?

Фарис. Мин хәзерге хәлемне өтеклек дип бәялим. Яхшы фатирларда торасым, «мерседес»ларда җилдерәсем килә, шундый хыяллар утында янам мин.

Галиич. Афәрин! *(Фарисның ялганчы чокырына бармагын батыра.)* Максатчан кешеләрне яратам. Бәлкем, бер биш-алты елдан минем янда ук эш табылыр...

Фарис. Биш-алты?

Галиич. Кадр җитлектерү уен эш түгел, кияү балакай, барлык үсеш этапларын йөгерттереп булса да уздырмый ярамый.

Фарис. Мин ни, ни, йөгерттерсәгез, йөгерәм, Гали Галиич! *(Сәхнәне урап йөгереп килә.)*

*Дүртенче күренеш*

Фарис-2 пәйда була һәм Фарисны якасыннан эләктереп ала.

Фарис-2. Акылыңа кил, син нишлисең?

Фарис *(буылып)*. Син кем? Җибәр бугазны.

Фарис-2. Мин синең «икенче мин»ең, синең хакыйкый асылың, горурлыгың, намусың, вөҗданың, кыскасы, син түгел, ә мин — чын Фарис. Болай барсаң, исемеңне Фарисәйгә алмаштыр!

Фарис. Йә җибәр инде. Таныдым, таныдым дим бит!

Фарис-2. Ниемә бу маскарад? Нәмәкәйгә кирәк сиңа боларның мактанчык кызлары?

Фарис. Тугры булса, шул җиткән.

Фарис-2. Булмыйни. Әйдә киттек моннан тизрәк.

Фарис. Кая?

Фарис-2. Зәйтүнә янына, билгеле. Ул бит сине ярата, аңлар, кичерер. Мин сине һич аңлый алмыйм, дус кеше.

Фарис. Яратып өйләнүдән ни мәгънә. Минем киләчәктә үз «мерседес»ым булачак. Затлы кием-салым, затлы ризыклар. Чит илләргә командировкалар. Шәп пост. Вәт аннан үчен кайтарабыз инде сөймәгән түтәй белән яшәгәннең. Туташларның ниндие кирәк, шундые түшәгеңә чират тора, шәп бит. *(Күз кыса.)* Ә моңа ирешүнең юлы бер, Наилә туташны бәхетле итү.

Сәхнәгә Гали Галиич керә.

Галиич. Кем белән авыз суыңны корытасың анда, кияү балакай?

Фарис. Таныш булыгыз, бу минем «икенче мин»ем.

Галиич *(Фарис-2нең авызын ачтырып карый)*. О-о-о. Тешләр бүренеке кебек. *(Фарис-2 көч-хәл белән ачуын тыеп тора.)* Бик солтанат күренә «икенче мин»ең, муенына эт ассаң, койрыгы җиргә тимәячәк. *(Фарис-2 Галиичны измәкче булып кузгала, әмма аңа Фарис ябыша һәм, башын иеп, кисәк этеп, артына утырта, аннары артына тибеп куып озата.)*

Галиич. Чут чыгар кебек синнән, егетем. Яле әйт, үсәргә теләүче иң элек нишләргә тиеш?

Фарис *(каушап)*. Кайда кушсалар, шунда утырырга, кирәкмәгән төшкә борын тыкмаска.

Галиич. Монысы хәвефсезлек техникасына карый. Да. Бу мәсьәләдә минем Шарик тирәнрәк йөзә икән...

Фарис *(башына учы белән суга)*. Койрык болгарга!

Галиич. Минем Шарик, арт тәпиләренә басып, күзгә мөлдерәп карап тора, койрык болгый, ботинка башларын ялый, ә ятларга селәгәенә тончыга-тончыга өрә!

Фарис. Димәк, өстәгеләр каршында арт тәпиләргә басып койрык болгарга, ә астагыларга бер ботны күтәрергә!

Галиич. Афәрин! *(Башына чиертә.)* Дөм буш түгел, ахры, монда.

Фарис. Үрмәләргә иде инде.

Галиич. Башта үрмәләргә, бераздан атлап китәргә, аннан канат ярып очарга!

Фарис. Очарга!

Галиич. Әлбәттә. Дөрес, син, офыкларны иңләп, бөркеттәй тирбәлә алмассың алуын, әмма чүрәкәй сыман пыр-пыр килеп йөрүең бик ихтимал. *(Фарис бирелеп тыңлый.)* Башта куярбыз сине көчек должностенә! *(Фарис, иелә төшеп, көчек позициясен ала.)* Көчек ул, кусаң, чигенә-чигенә өрә, ә инде әйбәтләп артына типсәң, үпкәләп, чиный-чиный чабып китә. Әмма үпкәсе озакка бармый, янә аяк арасына кереп, итек кунычына башын куя. *(Фарис боларның барысын да башкара. Соңыннан Галиич дүртаякланган Фарисның ияк астын кашый.)*

Фарис. Көчекне уңышлы узсам, кая?

Галиич. Әлбәттә, кәҗә должностенә.

Фарис. Кәҗә?

Галиич. Ә нәрсә? Сакал бар бу хайванда, мөгез дә ярыйсы, койрык ягы дан түгел түгелен, сөтне дә аз бирә, аның караввы көтүдә алда йөри, юлбашчы, әйтергә кирәк.

Фарис. Персональ машиналы эшме соң ул, ичмасам?

Галиич. Аның көчеге дә машиналы. Ә кәҗә посты чит ил командировкаларына да юл ача.

Фарис *(шатланып)*. Ми-ки-ки-ки!!!

Галиич. Бер-ике ел сакал селкетеп йөргәч, институтта берәр темага кандидатлык яклагач, умырып ала торган бурзай вазифасына куярбыз...

Фарис. Тагын өрәсе?

Галиич. Нишләмәк кирәк. Язмыш. Кемдер сине, эттәй өрә, дип гаепләсә, исең китмәсен, чөнки бу дөрес түгел, дөресе — эт кеше шикелле өрә. Менә кара. Этнең башлангычы бүре. *(Фарис дүртаяклана.)* Ә бүре өрми, ул улый. *(Фарисның башын сыйпый.)* Эт буласы бүре кешегә ияләшкәндә улый торган булган.

Фарис. У-у-у-уу.

Гали. Тора-бара аңа хуҗасы сыйфатлары йоккан, яман гадәт йога бит ул, һәм шуннан киткән багана саен туктау, койрык болгау, өрү.

Фарис. Стоп. Кешенең эт ияләштергән чагында койрыгы булганмыни?

Галиич. Хәзер дә койрыксыз кеше сирәк ул, энекәем Фарисәй, муен тамырыңа бозау аягы. Кешемени ул койрыксыз кеше?

Фарис *(Галиичның артына төшеп, койрык булырга тиеш урынны караштырып)*. Кай төшендә була соң ул аның?

Галиич. Менә мин, берәр яры «джип» яки «мерседес»ыма утырып, кая да булса чыксам, бер көтү машина тагыла. Җәяү йөргәндә дә озатучыларым ишле. Менә шулар инде минем койрык, бәлкем әле аларны зур койрыкның аерым төкләре дип карарга кирәктер. Арада иң якыннары артыңнан кайчан тын алуыңнан да хәбәрдар була.

Фарис. Стоп. Патшалар яраннарын ияртеп йөрткән, сезгә дә актив тагыла, димәк, берни юкка чыкмый, бер форма икенчесе белән генә алмашына. Ә бу — Ломоносов законы.

Галиич. Бу тормыш законы, энем, ә ниндидер сынык борынныкы түгел. Сиңа иң төп сорау, кеше кайчан ике аякланган?

Фарис. Ә-ә-ә-ә, искә төште. Ул агачлардан үрелеп чикләвекләр, җиләк-җимешләр өзә-өзә ике аяклан-ган.

Галиич. Алайса, ник соң кәҗә ике аякланмый? Колагыңа киртләп куй, кеше, күңелендә ялагайлык хисе яралгач, ике аякланган.

Фарис. Стоп. Алайса, ник эт ике аякланмый?

Галиич. Чөнки эт беркатлы зат, хуҗасы алдында гына арт тәпигә баса, ә кеше моны күпләр каршында башкара. Еш кабатлану нәтиҗәсендә әлеге рәвеш тора-бара ныгып ук калган. Озын сүзнең кыскасы, кеше буласың килсә, чыгышыңны, тамырыңны бел, ә ул үткән тәҗрибәгә мөрәҗәгать итәргә, ягъни арт тәпиләргә басарга һәм өрергә димли.

Туй җыры яңгырый, Наилә чыгып килә.

Наилә. Сездән башка анда күңелсез, әйдәгез, көтәләр анда.

Галиич *(Фариска)*. Ошадың әле син миңа, кияү. Наилә элегрәк бер мозгляк белән мавыккан иде, кемнең Гулливер, ә үзенең лилипут икәнен төшенми торган. Дөрес, син дә кәрлә, әмма үсәчәксең! Үсәчәксең һәм очачаксың. «Вау-вау»!

Фарис. «Вәү», «вәү», «вәү»! *(Күкне күзәтә.)* Күк нинди киң! Иркенлек! Очарга! Чүрәкәй кебек, пыр-пыр килеп булса да очарга кирәк, шайтан алгыры!!! *(Җырлый.)*

Наилә аны коча.
Хәзер дөнья шуңа китте,
Космонавт та көтүче,
Мин дә айга менәчәкмен,
Гали Галиич яшәсен!!!

Наиләне күтәреп әйләндерә.

Беренче пәрдә тәмам.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### *Бишенче күренеш*

Кабул итү бүлмәсе һәм кабинет. Кабул итү бүлмәсендә Наҗия, әби, гозер белән килүчеләр: №1 һәм №2, артист. Стенада кәкре-бөкреле сызым. Каяндыр
Фарисның кычкырып сөйләгәне ишетелә.

Фарис тавышы. Эшләргә уйлыйсызмы сез канса кансов. Зарплата? Акча түләп дурак та эшләтә! Табыгыз! Культура — бөтен составы белән бәрәңгегә мобилизацияләнә. Мәктәпләрне ябасыз, врачлар — бәрәңгегә. Милиция начальнигы, прокурор, давай, сез бездельниклар белән разберитесь, сопли кирәк түгел разводить, кемгә кирәк, шуның күлмәген күтәртеп эченә, җитми икән, чалбарын төшереп, артына тибәсез!

Кабул итү бүлмәсендәгеләр хәвефләнеп тыңлыйлар, Наҗия тырнакларын тигезли.

Әби. Ай-һай, кәҗә тизәгедәй чәчелә бу, гозеремне тыңларлык мәне калыр микән?

Наҗия. Тыңлатыр өчен менә моннан үтәсең бар әле башта. *(Ишеккә ымлап.)* Карагыз әле моңа. Менә бу сызымга. *(Кәкре-бөкре сызымга указка белән төртеп.)* Менә сез гариза белән йөрисе юллар бу. Менә сез үтәсе инстанцияләр. Менә сез әләгергә мөмкин кармаклар, өсте ябулы чокыр-базлар. Менә сез шушыларны үтеп беткәч кенә монда керә аласыз. Әгәр йөреп бетерми килгәнсез икән, йөреп бетерегез, Фарис Әхмәтович уен кагыйдәсен боза торган кеше түгел... Аңладыгызмы?

№2 гозерче. Без инде бу боҗраларны бер генә кат урамадык, монда йөри башлаганга да атна була. Тик шушы ике катлы ишектән генә һаман кереп китеп булмый.

№1 гозерче *(урыныннан тора, йөренеп)*. Аһ, бу ике катлы ишек аша үтүләре... Гозер белән киләсеңме, сүгәргә дәшеп алдыраларммы *(ишеккә ымлый)* —ике катлы ишек сине көтә.

Наҗия. Килү белән кереп китү бәхете, әлбәттә, синдәйләргә тәтеми, башта менә минем хозурда бер-ике сәгать тозлан, пеш, җитлек. Аннары апагыз әйтер, керергәме, әллә кайтып торыргамы. Рас, тәртип шундый, сабыр итми чараң юк, син кемнән артык, аркаң — дуга, бүксәң — капчык.

№2 гозерче *(урыныннан торып йөренеп)*. Бәлкем, чиратсыз кереп булыр дигән өмет белән шыпан-шыпан ишек тирәли әйләнеп киләсең. Син якынайган чакта, аннан берәрсе чыкса, кереп китеп булыр төсле.

Наҗия. Әмма мин уяу, сезнең уйны адымыгыздан чамалап, бер генә акаям, ничек күн диван читенә чүмәшүегезне сизми дә каласыз.

№1 гозерче. Хәләл чират җиткәч тә бит әле сез безне туктатып, берәр Мырауҗанны яки Мияубикәне уздырасыз...

Наҗия *(көлеп)*. Ә алар керү белән баталар һәм, мунча кереп, чыгар ара үтмичә кабинетны бушатмыйлар.

Әби. Ә көткәндә минутлар гасырга тиң.

№2 гозерче. Күзләрең күгәреп, кан басымың уйнап, тешең сызлап, тез буыннарың дер-дер калтырый башлагач...

Наҗия. Вәгъдә сәгате суга, морадыгызга ирешергә санаулы адымнар гына кала!

Әби. Берәр әрсез алабай тагын юлыңа аркылы төшмәсен дип, ишеккә ташланасы килә...

№1 гозерче. Менмәгән абруеңны төшерергә куркып, ут йотып, тәкатьсез күңелеңне көч-хәл белән авызлыклап, салмак атларга тотынасың. Беренче кат ишекне үткәч *(үтә),* аны әйбәтләп ябасың. *(№1 гозерче ике ишек арасында кала.)* Уф... Инде, шәт, иншаллаһ, бәреп узып китмәсләр, дисең... Шулчак шаян, асылда, ахмак бер уй миеңне бораулап ала, әгәр кергән ишегеңне шартлатып бикләп алсалар, ә алдагысы ачылмаса? Яки караңгыда кирәкмәгән берәр кнопкага ялгыш орынудан басып торган мәйданчыгың лифт сыман аска яки өскә китеп барса, нишләргә? Көлемсерәгән буласың. Ләкин эчкә йөгерә башлаган салкын шомны куаларга җегәрең сыек булып чыга. Караңгыда капшана-капшана, ашыга-кабалана ишек тоткасы эзли башлыйсың. *(№1 гозерче эзләнә, башкалар көч биреп тора.)* Йа Алла, табыплар булмый лабаса. Шушы түгелме? Шушы гына булса ярар иде, дип, тотканы үзеңә тарта башлыйсың.

Әби

№2 гозерче *(Өчесе бергә.)* Ачылмый?

Наҗия

№1 гозерче. Ачылмый... Көлмәкче буласың, кая инде көлү, авыз гына кыегая. Аяк терәп, тагын бер тартасың... һәм бу шөгылеңнән ишек тоткасы суырылып чыга башлагач кына туктыйсың. Димәк, алга юл юк. Бәлкем, артка юл калгандыр? Актык өмет багларга да куркып, ике учың һәм күкрәгең белән кергән ишегеңә капланасың. *(Каплана, ишек ачыла.)* Уф! Монысы ачыла икән. Шулчак зарыгучылар, бу чыгып җитте, дип уйлап дәррәү сиңа таба ташланалар, авыз ачып торсаң, йә таптап, йә үзеңне читкә болгап үтеп тә китәчәкләр. *(№2 гозерче һәм әби моңа якынлаша.)* Ишек тоткасын ике куллап кысып, чүгәли төшеп, үзеңә тартасың *(беренче ишекне япканда, икенчесе №1 гозерченең арты бәрелүдән ачылып китә)* һәм бер генә мизгел караңгыда каласың. Тарткан мәлдә, теге ачылмый интектергән ишеккә артың бәрелүдән дөнья кинәт яктырып китә. Кайдан, нидән бу, дип, башта аңышмый торасың, аннары, тынсыз калып, муеныңны борсаң, ишек шыр ачык, түрдә, күтәртелгән юл шикелле өстәлләр очында кемдер бар шикелле. Әле шөкер, ара ерак. *(Башкалар моның сөйләгәнен куәтләп тыңлап тора.)* Кабинет ындыр табагыдай, һәм синең матавыклануыңны бинокльсез күрерлек түгел. Кабинет буйлап, йомшак келәмгә бата-чума беркавым баргач, абайлыйсың, чыннан да, түрдә берәү бар, һәм ул берьюлы дүрт телефоннан сөйләшә.

Әби. Бөек кешеләр гомер бакый берьюлы өч-дүрт эш эшләгән. *(№1 гозерче баш кага.)*

№2 гозерче. Син якынайган саен, теге һаман үсә. *(№1 гозерче янә хуплап баш кага.)*

№1 гозерче. Менә ул, тау кадәрле булып, өстәле артыннан чыга. Сине күреп түгел, болай гына, киерелер өчен. Ә син кечерәясең дә кечерәясең, тиз генә штиблетларын ялап куясың, бауларын төзәткәлисең. Бу, уңае килеп, гозереңне үтәргә дә, ата-бабадан ишетмәгәнеңне ишеттерергә дә мөмкин...

№2 гозерче. Син инде тотып ашамагач, боларына гына түзәсең.

№1 гозерче. Китешли, рәхмәт укып, башыңны еш ия-ия чигенәсең һәм ике катлы ишек арасына таракандай кереп китеп, ялт, юк буласың. Караңгыда ялгыз калгач, колакларыңнан тартып, үз-үзеңне үстерәсең. Аннары, чыраеңа тантаналы мәгъруրлык элеп, зарыгучылар бүлмәсенә аяк басасың. Баш бераз әйләнә. Тәндә җиңеллек. Мөгаен, парашюттан сикергән кеше шундый хис кичерәдер.

Бар да кул чаба һәм моны тәбрикли. Телефон чылтырый,
Наҗия трубканы күтәрә.

Наҗия. Тыңлыйм. Фарис Әхмәтович конференцияләр залында, киңәшмә уздыра. Гали Галиичкә чылтыратсын? Биш минуттан? *(Трубканы куя һәм гозерчеләргә карап.)* Гали Галиич белән сөйләшкәннән соң ул сезне йә кабул итмәс, йә кабул итүнең файдасы шуның хәтле булыр. *(Чыгып йөгерә.)*

№1 гозерче. Әллә кайтып торыйк микән?

№2 гозерче. Бар, сине кем тота соң? Вакытың күп, йөр дә йөр.

Әби. Файдасы шуның хәтле генә диме? Ә бәлкем, миңа, карт кешегә шуның хәтле генә кирәктер дә.

Фарис тавышы. Җыелышны миннән башка очларсыз, но, миннән пощады не ждите!

Бераздан Фарис, ашыгып, кабинетына үтә һәм телефонга ябыша, Наҗия үз
урынын били.

Фарис. Гали Галиич. Әйе. Эшлибез. Хәл ителә. Әйтелгән сроктан чыкты юк. График буенча. Әйе, киңәшмә җыйган идем. Акча? Бу айда да киметмәбез, килсен, алыр. Эш хакын пока түләп булмый, ну, халык күнекте бит инде, түзәр. Саламын-печәнен биреп барабыз бит. Яхшы. Сәламегезне тапшырырмын. Хушыгыз. *(Трубканы куеп.)* Туймаса туймый кеше дигәнең, һаман акча каера. Бирүен дә бирә, алырга да оныттмый.

Наҗия *(селекторга)*. Бүген сезнең кабул итү көне, биредә өч гозерче бар, кабул итәсезме, кайтып торсыннармы?

Фарис. Алар минем күзгә чалынгаладылар бугай?

Нажия. Бер атна йөри инде икесе.

Фарис. Керт.

Нажия *(№1 гозерчегә керергә ымлый)*. Сүзеңне кыска тот, монда тагын ике кеше бар.

№1 гозерче эчкә үтә, Фарис аңа утырырга куша, ул бер читтәге урындыкка бер утыра, бер тора.

№1 гозерче. Минем сеңелнең 14 яшьлек кызын милиция начальнигы малае көчләде. Сеңелнең ире алкаш, тормышлары авыр, прокурорга барган идек, кызның пычранган киемнәрен алып калдылар. Хәзер халык сөйли, бу киемнәрне шунда эшләүче тикшерүче катын юып үтүкләгән, аннары экспертизага җибәргән. Хәзер безгә әйттеләр, бернинди көчләү юк, экспертиза шуны күрсәтә, диләр.

Фарис. Югарыга жалоба яздыгызмы соң?

№1 гозерче. Карга күзен карга чукыр дисезме?

Фарис. Анысы да дөрес.

№1 гозерче. Сез бит безнең депутат. Сез бит очрашуда әйткән идегез, яшь чакта, студент чакта вагонын да бушаттык, дидегез, үдебеднең кешерәк дип чутлап килгән идем.

Фарис. Аның бит срогы бар. Срогы үткәч сезнең жалобаны беркем карамаячак. Ә ул үткәндер дә инде.

№1 гозерче. Әтисен эчерткәләп, аракылык биргәләп торалар, анасы иреннән уза алмый. Мин йөреп рәт чыгармы, белгән юк.

Фарис. Сигнал өчен рәхмәт, кәнишне, мин прокурор белән сөйләшермен, җинаяте расланса, гаепле кеше җәзасын да алыр, кем белә, бернинди дә вәгъдә бирә алмыйм. Бездә бит демократия, минем хокук органнарына басым ясарга хокукым юк. Әнә сызым, кабул итү бүлмәсендә дә эленеп тора ул, шуның буенча хәрәкәт итегез. Сез ни телисез соң?

№1 гозерче. Эшеннән куарга кирәк, ул сбулыч прокурорны! Ә теге кабахәтне утыртырга. Кирәк икән, Казанга, кирәк икән, Мәскәүгә чыгып китәм. Акча юклык кына чабудан тота.

Фарис. Акча кирәксә, процентыннан курыкмасагыз, әнә ссуда алыгыз. Тагын нәрсә диим, һәрхәлдә, мин сезнең якта.

№1 гозерче. Рәхмәт яхшы сүзегезгә, сау булыгыз, акча мәсьәләсендә хатын белән киңәшләшми булмас. *(Китә.)*

Фарис. Әле ул ссуданы алыр өчен ярты ел йөрергә кирәк. Ә ул арада... *(Телефон трубкасын күтәрә.)* Йә, ничек анда хәлләр, иптәш прокурор? Әлбәттә, без кушкач, сезгә үтәми ярамый, ну, малайны коткарып дөрес эшләдегез, үзегезнең коллега улы бит. Беләсеңме, иптәш прокурор, син кем? Синең законнарың этләр, ә син шуларны тәрбияләүче. Мин өстергән кешегә алар ташлана һәм өзгәләп ташлый, ә «чәбә» дим икән инде, болар аның ботинка башларын ялап, койрыкларын болгарга мәхкүм. Синең төп задача шул, бәяң дә шуннан чыгып бирелә, аңладыңмы? Әйе, керде, әле генә. Син үзең йөрмә, малайның әтисе чапсын, төртсен инде бераз, җайласын, рас, җинаятьне йомып калдырдыгыз, исе чыгарлык булмасын. Нүжәли шул йолкышның авызын томаларлык җай тапмыйсыз? Башта яхшылык белән, аннары үзегез беләсез, сезне монда мин өйрәтеп утырмам бит. Ярый, хушыгыз.

№ 2 гозерче керә.

№2 гозерче. Малай харап булды, Фарис улым. Чечнядә иде бит. Гәүдәсен тиз генә озата алмыйбыз, килеп алыгыз дип телеграм сукканнар. Алып кайтырга иде бит, акча юк, баянкомат, бездә андый статья юк, ди. Колхозыбыз рәисе дә акча юк, ди. Мин үзем инвалид, хатын сукыр.

Фарис. Ал банктан ссуда. Гариза яз.

№2 гозерче. Пронситы буламы инде аның?

Фарис. Була. Закон бит синең өчен генә чыкмаган.

№2 гозерче. Мин аны түли алырым микән соң?

Фарис. Кайгырма. Алар анда кайтарып алу җаен яхшы белә. Йорт-җиреңне, мал-туарыңны бәялиләр, пенсиягез бардыр, инвалидлар дисең бит үзегезне. *(Бер кәгазь алып нидер яза.)* Менә шушы кешегә кер, ул сиңа барын аңлатыр. Хуш, абзый, сау бул.

№2 гозерче. Алланың рәхмәте төшсен сиңа, улым. *(Китә.)*

Фарис *(селекторга кычкыра)*. Бүгенгә җитеп торыр.

Әби, Нажия белән тарткалашып, кабинетка керергә омтыла.

Нажия. Әби, бераз сабыр итегез, үзем рөхсәт сорап карыйм, бәлкем кабул итәр?

Әби. Заманында үгезне тәртә арасына керткән кортканың юлын бүлә алмассың. *(Нажияне этеп кереп китә, Нажия аңа иярә.)*

Әби. Депутак та депутак, диләр, кая соң безнең депутагыбыз дип, килдем әле улым, исәнме!

Нәҗия. Мине тыңламый, Фарис Әхмәтович, үтте дә китте, әллә нинди әби бу!

Фарис. Зыян юк, эшеңне кара. Ярар, гражданка, йомышыгызны әйтегез, тыңлыйм, вакытым тар.

Әби. Ничек син мине тыңлыйсың? Юк, улым, син түгел, мин сине тыңларга килдем. Ничек яшәтмәкче буласың дәлше? Ни трактарис малайның, ни сыер савучы килененнең рәтле эш хакы күргәне юк, бөтенесе минем пинсәгә карап тора. Газга түлисе, үзләре салган өйгә налук китереп салдылар, ничә төр страхавае, балаларны укытырга кирәк. Эшли-эшли эчәгеләре чыга бит инде халыкның, нәрсә майтарасыз соң сез монда безнең тормышны рәтләр өчен? Ни иткә рәтле бәя юк, җитмәсә, сөтне дә судан арзан хакка җыйдырасың, шунысын да бирмичә, Казанның халтуршик артистлары кансертын күрсәтеп бәхилләттең. Акчасын урталай бүлгәнсездер инде. Болай яшәп булмый лабаса, энекәем Фарисәй, муен тамырыңа бозау аягы.

Фарис. Нигә сез мине Фарисәй дип мыскыл итәсез?

Әби. Бөтен кеше шулай дип йөри сине. Хәтта хәләл катының да. Белми идеңмени, Фарисәй улым, муен тамырыңа бозау аягы.

Фарис. Ә синең борын төбеңә кәҗә тоягы. Ычкын моннан яхшы чакта. Элек тә күп үзәккә үттең, жалобалар язып. Хәзер теләсә кая бар, ирек, тәк йөри бир, бәкегә төшкән ат тизәге сыман. Кемгә кирәк син? Салам-печән бирәләр икән, улың-килене канәгать булсын. Ә балаларны укытам дип тилермәсеннәр. Армиягә кирәк алар, киң кырларга, төзелешләргә. Аңладыңмы?

Әби. Рәхмәт, улым, әле болай чын дөресен әйтеп бирәү дә аңлатканы юк иде. Бар да шомартып чыгара. Ахрысы, син арада иң ихласы. Сау бул, исән яшә. Мин барын да аңладым. Минем алда синең тышкы кабыгың, һәм ул күрер күзгә бик күркәм һәм ямьле. Әмма, асылда, син — черек җан, синең чын кыяфәтеңне ни үзең, ни башкалар күрми. Шулай дип йөрисеңдер. Әмма сөенмә, күрмәсәләр дә, тоялар, сизәләр, чамалыйлар! Мин сине үтәли күрәм. Күрәм! Карарлыгың калмаган лабаса. Болай барсаң, әкияттәге «үзе бер карыш, сакалы биш карыш»лыга әйләнәчәксең, белдеңме шуны! *(Бөкерәеп чыгып китә.)*

Фарис *(тәрәзәгә килә, валидол каба, аннары тәмәке кабыза)*. Кабахәт... Яшь чагында президиумнарда йөрткәннәрдер дә, депутатлыкта хәзер вакытың узган шул инде. *(Тәмәке тарта.)* Әһә, киңәшмәне очлаганнар икән, кузгалганнар. Тукта, кемнәр соң әле болар? Карасана, берсен икәве култыгыннан алып сөйри, ә тегенең күзендә «фонарь». Ә бусының кулы, марля белән уралып, муенына асылган. Һе-һе. Монда җыен аксак-туксак, барабан корсаклар лабаса. Һу. Бу икәвенең колагы бияләй кебек кабарган.

Фарис-2 пәйда була, ул гариплэнгән һәм картайган.

Фарис-2. Болар — әле генә җыелышта син бастырып сүккән кешеләрнең «икенче мин»нәре, горурлыклары, кешелекләре.

Фарис. Катырак эләкте шул. Туктале, ә син үзең кем?

Фарис-2. Бер дә төсмерләмисеңме?

Фарис *(җирәнеп һәм куркып)*. Син?! Ничек шушы көнгә төштең?

Фарис-2. Моны синнән сорасаң әйбәтрәк булыр иде. Син тәлинкә тоткан түрәләр тырышлыгы нәтиҗәсе. *(Елый.)* Нишләтеп кенә бетермәделәр алар мине. *(Авызын ача.)* Күр, бер тешне калдырмадылар, авызны мүкелдәтеп йөрергә генә калды.

Фарис. Димәк, кортка хаклы. *(Күзен йомып, сейфтан коньяк коеп эчә һәм селекторга баса. Нәҗия керә.)*

Нәҗия. Берәү дә калмады, Фарис Әхмәтович, мин дә җыенган идем инде.

Фарис. Ә кабинетта мин үзем генәме соң?

Нәҗия. Кем булсын инде монда тагы?

Фарис. Бәлкем, берәр рюмка тотарсың, менә конфетлар.

Нәҗия *(чытлыкланып)*. Көннән-көн яшәрәсез, Фарис абый, бер көн дә ял иттермисез. *(Алдына утыра, коньяк уртлый, конфет белән сыйлана. Кинәт яшен яшьнәгәндәй була һәм, Нәҗиягә сырышып, Надия пәйда була).*

Фарис *(коты алынып)*. Бу тагын нинди убырлы карчык? Чыгып киткән идең ләбаса?

Нәҗия *(Надияне күрми)*. Монда без икәү генә. Сез мине убырлы ди башладыгыз мәллә?

Фарис. Юк, юк. Син матур, син китмә. Ә бу убырлы ычкынсын!

Надия Фарисны үчекли, аңа тотынгалый.

Фарис *(башына ябыша һәм төшенеп)*. Белдем. Синең «икенче мин»ең. Юк, менә болай дөрес *(кычкырып),* синең горурлыгың зур сынаулар узган, ахры, Нәҗия?

Нәҗия. Күрде инде безнең башлар, Фарис абый. Синең белән дә, сиңа хәтле дә. Менә мине чибәр, диләр. Ә кайчак үз-үземә җен карчыгыдай тоелам, беләсезме?

Фарис. Ярар, үскәнем, кайт булмаса, кайтыгыз, мин бераз утырам әле.

Нажия *(тагын бер рюмка тотып куя).* Әллә сез дә мине ямьсез итеп күрә башладыгыз?

Фарис. Юк, сөеклем, син бик матур, хикмәт миндә, мин карт алашада.

Нажия. Карт алаша буразнаны бозмый. *(Кочарга тели. Надия, маймылланып, Фарисны үчекли, ул да кочмакчы.)*

Фарис. Китәсеңме, юкмы, убырлы, канса кансов!

Нажия. Киттем, киттем. *(Куркынып чыгып йөгерә. Аңа Надия тагыла.)*

Фарис *(кызыл дәү телефонга тотына, ачыргаланып, трубкага дәшә).* Гали Галич?!

*Алтынчы күренеш*

Биектә, кәнәфидә телефон трубкасын тоткан Гали Галич күренә.

Галич. Ни булды, кияү, нефть таптың мәллә, тавышың бик көр. *(Кабинет өстәле янындагы медальле этен сыйпый.)*

Фарис. Минем каршымда «икенче мин»ем утыра. Кинәт пәйда булды.

Галич. Нәрсә, бик шокәтсезмени?

Фарис *(Фарис-2 гә карый, тегесе маймыллана).* Макака төсле.

Галич. Борчылма, бераздан эткә охшый башлый әле ул.

Фарис. Сез моның шулай буласын белә идегез?!

Галич. Ә мин сине алдан ук кисәттем, югалтыр әйберең бар, дидем.

Фарис. Ләкин сез кисәтмәгән хәл дә бар.

Галич. Бүтәннәрнең, үзеңнән түбән баскычтагыларның «икенче мин»нәрен күрә башладыңмы?

Фарис. Сез бөтенесен беләсез. *(Тәрәзәгә бара.)* Менә мин тәрәзәгә карыйм. Әнә мин сүккән җитәкчеләр кайтып бара, аларның «икенче мин»нәре минекедәй яньчелмәгән. Әнә мәчет картлары ясиннан кайтырга кузгалган, боларныкы, гомумән, матур. Әлбәттә, арада төрлесе бар. Минеке бит коточкыч!

Галич. Ә сәркәтибеңнеке ничек соң? Хатыныңныкы?

Фарис. Мин өйгә кайтырга да куркам.

Галич. Мин бер чибәрлек конкурсында җиңгән туташ белән очраштым. Вәт аның «икенче мин»е җирәнгечнең дә җирәнгече иде... Чит илдә ир белән хатын аерым ятакта, хәтта аерым бүлмәләрдә йоклый. Ә сиңа нәрсә комачаулый. Аңла, моннан бер җитәкче дә котыла алмый. Нәрсә сопли развел? Син бит башкаларның асылда ниндилеген, тышкы кабыкларына туры килмәвен элек тә белә идең. Үзеңнең асылда нинди икәнеңне чамаламавың да мөмкин түгел. Берни үзгәрмәде, син тоеп йөргәнне күрә башладың, синең күңел күзең ачылды! Бары шул!

Фарис. Ярый, мин башкаларның «икенче мин»ен күрдем дә ди, югарыдагылар минем кемлекне белүенә дә түздем ди. Ә түбәндәге, берәр тәҗрибәлесе минем үземне күрә икән, нишләргә? Бүген шундый берсе сугылып чыкты әле, һаман аңга килә алмыйм.

Галич. Боламык булмаска, ә инициативаны кулда тотарга кирәк. Исеңдә тот, беренчедән, кемне кабинетыңа чакыру, үткәрү — ул синең эш. Үзеңне танырдай зиһенлеләрне якын җибәрмә. Урынбасарлар, ярдәмчеләр ни өчен? Алар кабул итсен. Кабул итәм дигәннәрен, озак кына көттереп, башта йөз суларын түктер, без бит йөз суында коенучылар, йөз суында чумып йөзүчеләр. Гозерчең кергәч, сүзне кыска тот, аның «икенче мин»ен күз уңыңнан ычкындырма, көтелмәгән сораулар әзерлә һәм сискәндер. Гозерләрен хәл итеп узындырма, югыйсә бөтен әтрәк-әләм ташкын булып агылачак. Сез әле башта шушы, аннары бу инстанцияләрне узыгыз, бер дә булмаса, яңадан миңа килерсез, дип өметләндер. Боларны үзең дә беләсең. Ә менә күңел күзең ачылу белән ихлас котлыйм. Димәк, син инде иң зур җитәкче булырга да әзерсең, пешкәнсең. Шуңа мондагылар матур дип кайгырасы юк, Мәскәүгә җибәрәм әле мин сине. Вәт анда күрерсең хәшәрәтураларны. Кунскамераның ни икәнен беләсеңме? Белмәсәң, белерсең. Ә үзеңнең «икенче мин»ең белән дуслаш, иң якын киңәшчең булыр әле ул берзаман...

Фарис. Сезнеке яныгыздамы?

Галич. Мин аны сыйпаштырам. *(Этен сыйпый.)* Яле сыныйк, хәзер мин сиңа сораулар бирәм, син миңа җавапларыңны башта үзең уйлаганча, аннары шул «икенче мин»ең белән киңәшкәч әйтәсең. Татарга латин хәрефе кирәкме?

Фарис. Әлбәттә. Төрекләр, төрки дөнья шул хәреф белән яза, урыс хәрефе татар телен боза лабаса.

Фарис-2 *(килешми, кулларын бутый, телефон трубкасына иелеп кычкыра).* Аның бер тиенгә кирәге юк, латин хәрефе Рәсәй бөтенлегенә яный. *(Телен чыгарып, Фарисны үрти.)*

Галич. Татарстанга суверенитет кирәкме?

Фарис. Әлбәттә, кирәк, югыйсә Мәскәү бөтен малны суыртып, республиканың җелеген корыта.

Фарис-2. Суверенлык вакыты узды, яшәсен бердәм һәм бүленмәс Рәсәй!

Галиич. Менә күрдеңме, ул сине ялгыш адымнардан һәрчак саклаячак, синдәй кадрның кадерен Мәскәү беләчәк һәм сине югалтмаячак. Хуш, Фарис, иртәгә сәгать унга — миңа. Ә пәнҗешәмбе Мәскәүдә буласың. Кайт, әзерлән, хатыныңа сәлам әйт.

*Җиденче күренеш*

Фарис йорты. Наилә телефоннан номер җыя.

Наилә. Алло. Бу Камил абыйлар фатирымы? Сез Зәйтүнәме? Минме? Мин — Наилә. Моннан күп еллар элек сездән Фарисны култыгына кыстырып киткән тутаң. Әйбәт. Анталиядан кайттым, ә тиздән Кипрга, йә Кырымга ычкынырга исәп. Фарис эштә. Кемдер эшләргә тиеш ич инде, эшләгәнгә эш язган, ашаганга аш язган, диләрме? Камил абый ни хәл соң? Сәлам әйтегез. Менә гәзит карап утырдым да, сезнең хакта хәбәр күзгә чалынды. Котлыйм! Безгә килеп чыгыгыз. Проблемалар булса, әйтегез. Мин бит Камил абый өчен хет утка, хет суга. Ярый, тапшырырмын. Хушыгыз. *(Трубкасын куя.)* Тавышы бик бәхетле. Билгеле. Камил абый белән яшә дә бәхетле булма, имеш...

Фарис кайтып керә.

Фарис. Нихәл, карчык?

Наилә. Миңа путевка булдымы?

Фарис. Әле Анталиядан кайтканыңа кайчан, бик тиз арыгансың.

Наилә. Ардырасың бит. Иртүк китәсең, соң кайтасың, ятасың да гырлап йокыга китәсең һәм син монда бәк зур кеше. Зур кешенең хатынына тегеләй дә ярамый, болай да. Синең янда тәртибемнең гел бишле булуын теләсәң, инде үзең белеп озаткаларга вакыт, һәртөрле сәяхәтләргә, абзый кеше.

Фарис. Син эшкә чыккан идеңме соң әле сәяхәтеңнән кайткач?

Наилә. Исәнмесез. Апаң инде бер ай авырулар дәвалый. Район гәзитен укы, анда мине мактап язганнар. Гәзит дигәннән, республиканыкында Зәйтүнә хакында укыдым, фән докторы булган тутаң.

Фарис. Кайсы Зәйтүнә?

Наилә. Ну, кеше. Мәгъшукасын да оныткан. Минем якын дустым Камил абыйны эләктергән җыланың! Ә Камил абый булмагач, миңа беркем кирәкми, үзең беләсең.

Фарис *(ирония белән)*. Беркем дә кирәкми дисеңме?

Наилә. Яки кем булса да ярый.

Фарис. Шулай дисәң, бер хәл. *(Пауза.)* Котласаң ярар иде үзләрен. Адресларын табып булмастыр инде?

Наилә. Шуны да тапмаска! Таптым да, котладым да. Теләсәң, мә, чылтырат. *(Язу бирә.)*

Фарис. Ярар. Бәлкем, Мәскәүдән кайтышлый сугылып та чыгармын үзләренә.

Наилә. Иртәгә китәсең мәллә?

Фарис. Гали Галиичкә. Аннары Мәскәүгә очарга тиешмен.

Наилә. Мәскәүгә эшкә алалар. Ур-ра! Ну, рәхмәт Гали абыйга, тәки ялынганнарым бушка китмәде. Мәскәү — ул зур кала, анда рәхәтләнеп яшәргә була! Анда беркемнең беркемдә эше юк!

Бии, Фарисны әйләндерә.

*Сигезенче күренеш*

Фарис караватта йоклый, янында Фарис-2. Сәхнәдә ут йөри. Сәхнәнең икенче очында, шулай ук диванда Гали Галиич йоклый. Янында уяу Эт. Фарис-2
телефоннан номер җыя. Чылтырау.

Эт *(трубканы күтәреп.)* «Һау».

Фарис-2. Саулармысез.

Эт. Сау.

Фарис-2. Бу мин, Фарисның хакыйкый мине, Мәскәүдән, кунакханәдән чылтыратам. *(Фариска карап ала.)* Калыбым йоклый.

Эт. *(Гали Галиичкә карап ала).* Минеке дә бүсә. Димәк, распадылар. Йә, ничек анда хәлләр?

Фарис-2. Монда бар да безнең иш. Хәтта гади мәскәүлеләрнең дә «икенче мин»нәре кәкре дә бөкре.

Эт. Шулай булмыйни, кайчаннан бирле бөтен Рәсәй хакын ашап, коммунизмда яшиләр. Ә оятларына бер дә көч килми.

Фарис-2. Монда шәп тә, мине бездәге хәлнең үзгәлеге шаккатыра. Күпчелекнең «икенче мин»нәре алай әллә ни гарипләнмәгән, яньчелмәгән. Бербөтен булып яшәүчеләре дә шактый.

Эт. Ну, без дә йоклап ятмыйбыз бит. Күр, укытучыларны нинди пүчтәк хәлдә калдырдык. Бу аларның үзләрен генә түгел, яшь буынның да рухын яньчү дигән сүз.

Фарис-2. Чагыштырып карасак, барыбер безнең хәл мөшкелрәк, күр сине, күр мине. Гади кешеләрнең хакыйкый «мин»нәре мондый түгел.

Эт. Димәк, тырышлыкны арттырырга кирәк. Халык бик сикеренмәсен өчен, рәтле хезмәт хакын, гомумән, күрмәскә, һәртөрле ясаклар, алдаулар, кысрыклаулардан даими һәм бертуктаусыз изелергә, тапталырга тиеш. Ә урыннарда шуны аңлап һәм эшләп җиткермиләр икән, димәк, гаеп бездә дә юк түгел.

Ут сүнә.

Казан. Камил фатиры. Зәйтүнә, шәмнәр кабызып, табын әзерләп йөри.
Магнитофонга кассета куя. Җыр ишетелә.

Урамнарда буран дулый иде,
Чәчләреңне димләп җиленә.
Ә мин сине җибәрмәдем,
Китәлмәдең барыр җиреңә.

Син утырдың шәмгә кулың сузып,
Бүгенгедәй истә ул чаклар.
Якыная барды әкрен генә,
Күзеңдәге ерак учаклар.

Алсуланып, бүлмә офыкланды,
Шәфәкъ төсе сеңде алмага.
Тәрәзәңнең зәңгәр төшенә кереп,
Ап-ак чәчкә атты абага.

Ай калыкты күңел күкләреннән,
Син кояштай балкып утырдың.
Ә урамда буран дулый иде,
Бар юлларны карлар тутырды.

Хәтеремдә, матур якты булып,
Һәр мизгеле калды ул кичнең.
Мин бит ул чак бик яшь, белми идем
Ни икәнен сәер ул хиснең.

Ишектә кыңгырау чылтырый. Зәйтүнә барып ача. Фарис керә. Кулында чәчәк
бәйләме һәм төргәк. Бер-беренә карашып торалар.

Фарис. Исәнме, Зәйтүнә! *(Чәчәкне тоттыра, төргәген идәнгә куя.)*

Зәйтүнә. Фарис! Нинди җилләр ташлады? Чәчәкләр! Миңамы?

Фарис. Сагындым. Мәскәүдән кайтыш, биш кенә минутка кердем, рөхсәттер бит?!

Зәйтүнә. Рәхмәт керүеңә. Син хәзер бик зур кеше бугай? Ничек вакыт таптың?

Фарис. Үстерәләр дә үстерәләр, чыдап кына тор, инде Мәскәүгә үк үрләттеләр, Наилә шатлыгыннан нишләргә белми, үрле-кырлы сикерә.

Зәйтүнә. Димәк, син барыннан да канәгать, мин синең өчен ифрат та шат. Уз, сал өстеңне, утыр табынга. Әйе, кыяфәт шәп синең.

Фарис *(Зәйтүнәне биленнән әләктереп).* Музыкасы матур, бер биик әле башлап, шул сылтау белән кочаклашып күрешербез, чөнки мин бу очрашуны бик зарыгып көттем!

Зәйтүнә. Әйдә соң. Күрче, вальс әйләнмәгәнемә бишбылтыр икән бит. *(Биеп китәләр. Кинәт яшен яшьнәгәндәй була һәм Зәйтүнә яшәрә, матурая, ә Фарис, Фарис-2гә алмашына. Зәйтүнә, Фаристан ычкынып, читкә тайпыла. Ут рәтләнә. Зәйтүнә куркып кына Фарис ягына борыла.)* Беләсеңме, әллә галлюцинациягә тап булдым, электр уты уйнады бит әле генә, шул мизгелдә минем күзгә, берүк гафу ит, син кинәт ниндидер шайтан сыман булып күрендең?!

Фарис. Ә менә син, ул ут уйнаганда, миңа фәрештә булып тоелдың. Ничек саклый алдың асылыңны? Югыйсә син дә гомереңне көлдән борчак чүпләп уздырмагансың, фән дөньясындагы пирамида да хакимиятнекеннән ким түгел. Мин барыннан да хәбәрдар. Фән докторы булуыңны, АКШка симпозиумга барып доклад укуыңны һәм зур уңыш казануыңны да беләм. Һәм котлыйм.

Зәйтүнә. Мин барысы өчен дә сиңа рәхмәтле.
Фарис. Миңа?
Зәйтүнә. Сиңа. Син мине аның белән таныштырдың.
Фарис. Ә бит син миңа гашыйк идең?
Зәйтүнә. Шулай дип озак ялгышып йөрдем. Мин бит аның тәкъдимен кабул итмәдем син өйләнгән чорда. Кайгырдым, баш-аягым белән фәнгә бирелдем. Ә ул барыбер үземә сиздерми генә гел ярдәм итте. Очраганда, баш кагып, исәнләшеп йөрдек. Әмма бермәл Камил каядыр юкка чыкты һәм мин аны юксына башладым.
Фарис. Мин үземне синең алда гел гаепле сизеп җәфаландым тагы.
Зәйтүнә. Берүк, тыныч бул, мин сине шундук оныттым. Ә аны юк. Каядыр эш белән, озаккарак озаткан булганнар икән, үзе дә карышмаган, күрәсең, кайчан кайтасын белешеп, каршы алдым.
Фарис. Һәм сез бергә?
Зәйтүнә *(күзләре яшьләнә).* Беләсеңме, мин аны көн дә сагынып яшим. Ул ничектер саф һава шикелле кеше...
Фарис. Шуңа да чиста һәм матур килеш саклангансың. Ут уйнаганда күзеңә чалынган бөкре шайтан ул бит минем чын асылым. Әле тагын нинди кыяфәтләргә каласымны бер Ходай белә.
Зәйтүнә. Куй әле юк-бар шаяртуларыңны, сал өстеңне, утыр.
Фарис. Ә Камил кайда соң үзе?
Зәйтүнә. Ә син үзең чамала. Уйласаң, табасың! Малай белән кияүне дә ияртте җитмәсә.
Фарис. Булмас, Зәйтүнәкәй. Ул бит инде хәзер академиктыр?
Зәйтүнә. Юк, һаман элеккечә, кандидат көе.
Фарис. Китсәнә. Ә ул сине яраттымы соң?
Зәйтүнә. Яратмаса, бер кыз бер малай алып кайтмас идек.
Фарис. Һей, без дә алып кайттык ул ике малай. Әмма арада тамчы да мәхәббәт булмады. Бер яктан да!
Зәйтүнә. Беләсеңме, Фарис, Камил дә Наиләне юксынып яшәде. Элегрәк миңа, ялгышып китеп, Наилә дип эндәшкәләде. Хәзер алай әйтми, әмма Наилә туган көне белән котлагач, башы күккә тиде. Аннары шул вагон бушатырга йөгерә инде. Күрәсең, ул үзенә җан дәвасын авыр хезмәттә таба, йөрәк ярасын шуның белән баса.

Ишектә кыңгырау чылтырый.

Зәйтүнә. Ахры, үзләре дә.

Эш киеменнән Камил кайтып керә. Бераз салган.

Камил. Нихәл, әнисе. Малай кияүләргә кереп калды, хәзер кызны, оныкны алып килеп җитәләр. Кем бар бездә? Фарис, син түгелме соң бу, чемпион!
Фарис. Камил! Әллә һаман вагон бушатасың?
Камил. Бүген бит шимбә.
Фарис. Беләктә егәр җитәме соң?
Камил. Бер вагонны сизмим дә әле! Шулай бит, әнисе.
Зәйтүнә. Шундый хобби да була икән.
Камил. Син озаккамы? Теләсәң, иртәгә берәрне бушатып кайтабыз.
Фарис. Минем Мәскәүдән кайтыш. Бер күрешеп, икегезне дә котлап чыгыйм дип кердем. Бүген бит синең туган көн. Ничә ел узды инде теге туган көннән бирле?
Камил. Әйтергә дә куркыныч. Наилә нихәл анда? Ул да котлап чылтыратты бит әле. Ни гомерләр узгач, көтмәгәндә...
Фарис. Зәйтүнәнеме?
Камил. Кичә Зәйтүнәне, бүген мине.
Зәйтүнә. Фарис зур бүләкләр белән килгән, әтисе.
Камил. Фарис, син өстәл тирәсенә урнаша тор, кая анда, кишер бармы? Күкәй куелмаган. Кулны юып килим әле мин тиз генә, бүләкне тотып карыйсыдыр бит. *(Китә.)*
Зәйтүнә. Бар да әзер, хәзер сораганыңны да чыгарам. *(Кухняга китә.)*

Фарис янында Фарис-2 пәйда була.

Фарис-2. Син мине күрәсеңме?
Фарис. Кызганычка каршы, күрәм.
Фарис-2. Инде аларны минем, ягъни үзең, үзеңнең чын асылың белән чагыштыр.

Фарис. Мин аларның «икенче мин»нәрен күрмәдем бит әле.

Фарис-2. Күрмәссең дә. Алар бербөтен булып яши. Алар өчен шәхесләренең икегә аерылу хаҗәте тумаган.

Фарис. Ә Наилә? Мин аның да «икенче мин»ен очратмадым.

Фарис-2. Ул да бербөтен.

Фарис. Кызык. Хәзер миңа синеңчә нишләргә кирәк инде?

Фарис-2. Болар исәнлегенә берәр чәркә күтәрергә һәм тизрәк таярга. Алар мине абайламасыннар дисәң.

Фарис. Зәйтүнә сизде ич.

Фарис-2. Ул аңышмады...

Зәйтүнә йомырка тәбәсе алып чыга, Камил керә һәм чәркәләргә шәраб агыза.

Камил. Йомырка тәбәсе! Тәк, нинди вино бу? Әйдә, үз кучтәнәчең белән сыйлансаң, гомерең озын була ди. Әмма мин үземә аракы салам инде, буталмасын. Вагонны бушаткач, берне бөклим бит мин хәзер.

Бар да күтәреп куялар.

Фарис *(урыныннан кубып).* Җәмәгать, мине гафу итегез, икенче юлы шимбә көн иртәннән килермен, берәр вагон да бушатып атарбыз, бәлки. Рөхсәт итегез, мин кузгалыйм.

Камил. Малай белән кызны, кияүне һәм оныкны күрми китәсеңмени? Бигрәк тиз.

Фарис. Икенче юлы.

Камил. Наиләне дә үзеңнән калдырма, килеп чыкканда, аның бит миңа бертуган сеңел кебек икәнен беләсең. Шулкадәр сагындым үзен.

Фарис *(залга карап).* Аһ, ул синең сеңлең. *(Фариска.)* Кая торганыгызны күрдем, очрашмый тормабыз, хушыгыз.

Камил. Мин озата чыгам, әнисе. *(Камил белән Фарис чыга.)*

Зәйтүнә *(тәрәзәгә килеп).* Ай-һай, машинасының зурлыгы танк кадәрле. Ә бит бу кеше мине өзелеп ярата иде заманасында. Менә нинди уенчыкка алмаштырган булган икән ул мине.

Икенче пәрдә тәмам.

## ӨЧЕНЧЕ ПӘРДӘ

Камил фатиры. Камил йоклый. Бертуктаусыз кыңгырау чыңлый. Камил, көч-хәл белән уянып, ишеккә килә, анда Наилә. Кулында чәчәк һәм төргәк.

Камилнең элекке егет чагы, Наилә дә яшь.

Камил. Син үзең генә. Ә кайда Фарис?

Наилә. Нинди Фарис?

Камил. Синең ирең.

Наилә. Минем ирем?

Камил. Әйе!

Наилә. Камил абый, син исерек мәллә?

Камил. Туктале, ә Зәйтүнә кайда?

Наилә. Нинди Зәйтүнә?

Камил. Ничек нинди, минем хатын, билгеле?

Наилә. Син өйләндеңмени? Аһ, подлец, ә нәрсә туган көнеңә дәшеп торган буласың соң алай булгач. Шаяртасың. Ну, Камил әкә!

Фарис. Гаҗәп, син шундый яшь.

Наилә. Син дә әллә ни карт түгел, утыз өч кенә бит әле.

Фарис. Миңа утыз өч кенәме?

Наилә. Ә синеңчә күпме?

Камил. Илледән дә ким түгел.

Наилә. Стоп. Сиңа нидер булган. Галимнәр белән андый хәлләр булгалый бугай. Әйдә, бергәләп хәзерлибез. Син миңа кичә яшелчә базасыннан чылтыраттың. Бер вагон бушатасы бар, дидең. Иртәгә туган көнгә кил, дидең. Исеңә төштеме?

Камил. Бик томанлы.

Наилә. Тагын бер пар була, дидең. Яхшы. Сәгать ничәдә вагонны бушатып бетердегез?

Камил. Төнге уникеләрдә шикелле.

Наилә. Шуннан син кайтып киттең?

Камил. Иртәнге берләрдә кайтып кердем.

Наилә. Аннары ятып йокладың?

Камил. Бик арылган иде, әллә ни йоклап булмады. Эшкә киттем. Әбәт тирәсендә коллегалар белән туган көнне билгеләп үттек. Аннары, азык-төлек алып, өйгә кайттым, табын әзерләдем. Аннары, диванга утырып, ял итәргә уйладым, миңрәткән, күрәсең.

Наилә. Менә бар да аңлашылды, Камил абый. Хәтерлә, тагын кемнәрең килә туган көнеңә? Ученый мирдыр инде, шулаймы?

Камил. Юк. Күңелсез, сөмеки кешеләр булмый.

Наилә. Кая, нәрсәләрең бар? *(Өстәлне барлый.)* Әһә, селедка, торт, хәмерләрең ярыйсы. Ә бу кишер нәрсәгә тагын?

Камил. Табыныңда кишер дә юк иде дип әйтмәскә. Духовкада чикмәнле бавырсак, утын кабызып җибәр әле.

Наилә. Бавырсак?

Камил. Әрчемәгән бәрәңге. Һәм минем табында пешкән күкәй дә булырга тиеш.

Наилә. Анысы ни өчен тагын? Ә-ә. Аңладым. Табыныңда ул да юк иде дип әйтмәсеннәр өчен. Әйтерең бармы, нәзакәтле юмор. Камил ага, деградируешь. Сиңа өйләнергә кирәк. Туктале, гомердә булмаганны син ничек туган көн уздырырга булдың соң, ә?

Фарис. Син шуңа кызыксынып, бар эшеңне ташлап чабып килеп җиттең?

Наилә *(аптырабрак)*. Дөрес...

Фарис. Тагын кемнәр килә дисеңме?

Наилә. Әйе.

Камил. Фарис килә. Галим түгел. Студент. Вагон бушату буенча чемпион. Һәм аның мәгъшукасы Зәйтүнә.

Наилә. Менә бу күчтәнәчләрне дә тезик әле.

Камил. Болар бит минем сый-хөрмәтне күләгәдә калдырыр.

Наилә. Юк, киресенчә. *(Камил аны бүлдерә.)*

Камил. Ачар димәкчесең?

Наилә. Син мине ярты сүздән аңлый башлагансың, сагынгансың, ахры?

Камил. Сагындым. Син нинди машина белән килдең соң? «Феррари»?

Наилә. Үземнеке автосервиста. Дус кызныкын алып тордым. «Ауди». Син бит ошатмыйсың андый нәрсәләрне, исеңдәме нәрсә дидең, тәти уенчык сорыйсың, сиңа алып бирәләр, ә Камил абыең уенчык түгел, гәрчә шулай тоелса да, имеш.

Камил. Карале, Наилә. Зәйтүнә дигәндә, минем кыяфәт мокытланмадымы?

Наилә. Син болай да мокыт кыяфәттә.

Камил. Тагы да мокытланмадыммы? Йә, тагын бер әйтеп үтәм, Зәйтүнә!

Наилә. Бернинди аерма юк.

Камил. Наилә, чеметеп бор әле минем колакларны утыз өч мәртәбә.

Наилә. Рәхәтләнеп. *(Камилнең колакларын бора.)*

Камил. Уй! Җитеп торыр. Бусы өн, ахры. Белсәң, мин нинди төш күрдем, тәннәрем әле дә чемерди. Мин төшемдә егерме еллап яшәдем. Балаларым, оныкларым булды.

Наилә. Ә ул төштә мин дә бар идемме соң?

Камил. Ничек кенә әле. Гәүдәң ничектер калынрак иде анда. Фариска кияүгә чыктың. Мескен Фарис, күрмәгәнен күрсәттең син аңа.

Камил. Нинди Фарис?

Камил. Чемпион. Вагон бушату буенча. Хәзер киләләр.

Наилә. Бар, юын, кырын, өстеңне алмаш, ә мин табын әзерли торам.

Камил чыга, Наилә җырлый.

Наилә. Мәхәббәт один раз,
Килми ул много раз.
Как сандугач, как сандугач,
Каждый яз...

Камил тавышы. Син каян беләсең минем җырларны?

Наилә. Бәрәч, ничә ел күрше яшәп белмәскә?! Мин түгел, әни дә җырлый боларны. Сине бик ошата бит ул, сәлам әйтеп калды.

Камил. Вәгаләйкем сәлам. Бәлеш пешереп калды дисең инде.

Наилә *(куркып)*. Әйтмәдем. Әмма пешереп калды. Тукта, син каян беләсең?

Камил. Мин сине ярты сүздән аңлый башлаганмын.

Наилә. Сколько раз, гүзәлләрне күреп,

На минутку хискә исердем.

Камил *(күлмәк киеп килеп чыга).* Ак күлмәк, кара яка. Әй лә, кара галстук. *(Пиджак кия.)* Кияү кыяфәте бармы миндә? Әзрәк?

Наилә. Кемгә ничек, кәҗәгә кәбестә, диләрме әле? Син миңа матур күренәсең. *(Ишектә кыңгырау чылтырый.)* Әһә, килеп тә җиттеләр.

Камил. Күзәт, минем кыяфәт мокытланамы?

Наилә. Сизелми.

Камил *(ишеккә барып)*. Әйдүк, кадерле кунаклар, түрдән узыгыз, рәхим итегез! Таныш булыгыз, Наилә. Ә болар Фарис белән Зәйтүнә. *(Наилә Зәйтүнәне кочып ала, Фариска кулын суза. Фарис кулны үбеп ала.)*

Наилә. Аһ, менә сез нинди икән, Фарис әфәнде!

Фарис *(авызын ерып).* Без шундый! Менә бу кейс бездән бүләк, докторлык диссертацияңне ташып йөрергә.

Зәйтүнә. Ә бусы — сезгә чәчәкләр.

Камил *(бүләкләрне алып)*. Рәхмәт сезгә.

Наилә. Җәмәгать, табынга утырыйк. Ә минем дә бер бүләк бар бит. *(Сәгать суза.)* Очсызлы гына, командирский, кыйбатлыны алсаң, сукрана торган гадәтең бар, ошамаса, үзеңә үпкәлә. *(Камил, кулындагы чәчәкләрне алып, вазага урнаштыра.)*

Камил. Рәхмәт, кадерлем! *(Битеннән үбеп ала. Наилә гаҗәпсенә.)*

Наилә. Еллар имин булсын.

Утырышалар.

Наилә. Йә, Фарис, сезнең колхозда кызлар белән ничек көрешкәнне күрдек, инде шампан аттырып күрсәтегез!

Камил. Йоклама, Фарис дус, йоклама.

Фарис *(шампан аттыра, бокалларга коя)*. Шулай аттыралар аны безнең авылда. Кадерле дуслар, Камил туган. Бүген сиңа утыз өч яшь. Гомереңнең өчтән бере үтеп тә киткән.

Камил. Мине туксан тугызлы диюгә ишарә бугай бу? Ә бәлкем киресенчәдер?

Фарис. Әйе, киресенчә.

Камил. Мин акыл иясе?

Фарис. Әйе, син акыл иясе.

Камил. Ә акыллы кешене ихтирам итү җиңел булса да, яратуы авыррак.

Фарис. Дөрес. Тик син мин әйтәсе сүзләрне авыздан тартып аласың.

Камил. Дәвам ит. Туктадым.

Фарис. Ә акыллы кешене ихтирам итүе җиңел булса да, яратуы авыррак. Мин сезгә һәр өлкәдә, һәм бигрәк тә мәхәббәттә, уңышлар телим. Ә анда уңышка ирешү өчен, минем карашка, сезгә печтеки генә җүләрлек җитми. Шул дефицит та бетсә, сез тәмам камиллеккә ирешеп, бәхетле булачаксыз. Мин сезгә, бәхетегез хакына бераз гына җүләрлек телим.

Наилә. Ә шәхси үрнәк?

Фарис. Һәм шәхси үрнәк күрсәтәм. *(Эчеп куя. Башкалар да рюмка күтәрәләр. Зәйтүнә минераль су эчә, Наилә башын чайкый.)*

Наилә. Браво, Фарис. Син югалткан очколарыңны кире кайтардың. Менә нидә икән аның проблемасы. Санагыз, унсигез секунд үтүгә, тиз генә бокалларны менә шушы затлы шәраб белән кабат тутырасы була. *(Бокалларны тутыралар.)* Сез беләсез микән, юк микән, әмма Камил абыегыз җырлар яза. Шуларны үзе җырлый да. Бер кышкы буранда мин менә шушы фатирда кунып калган идем. Күзләреңне түгәрәкләндермә, Фарис, Камил абый ул чын кеше. Дөрес кочкандыр, бәлкем үпкәндер дә, әмма син уйлаганы — юк. Ул бит, син яшь, ә мин карт, дип аптырата. Әйтерсең хикмәт анда. Ул шул кич хакында бер җыр язды дип беләм, башта менә шушы шәрабны эчик тә, Зәйтүнәкәй, бу юлы сез дә су эчеп котылмассыз, бәлки, аннары шуны рәхәтләнеп тыңлыйк әле.

Камил *(магнитофонга кассета куя).* Музыкасын кассетадан ишетербез, ә җырын җырлап карыйк булмаса. Әмма башта тамакны чылатмый да ярамастыр, әйдәгез, алай булгач, сафлык, саф мәхәббәт өчен күтәрик.

Рюмкаларны күтәреп куялар.

Камил *(җырлый).*

Урамнарда буран дулый иде,
Чәчләреңне димләп җиленә.
Ә мин сине җибәрмәдем,
Китәлмәдең барыр җиреңә.

Син утырдың шәмгә кулың сузып,
Бүгенгедәй истә ул чаклар.
Якыная барды әкрен генә,
Күзеңдәге ерак учаклар.

Алсуланып, бүлмә офыкланды,
Шәфәкъ төсе сеңде алмага.
Тәрәзәңнең зәңгәр төшенә кереп,
Ап-ак чәчкә атты абага.

Ай калыкты күңел күкләреннән,
Син кояштай балкып утырдың.
Ә урамда буран дулый иде,
Бар юлларны карлар тутырды.

Хәтеремдә матур якты булып,
Һәр мизгеле калды ул кичнең.
Мин бит ул чак бик яшь, белми идем
Ни икәнен сәер ул хиснең.

Наилә җыр барышында Камилне биергә чакыра. Фарис белән Зәйтүнә дә бергә бииләр. Җыр тәмам булгач, Наилә, Фарис, Зәйтүнә кул чаба.

Наилә. Беләсезме, дуслар. Мин тиз генә өйгә кайтып, бәлеш алып киләм, бәлешсез табын табын ук түгелдер ул.

Фарис. Бәлкем мине ияртерсез?

Наилә. Син тагын очколарыңны җуйдың. Кунакка алып килгән кызыңны ятларга калдырып китү егетлек түгел. Мин үзем генә дә адашмам.

Зәйтүнә. Камил абый бик ягымлы әле монда, Фарис китүгә, мин тамчы да каршы түгел!

Фарис. Зәйтүнә, нишләвең? Син бит мондый түгел идең?

Зәйтүнә. Асыл кошны ансат тоттың да, асрый белмәгәч, ул каргага әйләнде!

*Пауза.*

Камил. Фарис дус үзенең тостында миңа бәхетле булу өчен нәрсә җитмәгәнен төгәл әйтте. Мин аның фикере белән килештем. Миңа җүләрлек җитеп бетми, диде ул. Ә мин аны бүген эшләргә җыенам. Дусларым. Мин менә шушы кызны, Наиләне өзелеп яратам. Дөрес, ул миннән күпкә яшь, шул сәбәпле аңа тәкъдим ясарга кыймый җәфаландым, аны кызгандым. Әмма мин аны яратам. Аны гына яратам һәм ул да миңа битараф түгел дип өметләнәм. *(Наиләнең күзләреннән бәхетле яшьләр ага.)* Шаһитлар алдында, дусларым алдында тәкъдим ясыйм. *(Алдына килеп бер тезенә йөгенә.)* Наилә, минем кәләшем булырга син ризамы?

Наилә. Юк!

Фарис. Ничек юк?

Зәйтүнә. Ничек инде юк?

*Пауза.*

Наилә. Мин аның хатыны булырга телим. *(Барып Камилнең кочагына ташлана.)*

Фарис. Ә бәлеш белән нишлибез?

Наилә *(Камил кочагыннан каерылып).* Әйттем ич инде, алып киләм, дип.

Камил. Юк, хәзер җыйнаулап, кыз ярәшергә барабыз! Ә анда безне бәлеш пешереп көтеп торалар!

Җыр, музыка.

Өченче пәрдә тәмам.

# ЭЧТӘЛЕК

## ШИГЫРЬЛӘР


«Мин аклыктан качып китеп барам...»
«Һәр язганыннан кычкыра...»
Нәсыйхәт
«Инде менә күпме уйладым...»
«Карап торырга соклангыч...»
«Чабаталар атып, илдән сөргәч...»
«Ай Җир тирәли әйләнә...»
«Җәйне — яшәү, кышны — тыну, диләр...»
«Алга бараммы, арткамы — төшенмим...»
«Юк, яратмый идем, күрсәм җилдә...»
«— Алай түгел, болай кирәк, — дия-дия...»
«Кайчакларда сагыш ачыттыра...»
«Беркем хәтерләми икебезнең...»
Ничә гасыр...
Китү
Галләм маскасы
Тәрәз кинәт ачылды як-якка
Туган тел
Һәйкәл
Тукталып калдым да
Бер хатирә
Зиратта
Юкка...
«Китеп барган чак та булды...»
Бүректәге бүре баласы
Кеше?
Юбилейда уйланган уй
Бер мөхәррир авызыннан
Акча мәсьәләсе
Биофиллар
Күрсәт ихласлыгың!
Мин борылып яттым
«— Тибүчеләр»не фаш итеп...»
Шагыйрь дуста кунакта
«Адәм әүлиясы» дими җай юк...»
«Бәйсез этләрне атарга» икән...»
«— Татарстан, әйтче, син соң мөдәм илме?..»
Алыш-биреш
«КамАЗ арты АлАЗ күтәрелә...»
«Җитәкчене шуннан таныйм...»
Академиклар
СССР тарихы
«Аргамактан туа толпар...»
Алма
«Кешеләр бу табышмакны...»
«Шарт»намә
Тукай бүләген бүлгәндә
«Үрмәләүче мәңге оча алмый!..»
«Татарның миенә борау...»

«Күңел түргәрәк омтыла...» ================================================
«— Йөрмә, энем, ут йотып...» ==============================================
«...Порнобоевикка тарта Җирдә тормыш...» ==============================
«Өрми, нитми, кертми», — имеш...» ========================================
«— Мин — бәхетле! — дип кычкырды мескен...» ============================
«Шашлык ашый идек урманнарда...» =====================================
«Бүген дә көн узып китте, йа Алла...» ====================================
«Остаз» киңәше ==========================================================
Федералиссимус ==========================================================
«Мин дә әйтим әле, әфәнделәр...» =========================================
Туташ ===================================================================
Хирург монологы =========================================================
Пародокс ================================================================
Зыялыларымыз ============================================================
«Имеш, матур чәчәк атсын өчен...» ========================================
Ишек шакыдылар... =======================================================
«Ике ахмак бәхәсләшә...» ================================================
Мантыйк =================================================================
Кайту ===================================================================
Хуш, бәхил бул, Рәсәй... ================================================
Газаплы гашыйк ==========================================================
Җирсү ===================================================================
Тел яздыру ==============================================================
Толпарым җитез иде... ===================================================
Юл чатында ==============================================================
Төш =====================================================================
Ник төкәнми? ============================================================
Бу — безнең ил түгел... =================================================
Майтап җиңгинең Халит абзый колагына ирештергәннәреннән ========

ҖЫРЛАР

Җайдаклар ===============================================================
Тамчы гөл ===============================================================
Халәт фасыллары =========================================================
Беренче кар =============================================================
Солтанәхмәт =============================================================
Яфрак өзелгәндә искәрәбез... =============================================
Мишә ярыннан йөгердек... ================================================
Кайларда адашып калдыгыз? ===============================================
Зилә, Зилә, Зиләйлүк ====================================================
Туган көн ===============================================================
Тургай рухташы ==========================================================
Йосыф Алан ==============================================================
Саба ====================================================================
Саба сабан туйлары ======================================================
Биектау =================================================================
Адай ====================================================================
Миңгәрем ================================================================
Аккош микән, әллә син микән? =============================================
Алга, Татарстан яшьләре! ================================================

ПРОЗА

Көзнең гадәти бер көне ==================================================
Уйна, гармун! =========================================================
Әләметдин ============================================================
Маңгай ===============================================================
Сөялдем сөяннәргә =====================================================
Тозлы яңгыр ==========================================================
Бүрек ================================================================
Ак теплоход ===========================================================
Ләйсән ===============================================================
Ау-у-у! ===============================================================
Кгугом кгис ===========================================================
Тотынырга салам бармы? ===============================================
Җиктереп «Тулпар», Кырымга ==========================================

ЮМОРИСТИК ПАРЧАЛАР ============================

ДРАМАТУРГИЯ
Ни мамык, ни каурый *(лирик трагикомедия)* ===========================

Заказное издание

Рөстәм Зарипов

ФУКСИЯ

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Рәссамы *Н.Ю.Воропаева*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.П.Клипова*
Корректоры *Р.В.Сабирҗанов*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 13.01.2004. Форматы 84x108 $^{1}/_{32.}$
Офсет кәгазе. Офсет басма. Шартлы басма табагы 10,92+форз. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 11,55. Нәшер-хисап табагы 11,78+форз. 0,36.
Тиражы 2000. Заказ Э-14.
Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.
**http://www.tatarstan.ru/books/**
**E-mail: tki@books.kazan.ru**

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.